PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

№ 5 / 2022

# СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН
*сүз тидерерлек булмасын*

*килен-кайнана әйтелми калган* РӘХМӘТ

БРИЗОЛЬ *үзгә ризык*

*Ландыш* ЗАРИПОВА:

*«Журналистика бөтен хыялларымны да колачлый».*

PRESSA

# Әниемнең туй күлмәге...



Әниемнең туй күлмәге...
Сезнең гаиләнең матур
бер ядкаре.
Кадерле кешегезнең
яшьлегеннән бер кайтаваз.
Аның иң бәхетле бер көненең
шаһиты.
Саклана мы ул сездә?
Аны кулга алгач, йөзе балкып
киткән әниегез нәрсәләр искә
төшерә, нинди истәлекләр
сөйли?
Бездә яңа проект: әниегезнең
туй күлмәген киеп көзге
алдында бөтерелгән
мизгелне сурәтләгән
фотосурәтләрегезне көтәбез.
(«Минем кыз чагым син,
кызым!» – дип әйтәдер
әниегез сезгә карап.
Яратып, сөенеп, аз гына
моңсуланып...)
Тагын – аларның туй көненнән
бер мизгел дә көтәбез!

■ «Туй күлмәген кияү егете туйга кадәр күрмәскә тиеш», – диделәр безгә. Әтиең белән бу хорафатларга кул селтәдек! – дип көлә әни. – Күлмәкне базардан яки кибеттән генә түгел, ә сатучының фатирына ук барып алырга туры килде.
Шуңа да икеләтә кадерле...»
Яшьлек... Икесе дә дәртле, кызу канлы һәм бер-берсенә чиксез гашыйк. Әлбәттә, аларның туйлары да шаяруларсыз, көтелмәгән хәлләрсез үтмәгән. «Туй мәҗлесе барганда, тәнәфескә чыккач, әтиең белән мунчада икәүләп күлмәкнең пычранган җирен кер сабыны белән юганыбыз әле дә онытылмый. Яңгырдан соң икенче көнне өйләнештек – шуңа табы да хәйран иде шул», – дип искә ала әни.
Эзләгән – табар. Әнинең тыйнак, изүе ачык булмаган күлмәк киясе килгән һәм ул аны тапкан. Шулай ук әни гомерлек сөю һәм бәхет турында хыялланган. Һәм ул аны да тапкан...

Айзилә САБИРОВА.
Арча районы.

Фото: Анна Арахамия.

# Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2022




Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

**Баш мөхәррир**
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

**Редакциянең гомуми телефоны** 222-09-77

**Җитәкче урынбасары** 222-09-78
Рәмзия Кашапова
**Баш мөхәррир урынбасары** 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
**Җаваплы сәркатип**
Алсу Шакирова
**Әдәби мөхәррир**
Эльмира Закирова
**Сайт мөхәррире**
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

**Тышлыкта:**
Ландыш Зарипова
Фото: Анна Арахамия

**Мөхәррирләр**
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Лилия Гәрәева
Фәгыйлә Шакирова
**Верстка**
Резеда Галиуллина
**Корректор**
Фирдәвес Исмәгыйлева
**Фотокорреспондент**
Анна Арахамия
**Гамәли хезмәткәрләр**
Ильмира Сөләйманова
Павел Фадеев

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 22.04.2022 ел.
Чыгу көне: 29.04.2022 ел.
Заказ О-1228
Тираж 9286

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+

Резеда ВӘЛИЕВА

## *Җиңү килгән көн*

*Идел-ярга ярсып-ярсып*
*Чал дулкыннар каккан чакта,*
*Ерак-ерак юллар гизеп,*
*Кошлар илгә кайткан чакта,*
*Куе кара болытларны*
*Ярсу җилләр таратканда,*
*Төн карасын ярып җирдә*
*Якты-аяз таң аткандай,*
*Килде ул көн, балкып килде,*
*Кояш көлде, дөнья көлде.*
*Шаян җилләр, ашыга-ашыга,*
*Тупылларга чуклар элде.*

*Яшь бөреләр, бәбкәләрдәй,*
*Талпынышып куандылар.*
*Умырзая чәчәкләре*
*Елмаешып уяндылар.*

*Җырчы кошлар матур сайрап*
*Шатлык хәбәр итте җиргә:*
*Ул көн меңнәр зарыгып көткән*
*Бөек җиңү килде илгә...*



# 9 МАЙ — БӨЕК ҖИҢҮ КӨНЕ



Фото: https://president.tatarstan.ru/



# Безнең тышлыкта

«Бездә эш бүленеше юк. Әле вёрстка ясыйбыз, әле ТНВга төшереп җибәрәбез, әле берәр чарага чыгып йөгерәбез йә интервьюга китеп барабыз. Йөгерәбез, очабыз!»


18

Журналистикага – кастинг аша

Эльмира Закирова



10





14





22





«Мин эшләгәч, сүз тидерерлек булмасын...»

Чулпан Галиәхмәтова

«Әнкәй, мине бик сагынсаң...»

Алсу Шакирова

«Улларым үземне тәрбияли»

Чулпан Галиәхмәтова

Э Ч Т Ә Л Е К


## Заман һәм без

Исламда хатын-кыз хокуклары нык саклана 6
Гөлнур Сафиуллина

## Татар дөньясы

Әйтелми калган рәхмәт 24
Алисә Шәрәфиева

«Ак калфак» – рухи бишегебез 27
Эльмира Закирова

Яңгыркаем, яу, яу! 28
Лилия Гәрәева

## Мәдәни тормыш

Татар читеге 30
Ренат Харис

Алдашу 37
Марат Кәбиров

## Яшәеш

Әнием хатлары 44
Нәзифә Кәримова

«Йөрәгем кичерми...» 48
Гөлнур Сафиуллина

Һади бураны 52
Фәгыйлә Шакирова

«Өйдә мин ишетергә теләгән кешенең тавышы яңгырый...» 54

## Хуҗабикә


Яшь әни: сорау–җавап 56

Бию терапиясе 58

Күрү сәләтен яхшыртабыз 59

Өйнең яме – гөлләрдә 62

32



Әллә нигә сине юксынам...
Гүзәл Әдһәм

40



Әтиле чагымны сагынам...
Айгөл Зәкуанова-Нәбиуллина

60



Сюрпризлы коймаклар
Венера Арсланова тәкъдим итә



# ИСЛАМДА ХАТЫН-КЫЗ ХОКУКЛАРЫ НЫК САКЛАНА



Гөлнур САФИУЛЛИНА

**Быел Идел буе Болгары дәүләтенең ислам динен кабул итүенә 1100 ел була. Зур вакыйга! Бу бәйрәм Татарстанда гына түгел, Россия Президентының махсус карары нигезендә ил күләмендә билгеләп үтеләчәк. Безне берләштерү, халкыбызга, динебезгә карата уңай мөнәсәбәт тудыру юнәлешендә зур бер адым булыр дип көтелә ул. Дәүләт дине итеп ислам дине игълан ителү ул чакта халык язмышында зур бер яңа сәхифә ача. Шул исәптән – хатын-кызлар тормышында да. Сәясәт фәннәре докторы, профессор, Россия Ислам институты ректоры, Татарстан мөфтие урынбасары Рәфыйк Мөхәммәтша улы МӨХӘММӘТШИН белән ислам дине хатын-кызларыбызга алып килгән шул үзгәрешләр турында сөйләшәбез.**

**Бабаларыбыз ислам динен кабул иткәнгә 1100 ел тула. Динебез бу вакыт эчендә төрле чорлар кичергән: көчәеп, күтәрелеп киткән чаклары да булган, тыелган еллары да. Ислам динен саклап калуда, таратуда хатын-кызларның роле нинди булган?**

– Чыннан да, ислам динендә хатын-кызларның тоткан роле бик зур. Әгәр дә дәүләтчелек чорына – борынгырак чорга карасак, хатын-кызларның ролен ассызыклап күрсәтү, мөгаен, әле авыррактыр. Мөселман дәүләтенең ул чакта үз институты булган, дәүләт башында ир-атлар торган, ә хатын-кыз иң беренче чиратта гаиләнең төп терәге саналган. Совет хакимияте елларында ислам диненең ул институтлары юкка чыга, динне саклау мөмкинлеге бары тик гаиләдә генә кала. Һәм биредә инде хатын-кызның роле, һичшиксез, зур була. Мин моны үз мисалымда да әйтә алам. Әти-әни эштә, безне иң беренче чиратта Газизҗамал әбием тәрбияләде. Бу хакта һәрвакыт кабатлыйм: без – чын мөселманча тәрбияләнгән әби-бабайлар белән аралашкан соңгы буын. Дини традицияләр революциядән соң ук юкка чыкмаган – алтмышынчы елларга кадәр сакланып килгән әле. Аны безнең әбиләр, әниләр саклаган. Әби биш вакыт намазын калдырмады: ул намаз укыганда бүлдерергә ярамавын әти-әниләр кечкенәдән сеңдерде. Әбине тирән дини белемгә ия иде дип әйтә алмыйм, әмма әхлак кагыйдәләрен, ислам дине буенча үзеңне ничек тотарга кирәклеген аның аша белдек: ризыкка бисмилла әйтеп үрелергә, табын янынннан дога кылып китәргә… Итне гаиләдә иң өлкән кеше – әби бүлүе, беренче кисәкне әтигә бирүе – барысы да тәрбия дәресләре булган. Традицион гаилә кыйммәтләре буыннан-буынга шулай тапшырылган. Бу урында яулык мәсьәләсенә дә кагыласым килә. Бездә, бигрәк тә зыялылар арасында: «Татар хатын-кызы яулык бәйләмәгән, аның башында калфак кына булган», – дигән фикер яши. Минемчә, дөньяви фотосурәткә генә шулай төшкәннәр. Әнием гомер буе яулыгын салмады, әбиемне әйтәсе дә юк… Әйе, без гаиләдәге бу традицияләрне күреп, шул кысаларда тәрбияләндек. Шуңа күрә ислам диненә яңадан әйләнеп кайту җиңелрәк булгандыр.

Яңарыш чорында да динне саклауда, таратуда хатын-кызларыбызның роле бәяләп бетергесез. Үзенең алты баласын, оник һәм оникчыкларын гына түгел, йөзләгән шәкертләрен динле иткән Рәшидә абыстай Исхакыйны искә төшерик. Әлмира апа Әдиатуллинаны: ул – хатын-кызларның бик күп проблемаларын күтәреп, аларны сәяси яссылыкка алып чыккан абыстайларыбызның берсе. Урыннары җәннәттә булсын.

**Мәгълүм булганча, исламга кадәрге вакытларда хатыннар ирләрнең бер милке генә булып саналган. Ислам дине кабул итү хатын-кызларның тормышын ни дәрәҗәдә үзгәрткән?**

– Ислам кабул иткәнче хатын-кызларның язмышы хакында Согуд Гарәбстанында сакланган чыганаклар аша бик яхшы беләбез. Бернәрсәгә бернинди хокуклары да булмаган! Хокукый яктан карасак, ислам динендә исә мөмкинлекләре бик зур аларның. Беренчесе кәләшкә никах бүләгеннән – мәһәрдән башлана. Кайчандыр зур, мөһим бер институт булган ул. Җәлил хәзрәт очраклы рәвештә генә: «Мәһәрнең күләмен миллион сумга кадәр күтәрергә кирәк», – дими… Беренчедән, ул – хатын-кызны икътисадый яктан яклаучы бер инструмент. Мәһәргә аңа йорт, җир яки машина бүләк ителә икән, болар аның шәхси милке санала. Ире аңа: «Синең җирең (фатирың) бар, әйдә, без аны арендага бирик, шул акчага яшик», – дия алмый. Шәригать кануннары нигезендә, хатын-кыз мәһәрне тулысынча үзе файдаланырга тиеш. Теләсә генә ул аны гаиләсе өчен тота, әйткәнемчә, ире аны мәҗбүр итә алмый. Мәһәрнең күләме зур икән, баласы белән аерылган очракта да хатын-кыз бер тиенсез урамда калмый.

Икенчедән, шундый зур мәһәр биргәч, гаиләне саклауга ир-ат та башкача күзлектән карый. Кызганыч, татарларда мәһәр бер уенга гына әйләнеп калды хәзер: йөзек яисә бер муенса гына бирә кияү егете. Бу ислам кануннарын бозу түгел, әлбәттә. Шәригатьтә ачыктан-ачык әйтелгән: мөмкинлектән чыгып килешәсез, диелгән. Әмма ул инструмент буларак бүген үзенең ролен уйнамый. Шуңа күрә дә татар-мөселман яшьләре арасында аерылышулар бик күп. Мәһәрнең зурлыгы – гаилә кору мәсьәләсенә, гомумән, җитди карарга этәрер иде. Югыйсә бүгенге яшьләр мәчеткә барып кына никах укытып кайталар да, шәригать кануннарын бозмадык, дип, бергә яши башлыйлар. Ата-аналар күп вакыт аларның өйләнешкәнен дә, соңрак аерылышканын да белми кала. Мин үзем шуңа күрә дә мәчетләрдә никах укытуга каршы. Керде, укытты, сәдака бирде, чыгып китте. Беркем белми! Мулла өйгә килергә, мәҗлес каршында – әти-әниләр, туганнар янында укырга тиеш никахны… Исламда, шәригатьтә салынган инструментлар сакланса, гаиләләр күпкә ныграк булыр иде.

Әйе, ислам хатын-кызга икътисадый яктан зур мөмкинлекләр биргән. Дөрес, мирас бүлгәндә аның өлеше дүрттән бер генә булуны хокукларын чикләү дип мисал китерәләр анысы. Әмма биредә хатын-кызның хокукын чикләү юк. Гаиләне тоту, алып бару ир-атка йөкләнгән, хатын-кыз шәхсән үзе өчен генә җаваплы. Шуңа күрә милек реаль вазгыятьтән чыгып бүленә. Исламда барысы да тәгаен ачыклап язылган: мәһәрне кияү шунда ук түли алмаса, өлешләп түләп бетерергә тиешлеге дә; әгәр түләп бетермичә үлеп китсә, хатынына мәһәр иренең милкеннән түләнергә тиешлеге дә… Хатын-кызның хокуклары нык саклана исламда!

**Күпләр ислам дине куркытуга корылган дип саный...**

– Юк, болай әйтү дөрес түгел, ислам дине – ул инануга корылган. Аңарда курку-куркыту (страх) дигән категория бар, әлбәттә. Әмма ул иң беренче чиратта безнең әхлакый халәтебезне билгели. Ни өчен Аллаһы Тәгаләдән куркабыз? Аның тарафыннан иңдерелгән һәм без башкарырга тиешле эшләрне бозмыйбызмы дигән курку бу. Әмма дә ләкин ислам динендә икенче нәрсә дә бар: курку халәте – Аллаһы Тәгаләгә инануның түбәнге баскычы дип карала. Ә иң югары баскычы – Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәт.

Фото: Анна Арахамия





Курку бар һәм булырга да тиеш: ул безнең чикләрне күрсәтә. Әгәр кеше: «Мин бернәрсәдән дә курыкмыйм», – дип, ул чикләрне билгеләми икән, димәк, ул әхлакый һәм хокукый нормаларны бозарга әзер дигән сүз. Аллаһы Тәгаләдән куркуны гади курку белән чагыштырырга һич тә ярамый. Бу – иң беренче чиратта зур җаваплылык.

VIII гасырда яшәгән Рабиа аль-Адавия дигән бик мәшһүр, изге бер ханымның безнең заманнарга ук килеп ирешкән сүзләре бер. «Әгәр дә Аллаһы Тәгаләм мин сиңа бары тик оҗмахка керү өчен генә иманам икән, мине анда кертмә. Әгәр дә инде мин үземнең гөнаһларымны бары тик җәһәннәмгә керүдән куркып кына кылмыйм икән, син мине шунда керт», – ди ул. Аның бу әйткәннәре турыдан-туры куркуга кагыла.

**Ислам хатын-кызны җәмәгать намазын уку бурычыннан азат итә. Сез бүгенге мәчетләрне хатын-кызлардан башка күз алдына китерә аласызмы?**

– Мәчетләр элек-электән биш вакыт намаз уку урыны гына булмаган. Мәчет аша ир-атлар бөтен яңалыкны белгәннәр, мәхәллә мәсьәләләрен хәл итү өчен анда җыелганнар. Шуңа күрә мәчеттә социаль һәм мәгариф эшләре киң алып барылган. Бүген дә алар шул функцияләрне башкара. Җәмәгать намазларында хатын-кызларның булмавын зур проблема дип санамыйм. Менә безнең институт каршындагы «Әниләр» мәчетендә хатын-кызлар өчен кечкенә зал бар иде. Әмма җомга намазларына ир-атлар сыймый башлагач, без ул залны алардан алдык. Безгә җомга намазына хатын-кызлар йөрми хәзер. Җомга намазы ир-атлар өчен мәҗбүри: ул аны өч мәртәбә рәттән сәбәпсез калдырса, зур гөнаһ санала. Шәригать кануннары буенча хатын-кыз өстендә исә андый гөнаһ юк. Шуңа күрә үзебезнең мәхәллә ир-атларын җомга намазын укудан мәхрүм итә алмыйбыз.

Әмма бүгенге мәчетләрнең тормышын хатын-кызлардан башка күз алдына китерү авыр булыр иде. Татарстаныбыздагы мең ярым мәчетнең сигез йөзгә якынында бүгенге көндә курслар эшләп килә. Төрле мәгълүматларга караганда, ул курсларга 20 меңгә якын кеше йөри. Аларга белем бирүче ике меңгә якын укытучыларның 80 проценты, әлбәттә, хатын-кызлар. Алар күбесе югары профессиональ белемле, элек мәктәптә укытучы булып эшләгәннәр, аннары мәдрәсә тәмамлаганнар. Шушы 20 меңнән артык кешене хатын-кызларыбыз бүген намазга бастыра, дини белем бирә дип әйтергә була. Революциягә кадәр мөселман илләрендә хатын-кызлар мәчеткә йөрмәгән. Татарларда да шулай булган. Иске татар бистәсендә урнашкан, сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Казаков акчасына төзелгән таш мәчеткә беренче тапкыр кертәләр хатын-кызларны. Совет хакимияте урнашкач була бу. Мәрхүм Вәлиулла хәзрәт: «Шуңа ул мәчет җимерелгән», – дип шаярта иде.

**Исламда ир-ат белән хатын-кызның дәрәҗәләре бертигез диярлек. Ир-атның хокуклары ул гаилә башлыгы, төп мал табучы булганга күрә генә күбрәк. Ә гаиләдә малны күбрәк хатын-кыз тапса? Андый гаиләләр дә аз түгел бит хәзер.**

– Ул чыннан да хәзер зур проблемага әйләнде. Европада ир-ат белән хатын-кыз бөтен яктан да тигез булырга тиеш дигән принциптан чыгып эш итәләр. Әмма ислам тигезлек принцибына башкача якын килә. Әйе, алар тигез булырга тиеш – икесенең дә хокуклары чикләнергә тиеш түгел, әмма хатын-кызның физиологик мөмкинлекләренә дә, эмоциональ халәтенә дә карарга кирәк. Мәсәлән, татарларда мәетне җирләгәндә хатын-кызлар зиратка бармаган, өйдән генә озатып калган. Бу традиция шәһәрдә күптән бозылган, әмма авылларда ул әле дә бар. Әти-әни каберләрен күрәсем килә дисә дә, апамның зират капкасын ачып кергәне юк менә... Мәетне җирләгәндә хатын-кыздан бернинди ярдәм юк, ул елап кына басып тора ала. Зираттан еракка куеп, ислам аның рухи халәтен саклый.

Инде икътисадый якка килгәндә. Хәзер мөселман гаиләләрендә дә эшләмәгән хатын-кызлар юк дәрәҗәсендә, чөнки гаиләне тоту өчен ир-атның гына эш хакы җитми. Иреннән күбрәк мал тапкан хатын-кызлар да бар. Әлбәттә, ул традицион кыйммәтләрне җимерүгә китерә. Хатын-кызның гаиләдәге роле үзгәрә, ул ире белән дә башкачарак сөйләшә башлый. Нәтиҗәдә, аерылышулар да арта. «Балаларымны үзем дә туйдыра алам, нигә иргә дә хезмәтче булырга?» – дип уйлый хатын-кыз... Бу процессларны туктатып – хатын-кызны кире гаиләгә кайтарып булмый инде. Кызганыч, бүгенге глобальләшү чорында гаилә кыйммәтләре дә үзгәрә, аларны саклап калу шактый авыр. Әмма барысы да хатын-кызга – аны үзенең гаиләдәге урынын аңлауга бәйледер. Әгәр ул моңа хакым бар дип, беренче урынга чыгарга тырышса, бу балаларга начар тәэсир ясаячак. Тышкы яктан күренмәсә дә, баланың психологик халәте үзгәрәчәк, аны тәрбияләү проблемага әйләнәчәк. Чөнки балалар өчен, бигрәк тә ир балалар өчен әти авторитет булырга тиеш.

**Бүгенге көндә гаилә проблемаларын хәл итүдә ислам психологларының өлеше зурмы?**

– Әйдәгез, җавапны ерактанрак башлыйк әле. Беләсез инде, фән буларак психология Европада формалашкан. Бүген үзләрен «мөселман психологы» дип йөртүчеләрнең 90 проценты көнбатышта формалашкан шул психологиянең инструментарийларын ала һәм аларны мөселманнар арасында файдалана. Мин аны фиктив инструмент дип саныйм, чөнки ул әле чын мәгънәсендә мөселман психологиясе булып формалашмаган. Гомумән, психологиягә карата ислам динендә мөнәсәбәт шактый үзенчәлекле. «Фән буларак психология ислам диненә кирәкме?» дигән сорау да куябыз әле. Бездә әдәп, әхлак, тәсаувыф бар – шулар аша да кешене тәрбияләү мөмкин. Кызганыч, бүген бөтен дөньяны психологлар басты. Алар өч яки алты айлык курслар узалар да психологик ярдәм күрсәтергә алыналар. Чынлыкта, бу – бизнес. Аларның мөселман гаиләләрендә килеп чыккан проблемаларны хәл итә алуы шикле, чөнки, әйткәнемчә, көнбатыш психологик инструментларын файдаланалар. Әлеге психологлар биргән киңәшләр безнең гаиләләргә хас традицион кыйммәтләрне җимерә генә. Ир белән хатын арасында проблема бар икән, нигә моңа түзеп яшисең, аерыл, ди алар. Иреңнең әнисе белән

мөнәсәбәтләр начар икән, иреңнән аерым торуны таләп ит, диләр... Сезнең журналны укучыларга да әйтәсем килә, ниндидер соравыгыз бар икән, киңәш сорап, мәчетләргә, имамнарга мөрәҗәгать итә аласыз. Яхшы казыйларыбыз бар, мәсәлән, Колшәриф мәчетендәге Булат хәзрәт. Шәхсән үземнең мөселман психологларына бернинди ышанычым юк.

**? Пәйгамбәрләр заманында яшәгән хатын-кызларның кайсыларын бүгенгеләргә үрнәк итеп куярга теләр идегез? Безгә бүген аларда булган сыйфатларның кайсылары җитми?**

– Өч мисал китерер идем. Беренче – Аллаһыга тугрылыгын саклау өчен явыз иренә каршы чыгудан курыкмаган Асия. Ул – Фиргавеннең сөекле хатыны. Дан-шөһрәткә, сансыз байлыкка ия чибәр Нил патшабикәсе... Халык ирен илаһ дип белә һәм аңа табына. Теләсә, Асия дә аларны үзенә гыйбадәт кылырга мәҗбүр итә алыр иде... Муса пәйгамбәр тугач, Фиргавеннең аны үтерүеннән куркып, әнисе баланы бишеккә салып суга агыза. Асия исә аны золым иреннән качырып тәрбияләп үстерә. Иренең мәрхәмәтсезлеге өчен бер хатын да Аллаһ каршында җавап бирмәячәк. Залим, әчкече ирләр бүген дә бар. Андый гаиләдә көн итүче хатын-кызлар өчен Асия бар яктан да үрнәк була ала – ирен сылтау итеп диннән баш тармый ул.

Икенче мисал – Мөхәммәд пәйгамбәрнең беренче хатыны Хәдичә. Пәйгамбәребезгә Коръән иңдерелә башлагач, ул иң элек Хәдичә белән киңәшләшә. Хатыны аңа ияреп иң беренче намаз кылучы, Коръәнне беренче тыңлаучы була. Ул – бай гаиләдән, икътисадый яктан мөмкинлекләре дә зуррак: үзенең бөтен милкен Аллаһы Тәгалә юлына тота. Пәйгамбәребезне кешеләр кире каккач та, ул аңа ышана, ялганда гаепләгәч – хаклыгын раслый, ярдәмсез калгач – ярдәм итә... Тугрылык үрнәге!

Нинди булмаска кирәк дигәнгә дә мисал бар. Өченчесе – шунысы. Нух пәйгамбәрне барыбыз да яхшы белә. Аның хатыны ире әйткән бер сүзгә дә ышанмаган, аны санга сукмаган, ул кушканнарга инанмаган. Ире хакында кешеләргә: «Ул акылдан язган», – дип сөйләгән, аны яманлаган. Моның ахыры нәрсә белән беткәнен дә беләсез...

**? Ислам күзлегеннән караганда, яхшы хатын-кыз нинди хатын-кыз ул?**

– Ул – иң беренче чиратта гаилә кыйммәтләрен дөрес аңлаган, гаиләнең ныклыгын, андагы рухи-әхлакый атмосфераны саклаган, балаларын дөрес тәрбияләгән хатын-кыз. Исламда гаилә – иң мөһим урында. Гаиләдә тәртип булмаса, җәмгыятьтә дә проблемалар арта. Бүгенге глобальләшү чорында гаилә кыйммәтләренә караш, әйткәнемчә, бик үзгәрде. Европада әнә хатын-кыз 40 яшь тулмыйча кияүгә чыгарга да җыенмый. «Миңа башта карьера ясарга, акча эшләргә кирәк», – ди ул. Балалар тугач та, кабат тизрәк эшкә чыгарга ашыга – сабыйларын ятлар карый. Мондый шартларда анадан балага күчәргә тиешле гореф-гадәтләр, йолалар, дин, билгеле инде, икенче планда кала. Кызганыч, безнекеләр дә хәзер алардан үрнәк ала...

# РИВАЯТЬЛӘР

Халык болгарларның ислам дине кабул итүен сәхабәләр исеме белән бәйли. Риваятьләр бәян итүенчә, сәхабәләр Болгарга Айдар хан вакытында килә: «Болгарның беренче ханы Туки яки Туфи атлы була. Ул һиҗринең 9 нчы елында (милади буенча 630) вафат була. Шул елда тәхеткә улы Айдар утыра. Аның илле еллык идарәсе вакытында Болгар халкы ислам динен кабул итә». Риваятьнең күптөрле версияләре һәм вариантлары бар. Иң борынгы риваять әл-Гарнати сәяхәтнамәсендә сакланган. Болгарга Бохарадан мөселман сәүдәгәре килгән. Ул медицинаны яхшы белгән. Шулчак патша һәм аның хатыны бик каты авырып китә. Мөселман сәүдәгәре аларга: «Әгәр дә мин сезне дәваласам, минем динне кабул итәрсезме?» – дигән. Ул аларны дәвалаган, һәм болгарлар шул вакыттан ислам динен тота башлый. Әбу Хәмид әл-Гарнати бу риваятьне XII гасыр болгар тарихчысы Якуб бине Ногманның «Болгар тарихы» дигән хезмәтеннән ала.

XVI гасырга караган «Тәварихы Болгария» әсәрендә риваятьнең тагын бер варианты китерелә. Ул әл-Гарнати сәяхәтнамәсендәге вариантка бик охшаш: «Тарих тукыз сәнәсендә хут елында вә йолдызында рамазан мөкәрәмнең тугызынчы көнендә, ул заманда Айдар хан ирде, хәзрәте Сәйеде салләллаһи-галәйһиссәлам өч сәхабә җибәрде тәгълиме ислам вә дин өчен Болгарә: берсе – Габдерахман бине Зөбәер, икенчесе – Зөбәер бине Җәгъдә, өченчесе – Тәлха бине Госман». Бу өч сәхабә үзләрен табиблар дип игълан итеп, күп кешеләрне дәвалый. Айдар ханның кызы Туйбикә дә авырып китә. Сәхабәләр кызны ничек дәваларга икәнен әйтә. Алар бер таякны кара савытына куеп дога кыла. Таяк яфрак ярып утырган каен агачына әйләнә. Кыз мунчада яңа каен себеркесе белән чапканнан соң терелә. Бу могҗизаны күргән халык ислам динен кабул итә. Сәхабәләр Болгарда өч ел яши. Халыкны дингә өйрәтә, мәчет салдыра, мәдрәсә ача, Коръән өйрәтә. Өч елдан соң ике сәхабә кире Мәдинәгә китә. Хәзрәте Зөбәер бине Җәгъдә Болгарда кала, хан кызы Туйбикәгә өйләнә, егерме биш ел Болгарда яшәп вафат була.

«Сөләйман хуҗа» дигән риваятьтә Мөхәммәд пәйгамбәр исән чакта Мәккә шәһәреннән бер зур галим кешенең Идел буена дин өйрәтер өчен җибәрелүе турында сөйләнә. Бу кеше Сөләйман исемле була. Сөләйман Хуҗа илгә чыгып, зур мәдрәсәләр ачып, бик зур муллалар әзерләгән. Алар, авылларга таралып, илне агарткан.

Икенче риваятьтә Болгар халкының ислам дине кабул итүенә сәбәп итеп ханның төш күрү мотивы күрсәтелә. Бу турыда әл-Мәгъсуди язып калдырган: «Болгар ханы 310 нчы елда (милади белән 921–922) төш күргәннән соң ислам динен кабул итә». Монда Болгарга Ибне Фадлан килүе, илнең рәсми рәвештә ислам дине кабул итүе турында әйтелә. Бу сюжетка корылган риваять тә бар. Габдешәмс дигән кеше төшендә Хозер галәйһиссәламне күргәннән соң Аллаһы Тәгаләгә инана башлый.

Илсөяр ЗАКИРОВА,
филология фәннәре докторы.

# «МИН ЭШЛӘГӘЧ, СҮЗ ТИДЕРЕРЛЕК БУЛМАСЫН...»

Үземне уңышлы кеше дип саныйм. Әмма бу уңыш – җай килү очрагы гына түгел. **МИҢА КАЛСА, КЕШЕНЕҢ КИЛӘЧӘГЕН АНЫҢ ЭЧКЕ ХАЛӘТЕ, ШӘХСИ СЫЙФАТЛАРЫ БИЛГЕЛИ.** Сабыр холыклы булу, кимчелекләреңне белеп, аларны бетерү өстендә эшләү, үзеңне чикли белү кебек сыйфатлар, минемчә, уңышка ирешүдә мөһим роль уйныйлар...

Кешегә хакимият гомерлеккә бирелми, ул вакытлыча гына. **ИҢ МӨҺИМЕ: КЕШЕ БУЛЫП КАЛА БЕЛЕРГӘ.**

Һәр сәясәтче өчен эмоцияләреңне яшерү, үз-үзеңне тота белү – алыштыргысыз сыйфатлар. **САБЫР ИТӘ БЕЛҮ ҺӘМ ТЫЙНАКЛЫК ЭШТӘ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, ГАИЛӘДӘ ДӘ КИРӘК.**

Әгәр дә нәрсә белән булса да килешмисең икән, куелган максатка ирешү өчен үз юлыңны күрсәт. **ТӘНКЫЙТЬЛИСЕҢ ИКӘН – ТӘКЪДИМ ИТ!**

**МӘДӘНИЯТ, ТЕЛ, ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР, ТРАДИЦИЯЛӘР ИҢ ЯХШЫ САКЛАНГАН УРЫН – АВЫЛ.**

Машинада йөргәндә кумыйм, бик сак кына, рәхәтләнеп йөрим. **МАШИНАЛАР – МИНЕМ ХОББИ.** Беренче белемем буенча тәгәрмәчле машина һәм тракторлар буенча техник-технологмын. Машиналарга мәхәббәтем әлегә кадәр саклана. «Тимер атлар»ны юарга, чистартырга, ремонтларга, гомумән, техника янында кайнашырга яратам. Гараждан ял итеп чыгам. Иске маркалы машиналар яратам. «ГАЗ-21 Волга» автоклубын да шуларны саклап калу максатыннан оештырдык.

Нәтиҗәле хакимият формуласы, абсолют бәхет формуласы кебек үк, юктыр ул. Бөтен кешенең дә күңелен күреп бетерү мөмкин түгел. Барыбер тәнкыйть итәр әйбер табыла. **ШУҢА КҮРӘ ДӘ КЕШЕЛӘРГӘ КАРАТА ГАДЕЛ БУЛУ МӨҺИМ.** Халык үз вәкаләтләренең бер өлешен сиңа тапшырып, депутат итеп сайлый. Вакыт үткәч, уңышлы хәл ителмәгән һәм кулдан ычкындырылган мөмкинлекләр өчен хакимиятне тәнкыйть итүчеләр янәшәсендә булу ихтималың бар.

**ЛЕКЦИЯ УКЫП КЫНА ПАТРИОТИЗМ ТӘРБИЯЛӘП БУЛМЫЙ. УЛ ГАИЛӘДӘ ТУА.** Иң яхшы традицияләрнең берсе – «Үлемсез полк». Без анда гаиләбез белән катнашабыз. Гаиләләр тарихы Ватан тарихына барып тоташа ул.

Мәктәптә укыганда милләтем буенча татар булган бердәнбер бала идем. Җитмәсә, әти фронттан алып кайткан үткен пәкесе белән дүртенче сыйныфка кадәр чәчемне кырып ала иде. Шуңа күрә классташларым мине «Татарин» дип йөртте. Кушаматым бераз үпкәләтә иде. **ӘММА ЕЛЛАР ҮТКӘЧ, ТАТАР БУЛУЫМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНДЫМ ГЫНА.**

Гаилә – җәмгыятьнең нигезе. Шушы сүзгә барысы да сыйган... Гаиләләр нык, тату, бердәм, сәламәт икән, җәмгыять тә төзек. **ГАИЛӘ – ТРАДИЦИЯЛӘР БЕЛӘН ЯШӘРГӘ ТИЕШЛЕ ДӘҮЛӘТ.**

Әти, әнинең кадерен белеп, аның белән һәрвакыт киңәшеп яшәде. Ул әнигә ягымлы итеп «карчык» дип эндәшә иде. Берзаман бу сүз минем дә телгә керде бит. Ниндидер командировкадан йөреп кайткач, Луизага «карчык» дип эндәштем. Башта аптырап калды. Аннан соң бу сүзнең хикмәтен аңлады. **ТОРМЫШ ИПТӘШЕҢӘ БОЛАЙ ЭНДӘШҮ КҮП МӘГЪНӘНЕ АҢЛАТА... АНЫ ИКӘҮ ГЕНӘ БЕЛӘ.**

Безнең гаиләдә хатыным әти культы булдырды. «Әтиегез нәрсә әйтер...» – ди ул һәрвакыт. Моның өчен аңа бик рәхмәтлемен. **ТАТАР ГАИЛӘСЕНДӘ ӨЛКӘННӘРГӘ ХӨРМӘТ – ТРАДИЦИЯ.**

**ҮЗЕМНЕ ДЕМОКРАТ ҖИТӘКЧЕ ДИП САНЫЙМ, ЧӨНКИ ГАИЛӘДӘ БАШКАЛАРНЫҢ ФИКЕРЕНӘ ИГЪТИБАРЛЫ БУЛУ, ТЫҢЛАУ, ИШЕТҮ ҺӘМ ШУННАН СОҢ ГЫНА КАРАР КАБУЛ ИТҮ ҮРНӘГЕНДӘ ТӘРБИЯЛӘНДЕМ.** Әти нәрсә эшләргә икәнен үзе хәл итә иде, әни белән дә киңәшләшкәннәрдер, әмма вакытын туры китереп, ул безне, шулай-шулай итәчәкбез, дип кисәтә иде.

**ҮЗ ФИКЕРЕҢНЕ ЯКЛАУ ӨЧЕН ҺӘР МӘСЬӘЛӘНЕ ТӨБЕНӘ ТӨШЕП ӨЙРӘНҮ МӨҺИМ.**

Татарстан
Дәүләт Советы Рәисе
Фәрит МӨХӘММӘТШИНның
тормыш кагыйдәләре







Хакимият – үз уйларыңны гамәлгә ашыру мөмкинлеге. **ТИК МИН БЕРКАЙЧАН ДА, БЕРНИНДИ ОЧРАКТА ДА ХАКИМИЯТНЕ УҢАЙЛЫЛЫККА ИРЕШҮ ДИП КАРАМАДЫМ.**

Һәр сессиягә ныклап әзерләнәм. Бөтен җитди сорауларны комитетлар рәисләре, хокук идарәсе белән «сүтеп җыябыз». **ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ ҺӘР УТЫРЫШЫ АЛЫП БАРУЧЫ ГЫНА ТҮГЕЛ, Ә ҺӘР КАТНАШУЧЫ ӨЧЕН ДӘ ИМТИХАН. Ә ИМТИХАНГА ӘЗЕРЛӘНМИ БАРМЫЙЛАР.**

Тормыш тәҗрибәмнән чыгып шуны әйтергә телим: **КАЙДА ГЫНА ЯШӘСӘК ТӘ, НИНДИ ГЕНӘ ТЕЛЛӘРДӘ СӨЙЛӘШСӘК ТӘ, БЕЗНЕҢ ТАМЫРЛАРДА ТАТАР КАНЫ АГА, ГЕННАРДА ХӘТЕР САКЛАНА.**

**МИН ҺӘРВАКЫТ ХАЛЫК АРАСЫНДА БУЛДЫМ.** Бервакытта да бер аудиториядән дә курыкмадым. Нинди генә каршы фикерле, тәнкыйтьчел аудитория булса да, курыкмый чыктым.

**ӘГӘР СИН САБЫРСЫЗ ҺӘМ ХАЛЫКНЫ ЯРАТМЫЙСЫҢ ИКӘН, УЛ БИК ТИЗ СИҢА КАРШЫ ЧЫГАЧАК.**

**МАКСАТ – БЕР, АҢА ИРЕШҮ ЮЛЛАРЫ ГЫНА ТӨРЛЕ.** Коллегалар арасында, мин бу юлда шикләнәм, менә болай итеп карап карыйк әле, дип әйтүче кеше бар икән, ул – уйлый белүче, кайгыртучан депутат. Андыйларны бик хөрмәт итәм.

**КЕШЕНЕҢ ЭЧКЕ ДӨНЬЯСЫ БЕЛӘН КЫЛГАН ЭШГАМӘЛЛӘРЕ ТӘҢГӘЛ КИЛЕРГӘ ТИЕШ.** Үзең бертөрле яшәп, икенче төрле сөйләп йөреп уңышка ирешеп булмый ул.

**МИН ЭШЛӘГӘЧ, СҮЗ ТИДЕРЕРЛЕК БУЛМАСЫН.**

Төп вазыйфам ничек кенә җитди һәм авыр булмасын, иҗтимагый эшчәнлегемдә беркайчан да «туй генералы» булырга килешмәдем. **ӘГӘР ДӘ НӘРСӘНЕ БУЛСА ДА ҖИТӘКЛӘРГӘ АЛЫНАСЫҢ ИКӘН, РӘХИМ ИТЕП ВӘКАЛӘТЛӘРЕҢӘ ТУРЫ КИТЕРЕП ЭШЛӘ.**

**ЯҢА КЕШЕЛӘР БЕЛӘН АВЫРРАК ДУСЛАШАМ.** Бу мәсьәләгә саграк карыйм. Дәрәҗәле эштә эшләсәң, «дуслар» күп була инде ул. Эштән китәргә туры килсә, чын дуслар гына кала.

Битарафлыкны җенем сөйми. Хәтта сатлык кешеләрне дә, гафу итмәсәң дә, аңларга тырышасың, бу адымга барырга ниндидер сәбәп булгандыр дип уйлыйсың. Кыйбласыз кешеләрне аңламыйм. Туфан абый Миңнуллин әйтә иде, Фәрит, моңарда өмет юк, дия иде. **КЕШЕНЕҢ ТОРМЫШТА ҮЗ ФИКЕРЕ, КАРАШЫ БУЛЫРГА ТИЕШ.** Миңа яшәүдән мәгънә, ямь таба белгәннәр ошый.

**ТОРМЫШНЫҢ КАДЕРЕН, АНЫҢ ФӘЛСӘФӘСЕН АЗРАК ТӘҖРИБӘ ҖЫЙГАЧ КЫНА АҢЛЫЙ БАШЛЫЙСЫҢ.** Яшь чакта көндәлек тормыш белән яшисең, төрле вак-төякләргә куанасың, ә тирәнрәк уйласаң, тормыш һәрбер көннән җыела. Бераз яшәп, тәҗрибә туплагач, тормышның яртысы үткәч кенә кеше яшәү яме, аның мәгънәсе, фәлсәфәсе турында уйлана башлыйдыр, мөгаен.

**МИНЕМ ӨЧЕН ЛУИЗАДАН ДА КАДЕРЛЕРӘК ХАТЫН-КЫЗ ЮК.** Тормышта башкарган эшләремнең күпчелеге өчен аңа бурычлымын. Гаиләгә еш кына вакыт таба алмавым өчен үкенәм.

**НӘСЕЛ ТӨШЕНЧӘСЕ АЕРУЧА ЗУР КЫЙММӘТКӘ ИЯ.** Элек гаиләдә бала-чага күп була иде. Бер нәселдән булган гаиләләр бер-берсенә ярдәм итеп, ихтирамлы мөнәсәбәттә яшәде.

**ЯКЫН ДУСЛАРНЫ, ХЕЗМӘТТӘШЛӘРЕҢНЕ САЙЛЫЙ АЛСАҢ, ХАТА-ЯЛГЫШ ЯСАМАСАҢ, ТОРМЫШ ЮЛЫН ҮТҮЕ ҖИҢЕЛРӘК, ЫШАНЫЧЛЫРАК БУЛА.** Гаиләдә яхшы тәрбия алып, дусларның да яхшыларын сайлап алган кешеләр – иң бәхетлеләр.

Хәзер уйлап утырам да: миңа нинди язмыш эләккән бит! Бер вазыйфаны, бер карьера баскычын калдырмаганмын: токарьдан башлап шәһәр мэры, министр, хөкүмәт рәисе, парламент спикеры. **ЭШНЕ ИШЕТЕП КЕНӘ БЕЛҮ ТҮГЕЛ, Ә ТӨПТӘН ҖИГЕЛЕП ТАРТУ – КИЛӘЧӘКТӘ ҮЗЕҢӘ ЫШАНЫП ЭШЛӘРГӘ ЯРДӘМ ИТӘ.** Бик бәхетле кеше мин, Татарстан Республикасында зур тормыш мәктәбен үттем.

**МӨХӘММӘТШИННАР НӘСЕЛЕНДӘ ШУЛАЙ КАБУЛ ИТЕЛГӘН ИНДЕ: СИҢА ЫШАНЫЧ КҮРСӘТКӘННӘР ИКӘН, ҮЛ, ӘММА УЛ ЫШАНЫЧНЫ АКЛА!** Бу принциптан тайпылмаска тырышып яшәдем.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА әзерләде.

**РЕДАКЦИЯДӘН: Фәрит Хәйруллович, журнал укучыларыбыз исеменнән Сезне юбилеегыз белән котлыйбыз! Сез – зирәк җитәкче, Татарстан парламентының алыштыргысыз спикеры! Республика халкын кайгыртуны максат итеп куйган күпьеллык эшчәнлегегез зур хөрмәткә лаек. Энергиягез, тормышны яратуыгыз, бай тәҗрибәгез, үзегезгә хыянәт итмичә яшәвегез – әйләнә-тирәдәгеләргә үрнәк.**

**MEDEL**
**МНОГОПРОФИЛЬНАЯ КЛИНИКА**

**МЕДИЦИНАДАГЫ ИННОВАЦИЯ**

# Аяклардагы варикозны дәвалауда ЭВЛК куллану буенча 14 еллык тәҗрибә





Лицензия ЛО-16-01-007039 от 19 июля 2018 г.

МАХСУС ТӘКЪДИМ

МЕДЕЛ Клиникасының

*17 еллыгы уңаеннан*

Аяк варикозын дәвалау 8500 меңнән алып

**«Варикозга – юк» программасы**

- ике аякның да артерия һәм тамырларына УЗИ
- флеболог консультациясе

**Бәясе 1450 сум***

МЕДЕЛ клиникасында аяклардагы варикозны дәвалаганнан соң компрессион трикотаж комплекты БҮЛӘККӘ!

*2022 елның 30 июненә кадәр дәвам итә.

## 1 ЭВЛК методы белән аяклардагы варикозны лазер ярдәмендә дәвалау буенча 14 еллык тәҗрибә.

МЕДЕЛ Клиникасы 2009 елдан бирле аяклардагы варикозны инновацион ЭВЛК методы буенча дәвалауда махсуслаша. Бу юнәлештә ул – Россиянең иң тәҗрибәле учреждениеләренең берсе.

Дәвалау нәтиҗәле һәм авыртусыз булсын өчен тәҗрибәле хирург-флеболог тирәнтен диагностика уздыра: дәвалау таләп ителгән бер генә тамырлы урынны да калдырмыйча, пациентның аягын җен-текләп тикшерә һәм иң кулай методлар комбинациясен сайлый. Дәвалау һәрвакыт ЭВЛК методы белән генә алып барылмый: кайбер очракларда склеротерапия белән дә чикләнеп була. Катлаулырак очрак булганда берничә методны берләштерү таләп ителә.

Дәвалау стерильләштерелгән оперция бүлмәсендә уза. Пациентның хәле монитор һәм ультратавыш аппараты ярдәмендә контрольдә тотыла. Процедура берьюлы ике югары категорияле хирург һәм аларның ассистентлары ярдәмендә уздырыла.

## 2 ЭВЛК-МЕДЕЛ дәвалау методикасы – МЕДЕЛ Клиникасы уйлап тапкан ысул. 2514337 нче номерлы патент бу методның уникальлеген дәлилли. Ул Казанда бары тик МЕДЕЛ Клиникасында гына уңышлы кулланыла.

Дәвалауда яхшы нәтиҗәгә ирешү өчен күппрофильле МЕДЕЛ Клиникасы белгечләре озак еллар дәвамында гыйльми тикшеренүләр үткәрде. Камилләштерелгән ЭВЛК-МЕДЕЛ дәвалау методикасы – шуның нәтиҗәсе.

Аның ярдәмендә дәвалаудан соң тернәкләнү процессы да тизрәк уза, тискәре йогынты, тире гематомалары барлыкка килү ихтималы да кими. Варикозны дәвалауда иң мөһиме – шунысы.


РОССИЙСКАЯ ФЕДЕРАЦИЯ

ПАТЕНТ

НА ИЗОБРЕТЕНИЕ

№ 2514337

СПОСОБ ЛЕЧЕНИЯ ВАРИКОЗНОЙ БОЛЕЗНИ НИЖНИХ КОНЕЧНОСТЕЙ С ИСПОЛЬЗОВАНИЕМ ЭНДОВАЗАЛЬНОЙ ЛАЗЕРНОЙ КОАГУЛЯЦИИ ВЕН

**Уйлап табу өчен табиблар коллективы 2514337 нче номерлы патент алды.**

## 3 14 еллык зур тәҗрибә варикозны тиз, ышанычлы һәм гарантияле дәваларга мөмкинлек бирә.

Варикоз аркасында операция кирәксә, яңа аз инвазияле ЭВЛК методикасы һәм МЕДЕЛ Клиникасының катнаш методлар кулланып эшләве дәвалауны тиз һәм сакчыл уздыру мөмкинлеге бирә. Безнең пациентлар операциядән соң басып шул көнне үк үз аяклары белән кайтып китәләр.

**Күппрофильле МЕДЕЛ Клиникасында кулланыла торган методлар барысы да: • аз җәрәхәтле • госпитализация таләп итми • 30–40 минут эчендә төгәлләнә • төзәлү вакытлары кыска • җөй һәм эзләр калдырмый.**




**МЕДЕЛ – 2018 елда «Комсомольская правда» газетасы уздырган онлайн тавыш бирү нәтиҗәсе буенча Казанның иң яхшы күпрофильле Клиникасы**

**Аяклардагы варикозны теләсә кайсы стадиядә дәвалау**

- **МЕДЕЛ** – Россиядә 2009 елда ук иң беренчеләрдән булып ЭВЛК лазер белән аяклардагы варикозны дәвалауны куллана башлаган учреждениеләрнең берсе.
- Варикозны дәвалауда **зур тәҗрибә**: 17 ел дәвамында 3000 нән артык операция ясалган.
- ЭВЛК-МЕДЕЛ ярдәмендә аяклардагы варикозны камилләштереп дәвалауда **Патент**.

**МЕДЕЛ – Сез сайлаган ышанычлы юл**




**MEDEL**
**КҮППРОФИЛЬЛЕ КЛИНИКА**
**Казан**

**medel.ru** (843) 528-04-51



КАРШЫЛЫКЛАРЫ БАР. БЕЛГЕЧ БЕЛӘН КИҢӘШЛӘШҮ КИРӘК

РЕКЛАМА



# «ӘНКӘЙ, МИНЕ БИК САГЫНСАҢ...»



Алсу
ШАКИРОВА

**– Мәйсәрә, Зөлхәбирә белән өчәүләшеп каршыда яшәүче Якуб абыйның хәлен белешергә уйлаштык. Яралы солдат кайткан йортка бөтен авыл халкы йөри – гадәте шундый. Без дә бурычыбызны үтәргә, хәл-әхвәл сорашырга кереп киттек. Якуб абый сугышка кадәр авыл советы рәисе иде. Яраланып кайткач яңадан шул эшенә керәште.**
**– О-о-о! Нишләп йөрисез монда, кызлар? – дип гаҗәпләнә Якуб абыйлары.**
**– Нишләп алай дисең, Якуб абый, кая булыйк без тагын? – дип аптырый кызлар сорауга сорау белән.**
**– Ат хәтле гәүдәгез белән сугышка бармыйча нишләп ятасыз?! – дип шелтәли солдат күршеләрен.**
**Өч көн дигәндә авылга өч повестка килеп тә төшә...**

### *Хәйләсез татар*

– Хәзер мин бернәрсә хәтерләмим. Бу яшьтә хәтерсез калсам, нишләргә кирәк, дим. Тукта, әни, алышыну түгел әле бу синең, дип юата инде Фәнис улым.

Балтач районы Түбән Кенә авылында гомер итүче 97 яшьлек сугыш ветераны Тәскирә апа ГАЛИМУЛЛИНА шулай хәтер бетүдән зарланып алды. Тормыш йомгагының урыны белән буталып беткән җепләрен сүтә-сүтә, берсенә берсен төенләп булса да ялгый-ялгый сөйләшеп утырдык. Шәһәр исемнәрен ачык кына хәтерләмәсә дә, эзлеклелеге югалса да, сугыш хатирәләрен еллар да җуйдыра алмый икән.

...Тәскирә апаның әнисе Һадия апа дүрт баланы бер ялгызы тәрбияли. Колхоз рәисе булып эшләгән ирен нахакка «халык дошманы» дип гаепләп, төрмәгә утырталар. Тәскирә – әнисенең иң олы кызы, таянычы. Дүрт сыйныф укыганнан соң, класс җитәкчесе Салих абый кызның укуын дәвам итәр өчен аны Арчага үзе алып барырга уйлый. «Бу кыздан берәр нәрсә чыгар, алыгыз, дип әйтермен», – ди укытучы. Ләкин биографиясендәге «кара тап» аркасында кызны кире боралар. Инде алдылар, булды, укырга керде дигәч бит...

Ә этисеннән бер хат килгәнен генә хәтерли Тәскирә апа. Җылы киемнәр алып килүләрен сорый ул. Ләкин әнисе дә, бабасы да бара алмый калалар. 1936 елда этисе Гомәр абыйның Свияжск төрмәсендә үлеп калуы ачыклана...

Укырга керә алмаган оныгын эшкә урнаштыру нияте белән бабасы Казанга алып китә. Ләкин 14 яше дә тулмаган кызны бер җиргә дә эшкә алмыйлар. «Әртилләр үзебездә дә барсәнә», – дип, шәһәргә кул селти бабасы. Кайтып, мех эшкәртү артеленә урнаша, кичке мәктәпкә дә укырга керә әле Тәскирә апа. Бөек Ватан сугышы башлану белән фабрика тормышы да үзгәрә, хезмәткәрләрне чиратлап окоп казырга җибәрә башлыйлар. Тәскирә апа шулай итеп Чуашиягә барып эләгә. Ике ел буе окоп казып интеккәндә киләчәктә тагын никадәр җирләр казыйсын белгән булса, үзе дә ышанмас иде...

Әле генә окоп казудан әйләнеп кайткан олы кызын ничек итеп фронтка җибәрсен Һадия апа?! Якуб абыйга тезләнеп ялына ана:

– Зинһар, җибәрмә кызымны, Якуб абый. Эшкә ярый башлагач кына... Бернинди белгеч тә, врач та түгел бит ул! – ди. Барыбер алып кала алмый...

Һадия апа фермада эшләгәч, китәсе кызларны җыеп, ат белән Шәмәрдәнгә үзе илтә. Кызына биреп җибәрергә бернәрсәсе дә булмый тол хатынның. Бөтен ярдәм – туганнары Мәсрурә апа юлга дип 12 йомырка белән бер кием оек. Аерылышу хәсрәтеннән озак елашалар әни белән кыз...

Шәмәрдәннән аларны Кукмарага алып китәләр. Анда русча белү-белмәүләрен тикшереп карыйлар, сөйләштерергә тырышалар. Русча белмәсәң, фронтка җибәрмиләр икән дигән сүзләр дә чыгып ала кызлар арасында.

– Без, авыл баласы, «низнаю», «дай»дан башканы белмибез дә. Аңа карап тормадылар, туры киләләр дип, барыбер алдылар. Казанга баргач, завод янында землянкаларга урнаштык. Сүзләрне башкалардан әйбәтрәк отканмындыр, күрәсең, русча да сөйләшә башладым. Шуклык та бар иде. «Хитрая татарка! Она, наверное, и в деревне уже знала по-русски», – дип әйттеләр әле. Имеш, белмим дип, алдарга гына тырышканмын.

Аннары кызларны юындырып, икенче киемнәр бирәләр, чәчләрен кисәләр. Тәскирә апаның да ике якка үреп салган калын озын толымнарын колактан түбән кисеп кулына тоттыралар. «Өйгә җибәрә торган әйберләрегез булса, танышларыгыз аркылы биреп җибәрегез», – диләр кызларга. Казандагы бер агай-эне тиешле туганнары



■ «Шушы яшемдә билемә буам солдат каешын...» 1943 ел. Сугышка китәр алдыннан.

Фотолар: Балтач районының Карадуган «Себер тракты тарихы» музее архивыннан.

Фото: Анна Арахамия

# Ул түгәрәк кара ипиләрнең тәме һич хәтердән чыга торган булмады.

аркылы күлмәк-ыштаны белән бергә шул ике толымын да салып җибәрә Тәскирә апа. Әнисе аларны бүлмә тактасына элеп куйган булган, әмма беркөнне ул толымнар әллә кая юкка чыккан. Газиз баласының кадерләп үстереп тә башыннан кисеп алган шул чәчләрен әнисе елый-елый эзләсә дә таба алмый.

Бераздан укулар, өйрәнүләр башлана. Казанда телефон, телеграф белән эшләү нечкәлекләренә төшенәләр, «Морзе» әлифбасын ятлыйлар. Горький шәһәренең бомбага тотылу хәбәре килгәч, кызларның укулары тагын да катлаулана. Карабин тоттырып атарга өйрәтәләр һәм «Ворошиловский стрелок» нормаларын тапшыргач, частька туплыйлар. «Фронтка!» дигән боерык та озак көттерми...

### «Казан чабаталары»

Украина якларына алып китәләр кызларны. Әле фронт сызыгына барып җиткәнче үк утырган машиналарын Коростень шәһәрендә бомбага тоталар. Берничә тапкыр машинадан сикереп, төрле якка сибелергә туры килә аларга. Исән калганнардан торган частьны таркатып, Сарны шәһәрендә яңасын туплыйлар.

– Сугышка киткәннән бирле кая гына барып урнашсак та, иң беренче эш итеп землянка казырга тотынабыз. Урман булса – агач кисәбез. Ашар өчен дә, аппаратлар урнаштырырга да, йокларга да, идарә пункты өчен дә землянкалар казыдык. Бомбага тотулар булмаганда чокырлар, маскировкалар казый идек. Инде урнаштык дигәндә генә яңа приказ килә дә, яңа җирдә тагын шулай ук урнашабыз. Күпме җир казылды...

Кайсы җирдә тупләнсәләр дә, бомба төшүдән өзелеп беткән линияләрне рәткә китерү, ялгау да – элемтәчеләр эше. Егетләр генә түгел, кызлар да ут эчендә 80 килограммлы катушкаларны үзләре артыннан өстерәп, шуышып, шул линияләрне ялгый.

Тәскирә апаны бомбежка вакытларында укыган догалары саклады микән, сугышта бер тапкыр да яраланмый ул. Ә менә дусты – Әгерже кызы Лидия Кузнецова бомба астында калып вафат була. Шунда землянкада «җирләнеп» кала, кузгатырга рөхсәт итмиләр дә. Утыз елдан соң шул якларга барырга туры килә Тәскирә апага. Землянкада калган дустының җәсәден туганнар каберлегенә күчергәнен шунда белеп кайта. Бик яхшы тәрбиядә булган каберлекләрне күреп күңеле шатлана.

– Нинди шартларда эшләргә туры килсә дә, элемтәне өзмәскә тырыштык. Бу – безнең төп бурыч. Бомбага тотылмаганда, буш вакытыбызны да укуга юнәлтә идек. Яңа станциягә килеп төшүгә, аны якыннан өйрәнәбез. Аларның кайберсе бик зур була иде. Кайда нәрсә урнашкан, нәрсәне ничек ялгыйсын аңларга, яңадан төшенергә кирәк. Әле дә хәтерлим, бер зур елга янындагы станциягә килеп төпләндек. Шул елгадан салмак кына мәетләр ага... Ә иң курыкканыбыз – дошман кулына эләгү. «Фашистларга эләксәгез, куркасы юк, алар шундук атып үтерә. Ә менә бандерчыларга эләгүдән Ходай үзе сакласын, җәзалап үтерәләр», – дип сөйләде безнең яндагы авылдан бер украин хатыны. Аларның фашисттан да яман икәнен белә идек ул вакытта ук. Хәзер дә нәрсәләр эшләп яталар бит, әнә, – ди Тәскирә апа. Өстәлендә көне буе радио сөйли, дөнья вакыйгаларыннан хәбәрдар ул әле дә.

– Безнең батарея Коростеньны урталай бүлеп ага торган Уж елгасы аша салынган күпер тирәсенә урнашкан иде. Елганың киң тугаенда эре кара ташлар ята. Бик күп иде алар. Елгада гимнастеркаларны юып, шул ташлар өстенә салып киптерәбез... Сугыш тынган арада шәһәр кешеләреннән икмәк ала идек. 30 елдан артык вакыт узып, Коростеньга баргач, иптәшләр белән ярты ипи алып ашап карадык. Исе дә, тәме дә шул ук. Икмәкне тотып, күңелем тулуга түзә алмыйча елап җибәрдем. Бик күп истәлекләрне яңартты ул икмәк. Ул хатирәләрне еламыйча искә алып та булмый инде...

Полкташлары, кызларны яратып, «Казанские лаптики» дип йөртәләр. Имеш, алар килгәч эшләр уңды, фронт сызыгы да гел алга бара. Шулай бер станцияне икенчесенә алыштыралар: Ковель, Брест, Польша шәһәрләре... Сугышчыларның күңелен күтәрер өчен концерт куярга да киләләр. Шунда бер кызның бик моңлы итеп татарча «Кошлар кебек» исемле җыр җырлаганын ишетә Тәскирә апа. Елый-елый тыңлаган бу җырдан соң әнисенә шигырь юллары белән хат язып сала:

*«Әнкәй, мине бик сагынсаң,*
*Кара кояш багышын.*
*Шушы яшемдә билемә*
*Буам солдат каешын.*
*Без үскәндә дүртәү идек,*
*Ник таралдык бу кадәр?*
*Тиз генә җыйнала алмабыз*
*Сугыш бетмәсә әгәр...»*

Матур гына барган концертны «Таралырга!» дигән приказ кинәт өзә. Дошман самолетлары бомбага тота башлауга, землянкаларга кереп качалар. Чыкканда инде артист кызлар таралышкан була. Тагын бер генә булса да татар җырын ишетергә гаҗиз булып кала Тәскирә. Гомере буе оныта алмый ул моңны. Җырчы кызны сугыштан соң барыбер эзләп таба. Зита Измайлова белән 1993 елда ветераннар очрашуында яңадан күрешәләр. Ә теге шигырь юллары белән язылган хатны әнисе саклап кына тота. Нишләптер кызы кайтудан өмете өзелә Һадия апаның...

### «Ай, Тәскирә апа!»

– Элемтәчеләр булгач, җиңү хәбәрен беренчеләрдән ишеттек. Ләкин нигәдер ышанып бетмәдек. Чөнки Япония сугыш башлаган иде. Бу афәтне исән-сау ерып чыктык, безне хәзер япон сугышына җибәрерләрме инде дип курыктык. Шуңа күрә аның сөенече дә булмады ул көнне... И-и-и, хәзер сөйләп булмый. Хәтер юк. Берсе артына берсен кушып сөйләсәң генә матур була ул, сезгә калганы шушы гына инде, – дип көрсенеп тә ала Тәскирә апа.

Хәтер йомгагын сугыштан кайткан көнгә ялгарга тырышабыз. «Сугыштан ничек кайтканыгызны хәтерлисезме, Тәскирә апа?» – дип сорыйм.

– Ничек кайтыйм? Тәпиләп, – ди дә, үзе дә көлеп куя. Җор теллелеген әле дә югалтмаган ул. – Арчадан безнең авылга егерме чакрым гына бит. Ялт-йолт каранып, бөтен авылларны күз аша уздырып җәяү кайттым... Төш вакыты узып киткән иде инде. Беренче урамда мине күрүче булмады. Аннары икенче урамга кергәч, бер кыз бала күреп алды да: «Ай, Тәскирә апа!» – дип килеп асылынды. «Кычкырмыйм тор, кызым, мин тынычлап кына кайтып җитим», – дидем дә, өйгә кадәр җайлап кайттым. Капканы ачып кердем дә, ишегалларын, бакчаны күзәтәм, әни күренмәсме, дим. Август ахырлары бит. Чыннан да, бакчада маташа иде ул, бәрәңге вакыты бит... Аннары елашу китте инде...

Көне буе кеше өзелми йорттан. Бигрәк тә бала-чага. Кайтканда Тәскирә апага юлга дип биргән шикәрдән рәхәтләнәләр! Әле берсе кереп ала, әле икенчесе. Монда шикәр юктыр дигән уйны башына да китермәгән солдат исенә килгәндә шикәр шактый кимегән була инде. Әнисенә дип җыеп куя аларын. Күрше-тирә бала-чагасы өчен Тәскирә апаларының сугыштан кайтуы бер татлы мизгел булып истә кала.

Берничә ел узгач, Тәскирә ападан соң авылга Шәрифулла исемле егет тә әйләнеп кайта. Дүрт классны бергә укыган була алар. Бер-берсенә күңеле төшеп йөргән яшьләрне әти-әниләре өйләндерергә ниятли. Сөйләшенгән көнне Шәрифулла, Тәскирәне ат арбасына утыртып, үзләренә алып төшеп тә китә. Берсе артыннан берсе биш малайлары туа. Ләкин дәһшәтле сугыш елларында узган сынаулары – сынау булмаган икән әле Тәскирә апаның. Бала хәсрәтен дә өч тапкыр күтәрергә туры килә аңа. Бер уллары җиде айда үлеп китә, икенчесе – 5 яшендә. Иң үкенечлесе – 46 яшьлек газиз улын югалтуы була...

– Бомба астында стенага ыграк сыенып иманымны укыганда бу кадәр яшәрмен дип тә уйламаган идем, – ди ветеран. Сугыштан соң вакыйгаларга бай тормыш белән яши ул. Бөек Ватан сугышының 30 еллыгын билгеләп үткән елны полкташлары белән җыелып Украина якларына юл тотканнар. Аның һавасы да әллә ничек, икенче төрле якын, ди. Үзләре азат иткән җирләр булгангадыр, мөгаен. Хатирәләрне яңартып, эз калдырган җирләрне йөреп, кунак булып, кадер-хөрмәт күреп кайтканнар.

Тәскирә апа тик ята торганнардан түгел! Бик күп китаплар укыган, язучылар белән аралашкан, Әмирхан Еники, Шәриф Хөсәенов белән фикер алышып, хатлар язышкан. «Казан утлары» журналында Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы басылып чыккач, кайбер хаталы урыннарны күрсәтеп, авторга хат язган. Җавабын да алган! Роман китап булып басылып чыкканда ул хаталарның төзәтелгән булуы белән горурлана ветеран.

Сугыш хатирәләрен үз гомерендә әллә ничә тапкыр сөйләргә, яңартырга туры килгән Тәскирә апага. Журналистлар, укучылар, укытучылар, якташлар кечкенә генә бу йорт сукмагына эзләрен әле дә суытмый. Ә менә дәүләт салып биргән яңа таш йортка ветеран күченмәгән. Ходай биргән гомерен шушында – Шәрифулласы белән бергә күтәргән, 47 ел буе иңне иңгә куеп бәхетле гомер кичергән нигездә уздырырга тели.



*«Бу фотокарточкада минем озын гомеремнең онытылмас мизгелләре. Без Польшада хезмәт иткәндә үзебез бик тә көткән, бик тә кадерле булган сугыш бетү хәбәрен алдык. Бик шатландык, елаштык, җырлаштык. Барыбыз бергә вакытта җай чыгу белән фотога төшәргә кирәк дип уйлашып, фотога төшү насыйп булды. Польша, 1945 ел».*

Көтеп алган көннең кадерле мизгелләрен тасвирлаган язулы фотосурәтне Тәскирә апа әле дә кадерләп саклый.

# ЖУРНАЛИСТИКАГА – КАСТИНГ АША



Фото: Анна Арахамия

Әлмәт. «Альметьевский вестник» газетасы. Баш мөхәррир Ландыш Зарипова. Аңлагансыздыр: Ландыш журналыбыз герое булачак. Күрешеп сөйләшкәнче, үзем белгән Ландышны искә төшереп утырам. Шаян телле, матур дикцияле, бөтерчек кебек җитез, тәвәккәл… Миңа ул үсмерләрнең «Алтын каләм» республика фестивале аша берникадәр таныш… Мәскәүдә узган матбугат күргәзмәләрендә юлларыбыз кисешкәне бар… Татарстан журналистларының «Бәллүр каләм» конкурсы лауреаты булган көннәре дә күз алдында… Ә шулай да Ландыш журналистика тарихына татар яшьләр газетасы чыгаручы булып кереп калачак! 90 нчы еллар ахыры. Әлмәттә «Молодёжный коктейль», аның татар телендәге дәвамчысы «Яшьләр заманы» дигән популяр газеталар чыга. Студентлар, югары класс укучылары егылып укый, «Яшьләр заманы»н үзара ЯЗ дип кенә йөртәләр!.. Язгы ташу кебек бөтереп ала, язарга, иҗатка илһамландыра, яз дип тора торган газета буларак кабул итәләрдер, мөгаен. Менә шундый ностальгия.
Ә бүген Ландыш Зарипова – «Альметьевский вестник»–«Әлмәт хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире, Бөтендөнья татар конгрессының Әлмәт бүлеге җитәкчесе, «Татарстан – Яңа гасыр» иҗтимагый-сәяси хәрәкәтенең Әлмәт бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары. Татарстан Республикасының атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре дигән мактаулы исемгә ия.
Күңелдә сорау арты сорау туа. Журналистикага ничек килгән ул? Нигә шул юлны сайлаган? Газета тикле газета ачуга ничек тәвәккәлләгән? Эш алымнары буенча ул редактормы, әллә медиаменеджермы? Хатын-кыз буларак, баш мөхәррир вазыйфасын башкару аңа кыен түгелме? Туктаусыз стресслар, гел ашыктырып торган дедлайн, ялларсыз эш… Шуларны җиңәрлек көчне каян таба икән? Командасын ничек туплаган?.. Ландыш белән күрешкәч, ул сораулар тагын да күбәйде.



Эльмира ЗАКИРОВА

– Бүген газетта, иртәгә советта без, – ди ул, сүзләрен рифмалаштырып. – Аннан Конгресс эше, «Татарстан – Яңа гасыр» хәрәкәте, отчетлар, планнар, газетаның 25 еллыгы. Көн саен бер эш, көн саен бер вакыйга... – Ландыш, сүзеннән бүленеп, редакция тормышына күчеп куя: – Ай, кызлар, туктагыз, бу текстны җибәрмибез, алмаштырыйк! Чү, теге карар номерсыз китеп бара... – Аннары: – Менә шулай эшлибез, – дип көлеп җибәрә. – Һич авырсынмыйча эшлибез, шулай бит, кызлар?

«Альметьевский вестник»–«Әлмәт хәбәрләре» редакциясе район башкарма комитеты бинасында урнашкан.

Ландышның көн саен кичләрен 15 әр чакрым җәяү йөрүләре дә, үзе әйтмешли, бөтен исполкомны татарча сөйләшергә өйрәтүләре дә (һәр эш көне «Хәерле иртә!» дип исәнләшүдән башлана икән монда, руслар да шулай сәламләшә диделәр. Татар телен өйрәнү буенча Әлмәт муниципаль районы Советы һәм башкарма комитеты махсус укулар уздырган!), өйләренә кайчак кайтып та керә алмаулары да (Әнә бит Фәрдия нәрсә ди: «Халыкта шундый сүз таралган хәтта. Безнең беребезнең дә гаиләсе юк, имеш: куна-төнә газета чыгарабыз, эштә генә яшибез, ди. Аллага шөкер, барыбыз да гаиләле: ирләребез дә, балаларыбыз да бар. Хәлебезне аңлый торган кешеләр өйдә»)... Барысы да кызык! Һәм без менә шулар турында сөйләшә-сөйләшә, кичләрен Ландыш җәяүләп йөри, фотога төшерә торган сукмаклардан атлыйбыз. Асфальт төсендәге, нефть төсендәге зәңгәрсу-кара биек биналар Дубайны хәтерләтә. Урамда яшьләр, велосипедларда яшьләр... Әлмәт драма театры яныннан узабыз, Татарстан нефте паркын артта калдырабыз, «Буалар шарлавыгы» дигән комплекста күперләрдән чыгып, нефтьчеләр башкаласы манзараларына сокланабыз. Шәмсенур паркы, «Каракүз» бакчалары турында, шәһәре, аның кешеләре турында яратып сөйли Ландыш. «Мин шәһәремнең патриоты. Әлмәттән ерак китеп яши алмыйм», – ди ул. Эше, мәшәкатьләре, хәтта ялгышлары турында да эчкерсез итеп ачыла.

### *Редакция тормышы – минеке!*

**Балачакта диктор буласым килә иде.** Телевизордан соңгы хәбәрләрне җиткерүче ике диктор – Лия Заһидуллина белән Рөстәм Нәбиуллин минем өчен тәмам кумирга әйләнде. Мәктәптән йөгереп кайтам да, форманы да салмыйча, өстәлдәге газеталарга ябырылам. Дикторларга охшатып, газеталардан һава торышын, тапшырулар программаларын укыйм. Аннан соң инде җырлап та алам. Берсендә абый керде дә: «Радиодан җырлыйлар дип торам. Синмени ул?!» – ди. Аннары артист булам дип йөри башладым. Иптәш кызым белән педагогика институтына дип әзерләндек-әзерләндек тә, Алабуга культура-агарту училищесының режиссура бүлегенә укырга кердек. Аны тәмамалагач укуны Казан дәүләт мәдәният институтында дәвам иттем.

**Үзем Габдрахман авылы кызы.** Әтием бик матур җырлый, баянда уйный иде. Беренче мотоцикл да аныкы иде Габдрахманда. Әни тапкыр телле, уен-көлке белән сөйләшергә ярата торган, мәкаль, хикмәтле сүзләр кыстырып сөйли иде. Ул сүзләр миңа да күчеп беткән. Әни әйтмешли, дип сөйли башлыйм. Бик тырышлар иде инде. Мин үзем генә андый түгел. Бакчаларда эшләмим, суган да утырта белмим, торт та пешерә белмим. (*Көлә.*) (Кылт итеп Фәрдия сүзләре искә төшә: «Аның каравы, биш минутта өчпочмак пешерә ул!») Ирем Рөстәмгә дә безнең сфера бик якын, укытучы малае буларак, иҗат эшенең күп көч, вакыт сарыф иткәнлеген яхшы аңлый, мөмкин кадәр ярдәм итә. Игътибарлы, кайгыртучан ул. («Рөстәм ел саен аңа ландыш чәчәкләре бүләк итә», – дип, Стелла белән Фәрдия серне тишә.) Ике кызыбыз бар. Гөлназ – юрист, Регина рухы белән журналистикага якын: студент чакта ук нефть институты газетасында да, матбугат үзәгендә дә эшләде. Хәзер «Каракүз» балалар бакчасында минем юлны дәвам итә: нәниләргә татар теле өйрәтә. Оныкларыбыз Ильдан белән Тамерлан да үсеп килә.

**Артист тормышы үзем белән бара.** Укыганда спектакльләрдә гел баш рольләрне уйнадым. Диплом спектакленнән соң Әлфинур белән мине Минзәлә театрына эшкә чакырдылар. Бармадым. Бер дә үкенмим. Яңа Кәшер, Тайсуган клубларында директор, Габдрахман мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе булып эшләдем... Нияз Фәрхетдинов белән бергә оештырган «Каз канаты» бию ансамбле халык бию ансамбленә әйләнде хәтта. Ун елга якын балалар бакчасында тәрбияче булып эшләдем. Чаллы дәүләт педагогика институтын тәмамладым. Ләкин күңел үзенә урын табалмыйча, һаман каядыр ашкына иде! Бәйрәмнәрне, кичәләрне гел үзем алып барырга тырышам. Әллә ниләр уйлап чыгарам, әллә нәрсәләргә омтылам. Миңа хәтта Мәгариф идарәсеннән тикшерү килде! Янәсе, мин методикадан чыгам, үзбелдегем белән эшлим икән. Кечкенә балалар белән генә эшләү миңа тар тоела башлады. Масштаблы эшләр кирәк иде. Редакция эше минем тизлеккә, минем колачка, хыял дөньяма бик тә туры килер сыман тоелды.

## Журналистикада күндәм холык белән озак тоткарланып булмыйдыр.

### *Журналистикада йөгереп йөрергә кирәк!*

**Һәм мин кастинг аша узып редактор булдым!** Башыннан сөйлим әле. Бервакыт «Әлмәт таңнары»ннан иптәш кызым шалтырата. «Син газетада эшлисем килә дигән идең. «Молодежный коктейль» газетасы кастинг игълан итте!» – ди! Чыгып чаптым шунда. Андагы халы-ык!

Бер материал язып карарга, заголовоклар әзерләргә, рубрикалар уйларга, газетаның концепциясен төзергә дигән биремнәр бирделәр. Һәм, беләсеңме, мине алдылар! Соңыннан гына әйттеләр, мәдәният һәм мәгариф буенча белемнәрең, тәҗрибәң булганга син уздың, диделәр. Жюрида утырган шагыйрә Клара Булатова, Әлмәтнең татар иҗтимагый хәрәкәтен оештыручы Марсель Зиннәтуллин миңа зур ышаныч, өметләр баглаганнар күрәсең. Татарча яшьләр газетасы чыгарырга алындым шулай. Ике сан дөнья күргәннән соң мине редактор итеп куйдылар. Бу 1997 елның 1 мае иде. Коллективта Стелла, Гөлнара

## «Мин яратам сине, Әлмәтем!» дибез дә паркта бәйрәмнәр үткәрәбез.



Гаязова һәм мин. Соңрак хисапчы Венера Галиуллина килеп кушылды. Журналистларым юк: татарча да, русча да язам. Рус газетасы эчендә кушымта булып чыгабыз.

**Яшьләр газетасы минем стихия булып чыкты.** Монда «Пресс-голоса» лагере, «Алтын каләм» фестивальләре... Мине «Татарстан – Яңа гасыр» иҗтимагый-сәяси хәрәкәтенә җитәкче итеп куйдылар. Йөзәм, кайтмый эшлим, әкрен генә штат туплыйм. Безнең командага журналистиканы тәмамлаган Фәрдия Хәсәнова килеп кушылды. Күп полосалы, шәп версткалы заманча, яшьләр газетасы укучыларга да ошады. Чаллыда басыла иде. Процессорны машинага төйибез дә чыгып китәбез, «Глагол» типографиясендә кунып калган чаклар да була иде. Күп еллар дәвамында шунда басылдык. «Яшь хәбәрче» мәктәбен ачтык, ике телдә эшлибез, мәктәпләргә йөрибез. Журналистлардан да уңдым. Лилия Яруллина, Ләйлә Хәйруллина, Аилия Дәүләтовалар... Чын профессионаллар! Чаллыдан Дамир Шәйхетдинов дигән талантлы журналист та безгә килде, ул инде мәктәпләрдән гел кайтып кермәде. Тиражларыбыз арта башлады. Безне беләләр, укыйлар. Ике ел дәвамында район башлыгының матбугат хезмәтен дә алып бардык. Ул чорларда журналистиканың барлык жанрларын да кулланып эшләргә туры килде. Чын тормыш мәктәбе булды дип әйтә алам. Өстәвенә, иҗтимагый эшләр: «Ак калфак» оешмасы белән берлектә чаралар үткәрәбез, авылларга чыгабыз... Мәгариф идарәсе, мөхтәсибәт, башкарма комитет – барыбыз бергә эшлибез. Өстәвенә, мин Бөтендөнья татар конгрессының Әлмәт бүлеге җитәкчесе.

**«Татарстан яшьләре»ннән кала, яшьләр өчен ике телдә нәшер ителүче бердәнбер газета булды ул республикада.** 1998 елдан башлап балалар, үсмерләр фестивале «Пресс-голоса»ны («Матбугат тавышы») үткәрүдә катнашты. «Яшьләр заманы» редакциясе белән берлектә Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе яшь журналистлар өчен профиль сменасы оештырды. 2011 елда «Татарстан – Яңа гасыр» хәрәкәте канаты астында «Без бергә»–«Вместе» яшьләр клубын эшләтеп җибәрдек.

Тора-бара «Молодежный коктейль»гә финанслау туктала башлады. Әлмәттә дә бик күп газеталар ябылды ул чорда. Безгә дә ябылу куркынычы янады. Газетаны мөстәкыйль итәргә вакыт җитте. Яшьләр идарәсеннән киттек, шәһәр администрациясе һәм район Советы башкарма комитеты – гамәлгә куючыларыбыз иде. Әлеге чаралар газетабызның алга таба тотрыклы яшәешенә нигез булды. Ул чактагы район хакимияте башлыгы Илдус Гәрәевкә бик рәхмәтлемен. Газетаның кирәк булуын аңладылар һәм рәсми рәвештә теркәделәр. Татар газетасы бит әле ул, яшьләр газетасы! Һәм Әлмәт җирлегендә чыга! «Татарстан яшьләре»ннән кала, икенче газета иде ул. Яшьләр елы уңаеннан «Молодежный меридиан» газетасы ачтык. Студентлар, эшче яшьләр, мәктәп укучылар проблемаларын яктыртуны максат итеп куйдык. Ул «Яшьләр заманы» эчендә чыга башлады һәм тиз арада үз укучысын тапты.

**«Яшь журналистлар мәктәбе» – үзе бер мактанычыбыз.** Гүзәлия Хәнипова, Ләйсән Төхфәтуллина, Лилия Заһидуллина, Эльнар Байназаровлар... Редакцияләрдә, матбугат үзәкләрендә хәзер алар. 1998 елда «Алтын каләм»дә безнең Альбина Төхвәтова Гран-прига лаек булды.

**Ике ел хезмәт хакы алмый эшләдек без!** «Молодежный коктейль»дә акчасыз эшләгән чакларны сөйлим әле. Энтузиазм белән генә бара торган шулкадәр инициатив команда булганбыз инде! Ул елларны искә төшерәм дә... Хәзер берәү дә шулай эшләмәячәк. «МК»ның баш мөхәррире Максим Игнатьев белән акча сорарга киттек исполкомга. «Акча булмастыр. Һәрхәлдә, хәзер булмас», – ди район башлыгы Илшат Фәрдиев. Ә редакциядә безне яхшы хәбәр белән кайтырлар дип көтәләр. Без болай да ничек тә тотабыз инде команданы. Югыйсә таралачаклар. Сүзсез кайттык башта. Өметләнеп, Максимга күз кырые белән карап-карап алам. Халыкка ничек аңлатырга? Менә ул елмайды да: «Все будет хорошо, Ландыш», – ди. «Әлбәттә!» – дим. Елмаеп кайтып кердек.

**Гөнаһ җыеп, алдашырга булдык.** «Акча булачак! Газетаны төсле итеп чыгарачакбыз! Полосаларны арттырабыз! Акчаны бераз соңрак җыеп бирәчәкләр! Ничек инде исполком булышмасын ди. Безнең Фәрдиев во җитәкче бит ул!» – дип мактый-мактый, үз ялганыбызга үзебез дә ышанып, мәш килдек шулай. И шатландылар инде! Менә бүген була, менә иртәгә була дия-дия эшлибез. «Молодёжный коктейль» «Иң яхшы кирпеч бездә!» дигән рекламаны урнаштырды. Ничек тә реклама белән акча эшләргә тырышабыз. Газетаны ничек чыгардыгыз диген – рекламага! Ә зарплатага акча калмый. Ул акча кәгазьгә, типография чыгымнарына китеп бара.

**Урыннар да алдык, ябылу алларында да калдык.** Берзаман 300 мең бурыч белән бу газета минем җилкәдә калды. Шундый зур штрафлар салдылар, җитмәсә. Кая ул штрафлар түләү, газета чыгарырга да акчабыз юк! Казанга антимонополь судка чакыртып, и сүгәләр безне! Ә мин сикерәм дә торам, сикерәм дә торам. Алай түгел, болай ул дип аңлатмакчы булам. «Бу – яшьләр газетасы. Сезнең хакыгыз юк!» – дим, еларга җитешеп. «Суд бара! Утыры-

гыз!» – дип шелтә белдерәләр. Сүзне ахырдан бирәләр икән. Ничек итсәм иттем, штрафсыз гына кайтып киттек.

**Минем беренче интервью.** Эшли башлаган гына көннәрем. Турыдан-туры җитәкчем Кассиров Николай Михайлович мине бөтен җиргә үзе белән йөртә, татар газетасы редакторы дип таныштыра. Берсендә Балалар һәм яшьләр эшләре буенча министр Марат Бариев килгән Әлмәткә. Миңа интервью алырга куштылар, диктофон тотып кереп киттем. Кем икәнлеген дә белмим, сорауларым да юк. Шулай да эшнең нәрсәдә икәнлеген тиз төшендем. Сәгать ярым сөйләштек шунда министр белән, бер полосалык материал булды ул. Икенче интервью Әлмәт районы хакимиятенең шул чактагы башлыгы Илдус Гәрәев белән иде. Нинди сораулар бирергә дә белмим. «Молодёжный коктейль» фотографы Илдар Сәетгәрәев бик белдекле кыяфәткә кереп, «Чәчү барышы турында сора... Башкалар шулай сорый», – ди. Уртак тырышлык белән язма бик уңышлы килеп чыкты.

## *Журналистика – мәңгелек командировка*

**2013 елда статус үзгәрде: «Альметьевский вестник»–«Әлмәт хәбәрләре» булып чыга башладык.** Районда беренче ачылган татар яшьләре газетасы «Яшьләр заманы» булып яшәп, муниципаль берәмлекнең рәсми публикаторы «Альметьевский вестник» булып үскән икән, димәк – ул халыкчан. Татар телендә район, шәһәр проблемалары турында язу, гамәлгә куелган программалар хакында тәфсилле хәбәрнамәләр, кеше язмышы турындагы хикәяләр – бар да газетаның танылуына һәм укылуына китерде. Бүген дә басманы ике телдә алып барырга тырышабыз. Югары профессиональ дәрәҗәдә халыкка мәгълүмат, хәбәрләр җиткерәбез, вакыйгалар үзәгендә кайныйбыз, хезмәт кешеләре белән таныштырабыз. Урта һәм кече бизнес вәкилләре, нефть предприятиеләре белән хезмәттәшлек итәбез. Басмабыз профессиональ, эшлекле һәм иҗтимагый даирәләрдә яхшы билгеле. Товарларны, хезмәт күрсәтүне, бизнесны таныту кирәк булганда һәрчак безгә мөрәҗәгать итәләр. Бу безгә булган ышаныч турында сөйли. Мәдәниятне, сәнгатьне, нефть төбәгенең данлы



кешеләрен киңрәк яктыртуга ирештек. Массакүләм мәгълүмат чараларының шәһәр, республика конкурсларында актив катнашабыз, призлы урыннар яулыйбыз. Миңа җиде район башлыгы белән эшләргә насыйп булды. Эш дәверендә һөнәремә дә, җитәкчеләргә дә тугры калдым.

**Муниципаль газета алдында куелган таләпләр бераз башкачарак.** Беренче максатыбыз район һәм җирле хакимият яңалыкларын, көн сулышын укучыга җиткереп бару булса, икенче төп вазыйфа – кабул ителгән документларга юридик җирлек тудыру. 25 ел дәвамында безнең белән бергә булган укучыларыбызга, һәрбер сорауны хәл итәргә булышкан гамәлгә куючыларыбыз Әлмәт районы башкарма комитетына, Совет Аппаратына, мәгариф, мәдәният учреждениеләренә, ЗАГС идарәсенә рәхмәтлебез.

**Газетаның төп көче, әчтәлеге, бизәлеше, әлбәттә, ул – команда.** Үземне бәхетле җитәкче дип әйтә алам: ярты сүздән аңлап эшләүче коллективым бар. Беренче көннән бергә эшләүче хезмәттәшләрем Фәрдия Хәсәнова, Стелла Рәхимова, баш хисапчы Виктория Бакиева, яшь журналистыбыз Алия Гомәрова – минем таянычым алар. Район башлыгының информацион-аналитик бүлеге белән тыгыз элемтәдә ярдәмләшеп эшлибез. Башкарма комитетның матбугат үзәге булып торабыз дип тә горурланабыз.

**Татар милләтенә кагылышлы эшләргә лаеклы өлеш кертергә тырышабыз.** Май аенда уза торган бәйрәмнәрдә яшь журналистлар мәктәбенә йөрүчеләргә таныклыклар тапшырабыз. Күргәзмәләр, хәйриячелек акцияләре белән үрелеп, милли колоритта уза ул. Спонсорлар табып, күп балалы гаиләләргә велосипедлар бүләк иттек.

**Бер начар гадәтем – үз фикеремне көчләп тагам.** «Юк, мин әйткәнчә дөрес!» – дим. Үземнекен әйтәм-әйтәм дә, «Кызлар, сезнеке дөрестер, бәлки. Әйдә, сезнеңчә булсын әле», – дип кайтып төшәм.

**Беренче булырга яратам.** 90 нчы елларда балалар бакчаларында татар төркемнәре ачыла башлагач, әлеге эшне миңа ышанып тапшырдылар. Шәһәрнең татар төркемле беренче бакчасы булдык без.

**Мин булган җирдә һәрчак көрәш!** Финанслау, подписка, акча, спонсор сорап керәсең. Баш мөхәррир менеджер да, хисапчы да, юрист та булырга тиеш.

**Ишектән кертмәсәләр – тәрәзәдән, аннан да кусалар, форточкадан кер, морҗадан төш...** Килешәм. Әрсезлек – ярты бәхет, диләр. Кая барсам, нишләсәм дә, үз сүземне әйтми калмыйм.

**Журналистикада нәрсә ошый?** Бүген театрга кереп утырам. Язам. Артистлар белән аралашам. Телим икән, авылга кайтып киләм. Җитәкчеләр янында булам. Яшьләр дөньясында кайнашам. Эшмәкәрләр белән очрашам. Артист булам, диктор булам, балалар белән эшлим дигән хыялларның барысын да колачлый ул журналист хезмәте. Башка җирдә эшләсәм, җаныма якын кешеләр барлыгын, Әлмәттә нинди шәхесләр яшәп ятуын белмәс тә идем.

**Уңышым – җаным теләгән хезмәтемдә, күңелемә якын кешеләр белән эшләү һәм яшәү.** 25 ел дәвамында үзем ачкан газетаны яшәтү, тарихта калу – минем иң зур уңышым!

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

# «УЛЛАРЫМ ҮЗЕМНЕ ТӘРБИЯЛИ»

Үсмерлек чоры. Ата-ана өчен иң зур сынау вакытыдыр бу, мөгаен. Сүзеңне тыңлап, һәрвакыт янында сырпаланган бала көннәрдән бер көнне бөтенләй үзгәрә дә куя. Аның инде үз дөньясы... Бала белән бәйләнешне ничек саклап калырга? Үсмер белән үзеңне ничек тотарга? Бәлки, безнең геройларыбыз тәҗрибәсе дә сорауларыгызга җавап табарга ярдәм итәр. Рубрикабызның кунаклары – «ШАЯН ТВ» каналының мөхәррире Чулпан ЗӘЙНУЛЛИНА һәм аның игезәк уллары САЛАВАТ белән АЗАМАТ.



**Егетләр, өйдә ашарга пешерү, идән юу кебек, хатын-кызныкы дип саналган эшләр башкаруга ничек карыйсыз?**

**Азамат:** Ни өчен хатын-кыз эшләре соң әле алар?! Барысын да ир-ат та, хатын-кыз да башкара ала. Әнкәй сорый икән, әлбәттә, булышабыз.

**Салават:** Әнкәй соңга калып кайткан чакта ашарга пешереп куюның ояты юк инде ул.

**Әниегез белән аңлашылмаучылыклар булыштырамы соң?**

**Азамат:** Була инде, ничек булмасын. Мин, мәсәлән, бик кызу кеше. Тиз кабынып китәм. Ләкин үз холкымны аңлап, вакытында гафу үтенәм.

**Әниең ишекне каты итеп ябып чыгып киткәлим, ди. Бу вакытта син нинди хисләр кичерәсең?**

**Азамат:** Әнине шул хәлгә җиткерүем өчен оялымдыр, мөгаен. Ә әнигә үпкәләргә ярамый. Мин, гомумән, үпкәче кеше түгел. Минем өчен тырышалар бит инде. Кызып китүемне контрольдә тотарга өйрәнәм. Киләчәктә моның кирәк булачагын да беләм.

**Салават:** Әйткәнемчә, конфликтлар ятратмыйм. Күбрәк тыңлыйм, аннан, берәр кызык сүз кыстырып, җавап бирергә мөмкинмен. Шулай үтеп китә инде ул...

**Егетләр, хатын-кызларга карата хөрмәтне кем тәрбияли дип уйлыйсыз?**

**Азамат:** Әти! Барысы да әтидән тора. Гомумән, егет кеше ир-ат булырга әтидән өйрәнә!

**Салават:** Әти ир кеше тәрбиясе бирә. Мәсәлән, йорт буенча эшләрне эшли белү. Егет кеше чүкеч тотып эшли белә икән, бу инде әти тырышлыгы нәтиҗәсе.

**Ә син чүкеч тота беләсеңме?**

**Салават:** Беләм, әлбәттә.

**Беләсез инде – төрле мохит бар. Ялгыш кына начар гадәтләрне татып карарга тәкъдим итсәләр...**

**Салават:** Организмга, яшәү рәвешенә зыян салганга да аларны начар гадәтләр дип әйткәннәр. Без моны аңлыйбыз. Ә нигә әле кешегә иярергә?! Гомумән, ир-атның һәрнәрсәгә үз фикере булырга тиеш. Миңа ул кирәкми икән, димәк, кирәкми. Бу хакта ике сөйләшмиләр.

**Үзегезне киләчәктә ничек итеп күрәсез?**

**Азамат:** Хыяллар зурдан! Режиссёр йә журналист булыр өчен Мәскәүдә уку турында хыялланам. Татар дөньясын тагын да танытасым килә.

**Салават:** Мин Казанда калам. Программист йә монтажер булып эшлисем килә.

**Әти-әни белән аралашуда ярату, хөрмәт итү, горурлану, курку сыйфатлары бар. Сезнең өчен кайсысы беренче урында?**

**Азамат:** Барысы да бергә кушылган. Ә иң соңгы урында, билгеле, курку.

**Салават:** Миңа калса, хөрмәт. Ә әти-әнидән без беркайчан да курыкмадык.

**Әти-әни контроленә ничек карыйсыз?**

**Азамат:** Без ирекле. Кая барырга телибез, шунда барабыз. Әмма хисап биреп торырга кирәклеген аңлыйбыз. Ярты елга бер тапкыр бергәләп утырып акча карталарыбыздагы чыгымнарны барлыйбыз.

**Салават:** Контроль түгел инде ул, борчылу. Безнең кайда йөргәнне белеп торсалар, аларга тынычрак бит инде.

**Бигрәк идеаль үсмерләр булып чыктыгыз әле. Берәр тискәре ягыгыз бармы соң сезнең?**

**Салават:** Бар нәрсәне планлаштырам. Минем өчен бар нәрсәнең эзлекле рәвештә баруы бик мөһим.

**Азамат**: Мин ялкау. *(Көлә.)* Һәм, киресенчә, бернәрсә дә планлаштырмыйм. Иҗат кешесе буларак, хаос өстенлек итә миндә.

**Әниегез нинди киңәшне еш кабатлый?**

**Салават:** Кылган гамәлләреңне уйлап кыл!

**Азамат:** Һәм шуңа өстәп: татар кызына өйлән!

**Кызлар дигәннән. Кызлар турында әниегезгә сөйләячәксезме?**

**Икесе бергә:** Сөйләячәкбез. Киңәшләр бирер. Әнкәй безнең өчен иң якыны. Ул – хатын-кыз. Кызларга кагылышлы акыллы киңәшне тагын кем бирсен инде?!

**Чулпан, игезәкләр үстерү авырмы?**

– Кечкенә чакларында да авыр булды дип әйтә алмыйм, ә хәзер алар белән рәхәтрәк тә. Уларымнан күп нәрсәгә өйрәнәм. Үзем бик эмоциональ кеше, тиз кабынып китәм. Сабыр итәргә, кайдадыр эндәшми калырга алардан үрнәк алдым, чөнки егетләр бик сабыр, бервакытта да күтәрелеп бәрелмиләр. Рульгә утырырга да алар этәргеч бирде. Бергәләп тау чаңгысына да бастык, тимераякта да шуабыз. Балалар күп нәрсәгә өйрәтә, тәрбияли. Безгә аларны ишетә белергә генә кирәк. Замана шаукымына бирелеп, тормыш куып, күп очракта ишетмибез генә яисә ишетергә теләмибез.

**Син ничек уйлыйсың, малайларга тәрбияне күбрәк әти кеше бирергә тиешме, әллә әниме?**

– Кечкенә чагында күбрәк әнидер. Бишенче-алтынчы сыйныфка кадәр миңа тартылдылар. Хәзер сизәм: күбрәк әтиләре янында кайнашырга яраталар.

**Әти иң элек малайларга нинди тәрбия бирә дип уйлыйсың?**

– Хатын-кызларга карата хөрмәт уята. Алар гаиләдә әтинең әнигә карата мөнәсәбәтен күреп, үрнәк алалар. Һичшиксез! Әйләнә-тирәдәге хатын-кызларга да бу мөнәсәбәтне күчерәчәкләр. Кыш көне мәктәптә эвакуация игълан иткәннәр. Безнекеләрнең берсенең өстендә курткасы булган. Аның янында юка күлмәктән генә укытучы басып торган. Ул укытучыга курткасын салып биргән. Улым өчен бик горурландым.

**Күренеп тора, уларың бик әдәпле. Тәрбия гаиләдә генә бирелә дип саныйсыңмы?**

– Алар татар гимназиясендә укый. Аның тәэсире дә бик зур. Яшьтәшләре дә, дуслары да безнең татар мохитеннән, бер даирәдән. Авылда әби-бабайлар бар. Алар белән аралашу да әдәпкә өйрәтми калмый. Татарда өлкәннәргә хөрмәт дигән әйбер бик көчле. Дини тәрбияне, әдәп-әхлакны әле әби-бабайлар күбрәк тә бирәдер. Авыл ул бит хезмәт тәрбиясе дә.

**Аннан соң алар сезнең әти-әниләрегезгә булган мөнәсәбәтне дә күрә.**

– «Мин әнигә шалтыраттым, син бүген шалтыраттыңмы әле?» – дип сорыйм һәрвакыт иремнән. Егетләр үсә: безгә шалтыратып хәл белешер вакытлары җитәр. «Аларга нәкъ менә хәзер үрнәк бирәбез», – дим.

**Чулпан, ике улың да бүген үз юлын тапкан дисәк тә була. Азамат – «ШАЯН ТВ»да алып баручы, киноларда төшә, Салават монтаж белән кызыксына. Бу өлкәгә аларны үзең кертеп җибәрдеңме?**

– Юк, киресенчә. *(Көлә.)* Мин мәктәптә эшли идем. Алар «Нур» театр студиясенә йөри башлады. Нурания апа Җамали кастинг уздырып, аларны кинода төшәргә сайлап алган. Аннан «Яшь ТНВ»га чакырдылар. Алар белән йөри-йөри мин дә телевидениегә кереп киттем. Әйтәм бит, үзләре мине тәрбиялиләр һәм үстерәләр. Алда егетләр өчен мең мөмкинлек, мең төрле юл. Бер юлдан китеп икенче юлга күчәргә бервакытта да соң түгел. Менә 38 яшьтә телевидениегә килеп кердем бит әле.

**Егетләр тормышында кызлар барлыкка килдеме инде?**

– Әйтә алмыйм. Бер соргач: «Барлыкка килсә, син беренче белерсең», – диделәр. Шуңа күрә тыныч кына көтәм.

**Син уларыңа иң элек әниме, әллә дусмы?**

– Әни кеше дус булырга тиеш дигән фикерне кабул итеп бетермим. Ул дуслардан өстенрәк торырга тиеш. Бала белән ата-ана арасында хөрмәт белән сугарылган чик булсын ул. Еш кына әниләр: «Без – дуслар», – диләр. Һәм бала белән әни арасындагы чик югала. Ике аралашу модуле (әни белән бала аралашу модуле – бер, дус белән дус аралашу модуле башка) буталып, аңлашылмаучылыклар килеп чыга башлый да инде.

**Кызларны гел мактыйлар. Малайларга да мактау кирәкме?**

– Минекеләргә кирәк. «Ярый әле сез бар, булмасагыз нишләр идем», «сез – минем ярдәмчеләрем», дим. Һәрвакыт рәхмәт әйтәм. Эмоциональ кеше буларак төрле чакларым була. Бүлмә ишеген дә каты итеп ябып чыгып киткәлим. Әмма ялгышымны танып, гафу үтенә дә беләм. Безнең Салават белән, гомумән, сүзгә килеп булмый. Ул тыныч кына: «Ярар, мин аңладым», – дип нокта куя белә. Ә Азамат – ул мин. *(Көлә.)* Тиз кызып китүчән, әмма ул да вакытында: «Әнкәй, мине гафу ит инде», – ди.

**Син гаиләдә өч ир арасында бердәнбер хатын-кыз. Уларыңа өй эшләрен башкарырга өйрәтәсеңме?**

– Алар аны эшли белергә тиеш. Киләчәктә үзләренә җиңел булачак. Ашарга пешерә беләләр. Күбрәк безнең Салават кухняда кайнаша инде. Әтиләренең миңа ярдәм итүен күреп үсәләр бит. Бу – бездә табигый хәл. Эштән алдан кайта икән, нигә әле ул хатыны кайтканчы пешереп куймасын?! Гаилә бит инде ул бер-береңне хөрмәт итүгә, ярдәмләшүгә корылган.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Фото: Анна Арахамия

Килен һәм кайнана… Ике арадагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы, ныклыгы, якынлыгы күбрәк кемнең зирәклегенә, акылына, тырышлыгына бәйләнгән? Иреңнең әнисе үзеңнекеннән тары ярмасы кадәр генә ким булырга тиеш, диелгән динебездә. Ә менә сез моңа ничек ирештегез? Нинди сынаулар, нинди юллар аша уздыгыз? Сөйләгез әле! Башкаларга – бигрәк тә яшьләргә гыйбрәт, сабак, үрнәк итеп сөйләгез.

«Сөембикә» журналы «Килен һәм кайнана» дигән хатлар конкурсы игълан итә. Ул ел дәвамында барачак һәм аларның иң әчтәлеклеләре журнал битләрендә урын алачак. Сездән хатлар көтеп калабыз!






# ӘЙТЕЛМИ КАЛГАН РӘХМӘТ

Алисә
ШӘРӘФИЕВА

Никахтан соң туган нигеземнән киткәндә әти-әнием, әбием белән бабам капка төбенә озата чыкты. «Машинага утыргач, артыңа борылып карама, кире кайтырлык булмасын!» – дип, колагыма пышылдады әби. «Чит җирләрдә читен булыр инде сиңа, кызым», – дип тә өстәп куйды. «Әллә кая китмим бит, күрше район – Питрәчкә генә!» – дип, әбиемне юатырга тырышсам да, тамак төбемә төер утырды. Машинага утыруга чытырдатып күзләремне йомдым. «Артка карамаска, ничек тә артка карамаска! Кире кайтырлык булмасын!» – дип, догаларымны укып баргач, 40 минутлык юл сизелми дә үтеп китте.

## Хәзер шул вакытны искә алам да, тамакка төер тыгыла. Үзем булса да янына төшәсем калган...

Менә машинабыз капка төбенә килеп туктады. Яңа туганнарым, кайнана, кайната, иремнең апасы, сеңлесе ишек төбенә ап-ак мендәр салып, барысы да тезелешеп басып торалар. Миңа әни буласы кеше елмаеп бал-май каптырды. Яратырмынмы, үз әнием кебек якын итә алырмынмы дип уйлап куйдым шунда. Иң авыры – әни дип эндәшү булды. Кайнанам: «Кызым, үз җаең белән әйтерсең», – дисә дә, кунаклар: «Хәзер үк әйт, аннан читен була», – дип кыстый башлады. Ул чакта тешемне кысып, авырлык белән генә әйттем мин ул сүзне. Чит-ят кешегә «әни» дип эндәшү бигрәкләр дә авыр икән... Никахтан соң кайнаналар йортында яши башладык. Ияләшеп китүе авыр иде. Эшләгән эшемнең рәте булмады: идән юарга алынсам – сулы чиләгемне түгәм, өй җыештырсам – өй җиһазын ватам... Үч иткәндәй, ризыкларым йә тозлы, йә көя, йә чилепешле була. Югыйсә һәрвакыт яхшы пешерә идем. Оятымнан шулкадәр гарьләндем. «Булдыксыз килен мин», – дип, үземне әчтән тиргәдем. Әни шул вакытта ник бер кыек сүз әйтсен. «Борчылма, минем плитәгә ияләшмәгәнсең генә әле син», – дип тынычландырды ул. Шуңа карамастан, икәү генә утырып чәй эчкәндә дә, кич утырганда да артык ачылып китә алмадым. Хәтта ишегалдында ялгызым гына йөргәндә дә кайнана гел мине сыный, күзәтә, ялгыш адымымны гына көтә сыман тоелды. «Кайнанага ышанма, эч-серләреңне ачып салма», «Килен кеше – ким кеше, сине барыбер үз кызы кебек яратмаячак», – дигән фикерләр күңелемә бик нык сеңгән иде шул. Кайнанамның елмаеп, матур итеп сөйләшүеннән, хәтта иртәнге ашлар әзерләп эшкә озатып җибәрүеннән дә ниндидер мәкер эзләдем. Чит балага кеше шулкадәр яхшы була алмый бит инде дип уйладым. Әмма бик каты ялгышканмын икән...

Бераз яшәгәннән соң без башка чыктык. Казандагы яңа фатирыбызга күченгәндә безнең бер урынлы караватт, бер кечкенә өстәл, ике урындык һәм плитәбез генә бар иде. Фатир алганнан соң табак-савыт алырлык та акчабыз калмады. Китәр алдыннан әйбер җыеп йөргәндә әни сервантында кадерләп саклаган өр-яңа сервизларын, кашык-чәнечкеләрен тартмага тутыра башлады. «Әни, кирәк түгел, тора-бара үзебез алырбыз әле», – дим. «Юк, кызым, мин менә шулай телим», – диде ул. «Кайнанам миңа да таба бүләк иткән иде, мин дә сиңа бүләк итәм, син үз килененә бирерсең, үзенчә бер традициябез булыр», – дип, өр-яңа табалар тоттырды. Ул инде фатир сатып алганда да булган бар акчасын безгә биргән иде. Ремонт ясаганда да, иртә таңнан автобуска утырып, Казанга, безгә обойлар ябыштырышырга килде. Безгә бик булышасы килде аның, ә мин аның ярдәмен кабул итеп алырга кыенсындым, оялдым. Аннан улыбыз туды. Палатама якыннарым да кереп йөри ала иде. Ирем гел янәшәмдә булды. Бәби тапканның икенче көнендә үк, ике сумка ризык күтәреп, Питрәчтән кайнанам килеп җиткән. Ләкин ул көнне бала тудыру йортына чит кешеләрне кертмиләр иде. Хәзер шул вакытны искә алам да, тамакка төер тыгыла... Үзем булса да янына төшәсем калган. Күңеле булган булыр иде... Ләкин мин төшмәдем. Үз хәлем хәл булгандыр, күрәсең. Ә ул миңа үзе баскан токмачлар белән аш пешереп, үләнле чәйләр әзерләп килгән иде. Шул чәй белән ашның тәмен әле дә оныта алмыйм. Андый ризыкларны әни генә пешерә белә шул.

Бала табу йортыннан чыккач, миңа кабат хастаханәгә ятарга туры килде. Биш көнлек баламны кайнанам карады. Аннан соң мине дә тәрбияләде. Питрәч белән Казан арасын шактый таптарга туры килде аңа. Шул вакытларда бер тапкыр зарланмады, аяклары авыртса да, «уф, арыдым», димәде. «Улым, Алисәне саклый күр, авыр әйберләр күтәртмә, температурасын гел күзәтеп тор, төннәрен йоклат», – ди иде иремә шалтыраткан саен. Ә бит улын чирле килененә каршы котырткан кайнаналар турында ишеткәнем бар иде минем...

Әни мине һәрвакыт сакларга тырышты. Авылга кайткач та: «Мин булганда ял ит», – дип, оныгын гел үзе карады, йокым туйганчы йоклатты. Шул чакларда фатирга күченгәнгә үкенеп тә куя идек. Шуңа ял саен Питрәчкә кайттык. Әниле йортыбыз нурлы, җылы, кайнар ашлы, бәхетле иде...

Яшь тә тугыз айлар тирәсендә улыбызны сөннәткә утырттык. Больницадан кайттык та, ирем эшләре буенча өйдән чыгып китте. Мин авыртудан һәм куркудан акырып елаган бала белән ялгызым калдым. Бу көнне ничек уздырырмын икән дип, белгән догаларымны эчтән генә укып Ходайдан ярдәм сорый башладым. Озак та үтмәде, ярдәм бирде – кайнанам килеп керде. Иң затлы күлмәген киеп килгән. «Бәйрәм белән!» – ди үзе. «Әни, нинди бәйрәм инде, күреп торасың бит хәлебезне», – дидем шунда ачуланып. Баламның елавыннан акылым томаланган иде инде. «Бик зур бәйрәм бүген – улыбыз сөннәтле егет булды», – диде дә, балага пульт белән идарә ителүче зур машина тоттырды. Улыбыз шунда ук елавыннан туктап, уйнарга тотынды. Аннан соң өстәлгә бер зур төргәк хуш исле бакча җиләге куйды. Каян тапкандыр шундый җиләкләрне, югыйсә сезоны да түгел иде. Бәйрәм табыны да әзер булды. Менә шулай иң авыр

## Гайбәт сөйләмәде әни, гомумән, ул кешеләрнең бары тик яхшы якларын гына күрде.

көнебезне бәйрәмгә әверелдерде әни. Һаман безгә акчалата ярдәм итеп яшәгән әни, бала тугач, «җомга хәере», «бала өлеше» дип, йә тагын берәр бәйрәм уйлап табып, улыбызга пенсиясеннән өлеш чыгарды. Яшь гаилә булгач, финанс ягы авыр икәнен аңлаган кайнанам, баланы барлык кирәк-яраклар белән тәэмин итәргә тырышты шулай.

Әнинең эчке тоемлавы да бик көчле иде. Гаиләбездә авырлыклар булса, авырып китсәк, акчабыз такырайса, табак-савыт шалтыраса да, шунда ук сизеп ала. Тормышыннан бер дә зарланмады. Кеше гайбәтен дә сөйләмәде, гомумән, ул кешенең начар сыйфатларын күрми иде. Аның үз кайнанасын «итәкле Гитлер» дип йөрткәннәр. Бик кырыс, явыз хатын булган. Бәлки, шуңадыр, миңа ул аеруча йомшак булды.



Узган елның октябрендә ашыгыч рәвештә бала белән әти-әнием янына кайтып китәргә туры килде. Кояшлы, салкын көзге көн. Аяк астында сап-сары каен яфраклары кыштырдый. Кайнанам безне юлга кадәр озата чыкты. Такси ярты сәгатьләп килмәде. «Әни, салкындыр сиңа, бар, кер!» – диюемә карамастан, «Сезне озатып җибәрәсем килә, кызым», – диде. Бу минем кайнанам белән соңгы күрешүем булган икән. Без киткәч, ирем белән әни авырый башлаган. Ул вакытта зәхмәтле чиргә юлыкканыбызны белмәдек, гади салкын тию дип кенә уйладык. Берничә көннән соң үзебез дә авырый башладык. Бер атна авыргач, әни хастаханәгә барган, ләкин аны, өйдә дә дәвалана аласыз, дип, кире борып җибәргәннәр. Ун көннән артык температурасы төшмәгәч, «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакырганнар, әмма ул килмәгән. Аптырагач, ирем әнине Казанга алып килгән. Аны хастаханәгә салганнар. Үпкәсенең 50 процентка зарарланган булуы ачыкланды. Кислород битлеге кигән килеш тә, телефоннан шалтыратуга ул иң элек безнең хәлне сораша иде. Хәле җиңеләеп, хастаханәдән чыгару турында сөйләшә башлаганда гына, әнидән «хәлем нык авырайды», дигән хәбәр килде. Ике сәгатьтән соң – җомга намазы вакытында аның үлүе турында әйттеләр. Беребез дә көтмәгән коточкыч хәбәр иде бу. Иремнең, кайнатамның өзгәләнеп елавын беренче тапкыр күрдем шунда. Ирләр күз яшен күтәрүе аеруча да кыен икән ул. Әнинең иң зур үкенече – яңа туган оныгын күрә алмыйча калуыдыр, мөгаен. Ул коронавирус белән тартышкан вакытта олы кызы бәби тапты.

■ Изге күңелле кайнанам барыбызны да бертигез күреп яратты. Оныклары аның өчен үзе бер зур бәхет иде.

Фотолар гаилә архивыннан алынды.

Әни сүз белән бернәрсәгә өйрәтмәде. Ләкин мин аннан бик күп нәрсәгә өйрәндем. Зарланмаска! Вак кына проблемага юлыксак та, зарланырга, мескенләнергә яратабыз инде без! Мин дә шундыйлар рәтендә идем. Ә хәзер әни нишләр иде икән, дип, аны уйлыйм да тынычланып калам. Һәр авырлыкның уңай ягын күрергә тырышам. Кешеләрне бар кимчелекләре белән ярата белү, олы йөрәкле, яхшы күңелле булу... Әниебезгә кагылышлы бу сыйфатларны үзебездә булдырырга өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле без яшьләргә. Иң мөһиме – кайнанам мине үз үрнәгендә әни булырга өйрәтте. Өч баласын гына түгел, мине, киленен, киявен дә үз канаты астына сыендырып, ана назына күмде ул. Кайткан саен аның кочагында бар тормыш мәшәкатьләреннән качып, көч туплап китә идек. «Әниеңнең шундый булуына син бәхетле», – дим хәзер дә иремә. Мин дә тормышымда, бик аз вакытка булса да, изге күңелле кайнаналы була алуыма бик бәхетле. Әнидән алган тәҗрибәмне, назымны, мәхәббәтемне инде үз балама бирәм. Минем балам үз баласына тапшырыр. Әнинең җылысы, тәрбиясе әнә шулай буыннан-буынга күчәр...

Йөрәгең дөньядагы барлык үксез балаларны сыендырырга, назың ана назыннан мәхрүм булганнарны җылытырга җитә иде, әни. Син безгә бик кирәк идең. Безне ятим итеп, бик иртә китеп бардың шул. Барысы өчен дә рәхмәт, әни. Мине какмаганың, сабыр һәм акыллы булганың өчен. Терәк булырдай ир үстергәнең өчен. Миңа кайнана түгел, Әни булганың өчен! Кызганыч, бу сүзләрне исән чагыңда үзеңә әйтергә өлгермәдем. Һәрвакыт янибызда булырсың кебек иде...

# «АК КАЛФАК» — РУХИ БИШЕГЕБЕЗ

Эльмира
ЗАКИРОВА

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты оешуга быел 30 ел була. Бөтендөнья татар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасына да шул елларда нигез салына: ул 1990 елда барлыкка килә һәм оешуының беренче көннәреннән үк хатын-кызларга кагылышлы үткен мәсьәләләрне хәл итү, ана һәм бала хокукларын яклау, татар гаиләсен саклау аша татар милләтен үстерү, гореф-гадәтләрне, телне, динне саклап калу юнәлешендә зур эшләр алып бара башлый.

Бу көннәрдә республикабызда, татарлар яшәгән төбәкләрдә әлеге олы вакыйга уңаеннан юбилей чаралары уза. Күптән түгел Татар конгрессы да шундый бер бәйрәм ясады: «Ак калфак»ның чишмә башында торган ханымнарны җыйды. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев әнә шул абруйлы хатын-кызларны сәламләп: «Бүгенге очрашу безнең өчен зур вакыйга, – дип белдерде. – Һәр буынның бурычы – милләт алдындагы җаваплылыкны тоеп яшәү. Сез бу юнәлештә гаять зур хезмәт куясыз», – дип, эшләрен югары бәяләде. 1992–2002 елларда Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе булган академик, тарих фәннәре докторы, күренекле сәясәтче Индус Таһировның: «Сез булмасагыз, без уңышка ирешә алмас идек. Конгрессны күтәрүдә, аның эшчәнлеген башлап җибәрүдә сезнең өлешегез зур булды», – дигән сүзләрендә тирән мәгънә бар. «Ак калфак»ка нигез салучы күренекле җәмәгать эшлеклесе, язучы һәм журналист Роза Туфитуллова бирегә җыелган ханымнарның һәркайсы белән якыннан таныштырып, аларның эшчәнлеген матур хатирәләр белән искә алды. «Сөембикә» журналы редакциясендә эшләгән елларда туган «Ак калфак» рухи бишегебез булды. Моны читтә яшәүче милләттәшләребез аеруча нык тоя, – дип, үткәндәге эшләрне барлады ул. – Дөнья буйлап сибелгән татарларыбызны барлап, Австралия, АКШ, Германия, Финляндиядә яшәүче милләттәшләребез белән бергәләп телебезне, динебезне саклау буенча зур эшләр башкардык. «Кыз бала тәрбияләсәң, милләтне тәрбияләрсең»... Халкыбызның бу сүзләре девизыбызга әйләнде», – диде ул.

«Сөембикә» редакциясендә баш мөхәррир урынбасары булып эшләгән елларында «Ак калфак» оешмасы үткәргән чараларның үзәгендә кайнаган язучы Марат Әмирханов исә Роза Рәхмәтулла кызы Туфитуллова эшчәнлеген бәяләп: «Сез нигез салган «Ак калфак» оешмасы бөтен Җир шарында танылу алды. Ул, таудан тәгәрәп төшкән ташкын кебек, асыл татар хатын-кызларын үз артыннан ияртте. Сезнең алдан күрә белү талантына сокланырга гына мөмкин», – диде. «Ак калфак»ның бүгенге җитәкчесе Кадрия Идрисовага Роза ханымның ак энҗе мәрҗән муенса бүләк итүендә дә тирән мәгънә бар иде. Димәк, традицияләр дәвам итәчәк! Очрашу барышында Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев «Ак калфак»ларга Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының медальләрен, Рәхмәт хатларын тапшырды, ханымнарның иңнәренә Оренбург шәлләре япты.

Аннары инде кунакларны Казанның Фатиха Аитова исемендәге 12 нче кызлар гимназиясендә – «Ак калфак»ларның көрәшеп, артыннан йөреп ачтырган уку йортында көтәләр иде. Андагы Милли мәгариф музее, Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган мемориаль зал, Фатиха Аитова музее, Актлар залында гимназия укучыларының чыгышлары – барысы да «Ак калфак»лар хыялында йөрткән, алар күрергә теләгән изге теләкләрнең чынга ашуы иде.






Фото: www.tatar-congress.org

# ЯҢГЫРКАЕМ, ЯУ, ЯУ!





Лилия
ГӘРӘЕВА

**Татарлар тупланып яшәгән Идел буе, Урал төбәкләрендә язгы кыр эшләре күбесенчә апрель-майга туры килә. Гомер-гомергә игенчелек белән тормыш иткән халкыбыз өчен әлеге эшләрнең башлануы мөһим көн саналган. Аңа алдан әзерләнгәннәр, мул уңышка өметләнеп кылына торган аерым бер йолалары да булган. Игеннәрнең уңышы кешенең үз тырышлыгыннан тыш, һава торышына да бәйле, әлеге йолаларның нигезендә табигатьнең фатихасын алу, Аллаһка ялвару ята.**

## *Орлык чыгару*

Бу йоланы Идел буенда һәм Уралда яшәүче татарлар башкарган. Казан татарларында ул түбәндәгечә үткән. Кичтән мунча ягылган, гаиләдәге һәркем юынган-чистарынган. Орлык чәчүче чиста киемнәрен киеп, иртән юлга кузгалган. Юлында беренче очраган кешегә йомырка биргән – чәчүнең уңышлы үтүен теләгән. Кырга барып, дога кылганнан соң, иген чәчүче, муенына тубалын асып, басуга кереп киткән. Иген бөртекләре белән бергә җир өстендә йомры-йомры йомыркалар сибелеп калган. Бөртекләр шушы йомыркалар кебек эре, тук булсын, дип теләгәннәр. Балалар аларны җыю өчен кырга махсус килә торган булган.  Кайбер якларда, аеруча керәшеннәрдә, йомыркаларны һәм ипи кыерчыгын җиргә дә күмгәннәр.

Әлки ягында яшәүче мишәрләрдә шундый сүзләр әйтелгән: *«Җир хуҗасы Суар ата, / Суар ата су япата. / Иген тулы нугратта (амбарда). / Бир, Ходаем, мул уңыш».* Такмакның мондые да булган: *«Җир атасы – җирән сакал! / Җир анасы – асыл бикә! / Түбәсенә туклыгын бир, / Тамырына ныклыгын бир, / Ил өстенә муллыгын бир, / Ил эчендә безгә дә бир! / Башлыйк теләкне, / Күтәрик беләкне, – / Кояш, шаһит бул!»*

Берникадәр араны чәчкәч, тәнәфес ясалган. Кырга зур ашъяулык җәелгән, бөтен килеш пешкән йомырка, түмтүгәрәк башланмаган ипекәй куелган. Табынга күрше ызаннардагыларны да чакырганнар. Тамак туйдыргач, мул уңыш, вакытында яуган яңгырлар теләп дога кылынган.

Кайбер авылларда йомыркаларны суган кабыгы суында кызылга манганнар. Ул йомаркалар кырга барганда юлда очраган бала-чагаларга бүләк ителгән. Алар исә кулларына йомырка тоттыргач: «Ашлыгыңның башы тукмактай булсын», – дип, изге теләген ирештергән.

Тәтеш якларында кырга чыкканда ат ялына он сибү гадәте дә булган. Бу көнне муллага яки авылның авыр тормышлы берәр ятимenә он, йомырка хәер ителгән.

Татарстанның Арча районында чәчүгә чыгар алдыннан сабан боткасы пешерү гадәте булуы билгеле. Бодай яки борай ярмасыннан пешерелгән бу ботка белән авылның мохтаҗларын сыйлаганнар.

Мишәрләр исә кичтән күп итеп төче камырдан күмәч пешереп, мохтаҗларга өләшкән. Питырас дип атаганнар аны. Шундый күмәчнең берсен юка гына телемнәргә кисеп, өстенә тоз сипкәннәр. Беренче телемне йорт хуҗасы – гаилә башлыгы авыз иткән. Ә бер күмәчне җир сөрәсе атка биргәннәр. Башактагы бөртекләр шундый ук зурлыкта булсын дип, кайбер авылларда бавырсак та пешергәннәр.

## *Шыйлык*

Язгы чәчү алдыннан, җирләр кипкәч, кырга чыгарга әзерләнгәндә уздырганнар аны. Шыйлык – төрки сүз, сыйлык дигәнне аңлата. Галимә Флера Баязитованың

Корбан – татарларның борынгы йоласын, кырда корбан китереп, теләк теләү, мул уңыш сорауны да белдерә.

«Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары» китабында (Татарстан китап нәшрияты, 1995 ел) шыйлык сүзенең – Казан арты, Түбән Кама тирәсендәге сөйләшләрдә билгеле булуы әйтелә. Әлеге йола башлыча керәшеннәргә хас. Шыйлыкны авылның бер махсус урынында уздырганнар. Гаилә башлыгы иртән җилпучка чәчүлек орлык, сөт, йомырка, түгәрәк ипи салып, шыйлык булган урынга юнәлгән. Сөт ризыкларын бер кисмәккә бушатып, шунда йомырка тураганнар һәм савытларга бүлеп, кеше саен өләшкәннәр. Ашаганнан соң, ирләр кояшка таба тезелеп басып, келәү әйткән.

Кайсыдыр якларда шыйлык бер генә тапкыр үткәрелсә, кайсыбер авылларда ул ике тапкыр узган. Иртән – ир-атлар, кичен хатын-кызлар җыелган. Зур табакларда сөттә пешкән тары яки ясмык боткасын да үзләре белән алып килгәннәр.

Күмәк табын һәм мул уңыш теләүдән тыш, шыйлык үз эченә сукага керешү йоласын да алган. Сукага чыгар алдыннан хуҗа хатын ат башына он сипкән. Кырга бөтен гаилә белән бергәләп чыкканнар. Җилпучка ипи, сөт, йомырка салганнар. Җир башыннан өч сажин буйга, бер сажин иңгә сукалаганнан соң, хуҗа тубалга орлык белән бергә йомыркалар салып, сукалаган җиргә сипкән. Соңыннан аны балалар җыеп алган.

Керәшен авылларында бу көнне мәйданда төрле ярышлар да узган. Әлеге ярышлар Сабан туе уеннары кебек уздырылган.

Удмуртиядә яшәүче татарлар язгы чәчү алдыннан кырга чыгып акашка, акатуй бәйрәме үткәргән. Акатуй күрше булып яшәүче башка халыкларга – мари, удмуртларга да хас булган. Чуашлар аны акатуй, марилар ага пайрам дип атаган. Акашка күмәкләшеп ботка пешерү рәвешендә уздырылган.

Халкыбызда сабанга, чәчүгә чыгу белән бәйле төрле ырымнар да яшәгән. Мәсәлән, чәчүгә чыккан көнне урамда ат алдыннан кеше уздырмаганнар. «Торып тор, аягың начар булмасын», – дигәннәр.

Игенне капчыкларга тутыргач, аның өстенә йомырка куйганнар. Йомырка шикелле, игеннәр тук, авыр булсын, дигәнне белдергән бу ырым. Гомумән, бу көнне йомыркага зур урын бирелгән – аны бүләк тә иткәннәр, җиргә дә чәчкәннәр, басуга да күмгәннәр, ашаганнар да...

Ике басу арасын – ызанны сукаларга ярамаган. Хозыр Ильяс йөри торган юл дип ышанганнар.

Чәчү башланган гына түгел, чәчү тәгәлләнгән көн дә зур бәйрәм саналган. Мәсәлән, Урал ягы татарларында бу көнне чәчү тәмамлап кайтучыларны су тулы чиләкләр белән каршы алып, баштанаяк коендырганнар. Уен-көлке башланган. Чәчүчеләр үзләре дә уенга катнашып киткән. Игеннәр яхшы үссен, яңгырлар вакытында яусын өчен үтәлгән йола булган ул.

Пенза татарлары чәчү тәмамлангач Йарилә бәйрәме үткәргән. Флера Баязитованың югарыда телгә алган китабында бу бәйрәмнең Пенза өлкәсендәге Каменски районы Решетино авылында уздырылуы билгеле. Борынгы славяннарда да Ярилка бәйрәме булуы мәгълүм. Ул – кояш алласы Ярила исеме белән бәйле, борынгы мәҗүсилек чорыннан калган йола. Бу көнне һәр йортта бәйрәм табыны корылган. Яшьләр урман уртасына җыелып, кичкә кадәр шунда төрле уеннар уйнаганнар. Шунысы кызык – Яриләдә дә, Сабан туендагы шикелле, уртадагы биек колга башына әтәч менгергәннәр. Колга башына кем беренче булып күтәрелә – әтәч шуныкы! Кичкә таба яшьләр авылда төрле шуклыклар кылган – кешеләрнең капка төпләренә иске арба яки чана куеп калдыра торган булганнар.

## *Келәүләр*

Никадәр көч түгеп сөргән, чәчкән җирдән мул уңыш аласы килү – игенченең табигый теләге. Вакытында яңгыр явуын, корылык, боз булмавын теләп, авыл халкы күмәкләп келәү әйтү, яңгыр сорау, корбан чалу йолаларын башкарган. Келәү – теләү дигән сүздән. Һәр йола төрле якта төрлечә аталса да, аларның максаты бер – игеннәрнең уңышы өчен яхшы шартлар сорау.

Ак алаша келәве, ашлык келәве, ил келәве, кыр келәве, яңгыр келәү... Бу йола күп җирдә кырда хайван чалып башкарылган. Келәүнең чишмә буенда дога кылып, су сибешү варианты да бар. Мөселманнар яңгыр сорап корбан чалган һәм бергә җыелып намаз укыган. Корбанга дигән акчаны авылда йорт саен җыйганнар. Кайчагында берәр хуҗалык аны үзеннән сәдака итеп тә биргән. Корбан ашына бала-чаганы, карт-корыны чакырып кунак иткәннәр.

Яңгыр сорап, халык күмәкләшеп казан аскан, өйрә пешергән. Яңгыр ашы, кереш ашы, корман ашы, җыен ашы дип аталган әлеге йола төрки халыкларның барысында да булган. Яңгыр ашын яздан пешермәсәң, җәй көне яңгыр яумый дип ышанганнар. Кеше саен йомырка, ярма җыеп, бер урында учак ягып, казанда күмәк ботка пешергәннәр. Сыйлангач, йоланың иң кызык өлеше – су сибеш башланган. Казан арты, Балтач якларында су сибешү чүлмәнчек дип аталган. *«Җаңгыр җау-җау, / Күктә болыт күп булсын, / Ашлык-тару күп уңсын, / Бар халык та тук булсын»,* – дип теләк теләгәннәр.

Дөбъяз якларында яңгыр теләп, җыен ашы уздырылган. Өйдән өйгә йөреп җыйган йомыркаларны чишмә буенда казанда пешергәннәр. Себер татарларында Сука боткасы пешерү йоласы булган. Мәчет янында узган ул.

Яңгырлар озаграк яумый торса, авыл ирләре зиратка барып намаз укыган. Өлкәннәр дә яңгыр намазы укыр өчен кырга чыккан. Ә балалар, бер-берсенә су сибешә-сибешә, такмак әйткән: *Яңгыр, яу, яңгыр, яу! / Без сорыйбыз Ходайдан / Арыштан, бодайдан, / Пәрәмәчтән-күмәчтән. / Сыерларның сөтләре аз булмасын, күп булсын. / Игеннәрнең башлары ач булмасын, тук булсын!*

Фото: ТАССРның Дөбъяз (хәзерге Биектау) районы Әлдермеш авылында язгы чәчү. 1930 нчы еллар. «Тартарика. Этнография» атласыннан («Феория» нәшрияты, Казан–Мәскәү, 2008 ел).

PRESSA

Ренат ХАРИС

# ТАТАР ЧИТЕГЕ

Поэма

*(Пролог урынына)*
– Нәрсә ул читек, дисәгез,
безнең читек – *эч итек*!
Тышкы итекләр кигәнбез
эчкесен оек итеп.
Тора-бара *эчитекнең*
баш авазы югалган,
(югалтуларга маһир без)
ул *читек* булып калган...

– Читек – эшче, юлчы, бүләк –
төшмәгән ил теленнән...
Хәзер нәрсә? Бии генә
бию ансамблендә...
– Заманга җигелә белми,
ә җигелмәгән килеш
бернине кузгатып булмый...
– Ә кем җигәргә тиеш?!.

* * *

Яшь чакта ул читек алдырмады –
бик картайта аны, янәсе...
«Лодочка»лар, «шпилька»лар алдым,
модныйларның да өр-яңасын...
Хәзер инде үзе читек сорый –
яшьләр белән, ахры, ярыша!
Мин шатланам эчтән, тыштан, юри,
картайта бит, димен, карышам.
Үҗәтләнә, ә кистереп әйтми –
кәкре атып туры тидерә.
Ап-ак чәчле җәмәгатем минем
мильон төрле дәлил китерә...
Куанычын авызлыклап тотып
йөрәктәге тулпар атымның,
читек академигы булган дип,
лекциясен тыңлыйм хатынның...

– Мең сигез йөз фәлән елда,
шаккаттырып чит илне,
алтын медаль алып кайткан
безнең татар читеге.
Парижда бит – дөньякүләм
күргәзмә үзәгендә!
Парижны[1] бизгәк тоткан, ди,
читекләр бизәгеннән!..
Лейпциг[1] немесләренең дә
читек алган һушларын,
Казанга күчеш башланган,
белгәч татарлар барын;
Дюма[2] да, имеш, Казанга
читекләр эзләп килгән –
читекне бүләк иткәннәр,
итекне алып кигән...

Мин әләктем бугай инде шулай
лектор салган матур кармакка –
үземдә дә сораулар ярала
чәчем астындагы чарлакта.
Нинди читек кигән Сөембикә?
Кемнәр теккән, кемнәр чиккәннәр?
Казан, Мәскәү, Касыйм музеенда
ник юк алар? Кая киткәннәр?
Нигә татар шундый саксыз икән –
тарихының белми кадерен...
Халык бит ул халык булып яши
озын булса гына хәтере...
Әби патша нинди бүләк алган
Иске бистә татарларыннан?
Ул чакта да Казан бай булган бит
читек-кәвеш осталарына!
Ул нигәдер татарны яраткан –
мәчетләрен күккә төбәткән...
Җир өстендә генә патша бит мин,
күккә Аллаһ хаким! – дип әйткән.
Мин уйларга бата-бата тыңлыйм,
чәй йоткалап, хуплап, баш кагам...
Татар читегенә шәп реклама
яңа дулкын булып башлана...

– «Война и мир» романында
Болконский да гелән
читектән. Аның читеге
көмеш белән чигелгән.
Толстой белгән татарны,
урыс кенәзләрен дә –
кенәзләр яраткан читек
киеп көязләнергә.
Тагын да тирәнгә керсәк,
күтәреп тарих читен,
Иван Грозный да кигән
каеп чигелгән читек!
Ул Курбский аягына
кадаганда таягын,
чигүле итек коткарган
воевода аягын.
Тирәнгәрәк, чоңгылгарак
чумсак тарих эченә,
тагын бер кат ышанырбыз
чиккән итек көченә.
Киев Русенең кенәзе,
ун артык гасыр элек,
Болгарны алмакчы булган
зур гаскәр белән килеп...
Добрыня Никитич әйткән
Кызыл Кояш кенәзгә:
болгарлар итек кигәннәр –
дань түләмәсләр безгә.
Киев, Болгар солых анты
эчкәннәр бер касәдән...
Аннары йөз елдан артык
чыгармаганнар сәбәп
сугышырга, кайтарырга
үткән талашлар үчен.
Менә нинди игелекле
читекнең магик көче!..
Мин мавыгып тыңлыйм хатынымны...
Кайсы фантазия? Кайсы чын?..

Ул үзенчә тарихны күзәтә,
лупа итеп читек кунычын!..
Хәтеремдә әле: дәү әнием,
күрше-күлән килеп керүгә,
самавырын, тизрәк кайнасын дип,
иске читек белән өрдерә...
Мин дә әйбәт читекне көйдердем
утлы самавырны өрдереп...
Татарларның шушы гадәтләре
зур җинаять белән бердер ул!..
Бүлдерәсе килеп тел кычыта,
кызыксыну җанны кыздыра.
Үз дигәнен дәлилләүдә хатын
Аристотельне дә уздыра,
чөнки акыл логикасына ул
куша белә хисләр давылын.
Җиңел хәл ителә җиңелүең –
аның тарафына авуың...
Ә чынында, мин бит үзем телим
аңа читек бүләк итәргә...
Ләкин, әйдә киттек кибеткә, дип,
лекцияне бүлү иртәрәк –
чөнки минем бер күрәсем килә

хатын логикасы җиңүен,
аның тантанасын!.. Һәм хатыным
хисси атакада! Чигенми!
– Безне хәзер «Көмеш гасыр»
геройлары урасын –
әйтик, Сергей Есенин һәм
аның Айседорасы[3].
Шагыйрь озак эзәрләгән
Айседора Дунканны –
һич эретә алмый икән
биюченең туң канын.
...Һәм бүләк иткән аңарга
саурый[4] үкчәле читек.

Күз ала алмый, ди, Дункан
читектән, исе китеп,
һәм шунда ук ауган да, ди,
Есенин кочагына...
Читек шундый – ут кабызган
мәхәббәт учагына!..

Хатын-кызга үҗәтлекне Ходай
тамызмаган, ахры, агызган –
ул, теләсә, суны суга ышкып,
океанда янгын кабыза.
Минем хатын, гүя Шәһрезадә[5]
сөйли арбап, сөйли бирелеп,
ишетеп торса аны, Шәһриярда
бетәр иде явыз кирелек.
Мин дә аны рәхәтләнеп тыңлыйм,
эчтән генә хәтта сокланам –
кайдан тапкан мондый мәгълүматны,
кайчан җыйган, нигә туплаган?!
Миннән читек алдырыр өченме?
Беркем юкса аны кысмады,
сапожкилар алган чакларда да,
читек алыйк, диеп, кыстадым.
Читек-кәвеш – авылым һөнәре,
шуның белән исем казанган,
итек-читек-кәвеш акчасына
китап, журнал кайткан Казмага.
Шулай итеп, читек-кәвеш безне
мәгърифәтле юлга бастырган...
Аһ, аяныч! Укымышлы кеше
туган авылында аз тора.
Читек-кәвеш тегә белгән минем
тырыш нәселемдә һәр кеше...
Мәскәү, Нижгар, хәтта Варшава да
яхшы белгән Казма кәвешен.
Патша Николай да белсә кирәк –
өч йөз елны бәйрәм иткәндә,
бүләккә дип, Казма осталары
аңа сафьян итек теккәннәр.
Пайтәхеткә итек барып җиткән!
Ә Зимнийга керә алганмы?
Шулхәтлесе генә миңа мәгълүм,
тарих кына белә калганын...

Мавыктыргыч хисләр дөньясына
ишек ачып кына өлгердем,
Шәһрезадәм, әкияттән чыгып,
уйларымны тагын бүлдерде...

– Парижларда, Лейпцигларда
татар читеге алган
алтын медальләр, мөгаен,
урланган йә югалган...
Медальләрен, әйткән дә юк,
рәсемнәрен дә хәтта
музейларда күреп булмый...
Борчыламын шул хакта.
Кайда хәзер ул медальләр?
Алар безнең горурлык –
Олимпия чемпионы
медаленә торырлык!
Бер уйласаң, күн итеккә
ниемә кирәк бизәк –
ул баса тирес-нәҗескә,
юлларда пычрак изә?!.
Читеккә бизәк кирәктер –
ул намазлыкка баса,
ә намазлык җәннәт багын
якынайта лабаса!..
Безнең акыллы элгәрләр,
җир рәнҗемәсен диеп,
хәтта сабанга чыкканнар
чигүле итек киеп...
Бу – кешенең Җир-анадан
ярлыкау соравыдыр,
бәлки, борчулы җанына
тынгылык юравыдыр.
Без дә Җирне күп таптадык...
Эзләр дә төрле-төрле...
Нигәдер башыма минем
читек кигән уй керде...

Үзем генә чыгып киттем дә мин
ЦУМда, ГУМда йөрдем эзләнеп.
Читекләр күп... Аларның берсен дә
сайламады зәвык бизмәнем.
Сөембикә киярлеге кая?
Әби патша моны киярме?
Мондый читек бүләк итә калса
Есенинны Дункан сөярме?..
Һәм Тукай да гүзәл Зәйтүнәгә
сайлар иде кайсы читекне?
Алыр иде микән Зәйтүнәсе,
ике так язмышны җөп итеп?..
Хәтеремә гүя яшен сукты
һәм яндырды Вакыт чаршавын...
Йөрәгемне сискәндерде кинәт
Печән Базарының бар шавы...
Кемдер кәҗә сата... Мин кемгәдер
чиккән читек, кәвеш сатышам...
Күзем төшә арбада утырган
бер малайга – моңлы Апушка...
Чиккән читекләрдән күзен алмый...
Ул да тиздән үсеп җитәчәк
һәм Газизә апасына шундый
матур читек бүләк итәчәк...
Ләкин «Асрамага бала бирәм!..»
дигән сүзләр китте яңгырап,
күкләр күкрәгәндәй... Һәм уйларым
әйләнделәр карлы яңгырга...

Хатынымның лекциясе минем
зәвыгымны тәмам болгаткан...
Бәлки, читек, нәрсәсендер җуйган,
йә читекне татар югалткан...
Һәм югалту дәвам итә бугай –
якташларым күреп кайталар:
чит илләрдә татар читекләрен
башка исем белән саталар...
Шундый хәлгә дучар Сабантуй да –
татарлыктан купкан кисемтә
булачак ул кемдер ЮНЕСКОда
теркәп куйса башка исемдә?..
...Минем өчен менә шундый булды
матур лекциянең файдасы...
Нәтиҗә шул: хатынымны, үзен,
алып чыгам – үзе сайласын,
кисен ханбикәләр кимәгәнне,
бөтен бәйрәмнәрдә катнашсын!
Ул бит минем иҗат ханлыгымның
тәхет тоткан әби-патшасы!

*(Эпилог)*

– Менә шундый безнең читек –
чәмчәләп[6] *чиккән итек*:
саурый үкчә, казан җөе!
Карыйсың исең китеп...
Бер хәрефе генә түгел,
биш хәрефе югалган,
(хәреф түгел, илне җуйдык)
ул *читек* булып калган...
– Ике сүз кушылган чакта
югала сүзнең берсе...
– Алай түгел! Ул чагында
ярала яңа бер сүз!..
– Килешми безгә хәреф һәм
сүз югалтуны аклау –
сүзне саклаудан башлана
телне һәм илне саклау!

---

[1] Парижда (1883), Лейпцигта (1886) Халыкара ярминкәләрдә татар читеге алтын медаль яулый.
[2] А. Дюма Казанда 1858 елда була.
[3] С. Есенинның хатыны, АКШ биючесе, шагыйрьдән 18 яшькә өлкәнрәк була.
[4] Саурый – атның сырт (савыр) тиресеннән эшләнгән күн.
[5] Шәһрезадә, Шәһрияр – «Мең дә бер кичә» әкияте персонажлары.
[6] Чәмчә – күнгә каеп төшерелгән бизәк.





# ӘЛЛӘ НИГӘ СИНЕ ЮКСЫНАМ...



Гүзәл ӘДҺӘМ

(Хикәя)

Мәңге туктамастай булып куйган көзге яңгыр түбә калайларын берөзлексез төйде. Нурия әле тегеләй, әле болай борылып ятты, йә мендәрен рәтләгәндәй итте, әмма күңелгә кереп оялаган пошыну халәтеннән арынып йокыга китә алмый җәфаланды.

Нигә болай борсалана соң ул? Шул тамчыларның бетмәс-төкәнмәс шыбырдашуы нигә шулай эчен пошыра? Югыйсә өйалдындагы бу агач караватэлек-электән Нуриянең иң яраткан урыны булды. Салкынча һавада йоклау ошыйрак төшә иде аңа. Яраткан иреңнең җылысына уралып, аның шундый якында, янәшәдә генә булу рәхәтлегеннән оеп, мамык юрганнан борыныңның очын гына күрсәтеп йоклауга ни җитә соң!

Кар сулары агып, көннәр җылына башлауга, алар һәр елны Харис белән шушы караватка күченәләр иде. Кайнанасы Халисә яшьләрнең бу гамәлләрен ошатмыйча, авыз эченнән гел мыгырданып йөрер:

– Дүрт бүлмәгә сыймас кеше була димени? Бүлмә саен – болын хәтле караваt. Аларга шул тактасы кадерлерәк... Салкыннар тидерерсез инде шул суык өйалларында!

...Хатын сулкылдап куйды. Тәнендәге һәр күзәнәккә, һәр чәч бөртегенә тәгаенләгәндәй, берөзлексез тып та тып шыбырдаган яңгыр тавышыннан котылырга теләп, юрганын баштанаяк ябынды. Аның шул тыпылдаулардан арынасы, сагынылган элекке тынлык рәхәтенә чумып иркәләнәсе килеп китте. Бермәлгә юрган асты дөньясы чынлап та тып-тын булып калды. Уйланырга һәм хыялланырга да, үрсәләнеп үртәлергә дә комачауламастай сәер бер тынлык иде бу. Тик Нуриянең җанына мондый тынычлыкның бер тиенгә дә кирәге юк! Нәрсәгә ди аңа бу тынлык? Булмасын иде ул! Кирәге юк! Шул чакта хатын үзенең ялгышуын, исемен дә әйтергә теләмәгән бөтенләй үзгә бер халәтне тынлык белән бутавын төшенеп алды. Ул халәт... Ул халәт... «ялгызлык» дип атала иде. Үткәндә калган бәхетле хатирәләр белән дә тутырып булмастай шыксыз бушлык икән бит ул – ялгызлык дигән нәрсә!

Харисның үлеме шундый көтмәгәндә-уйламаганда булды ки, хатын үзенең яңа халәтенә төшенә алмый йөдәде. Йөрәк, диделәр... Йө-рә-ә-әк...

Көннәр, айлар үтте... Ел да тулып узды... Нурия шактый озак Хариссыз тормышка күнегә алмыйча, күңеле дә, җаны да Хариссыз дөньяны танырга теләми изаланды. Ире элек тә командировкаларга еш йөргәнлектән, Харисның юклыгын ул баштарак вакытлыча бер халәт дип кабул итеп, үзен шуңа ышандырырга тырышты бугай...

«Әллә нигә сине юксынам...» – дип пышылдады ул җәйге иртәләрдә...

«Әллә нигә сине сагынам...» – дип көйләде буранлы таңнарда...

Нурия кинәт үзенең юрган астында җырлап ятуын искәреп, дертләп куйды. «Туктале, нигә шулай үрсәләнә соң ул? Югыйсә бүген дә, нәкъ башка көннәрдәй бер көн – Хариссыз көн! – үтте түгелме соң? Дөньяның инде Харистан башка гына агышына күңеле белән ризалашып, шул чарасызлыкка күнегеп киләм дигәндә генә!» Җан түреннән ниндидер бер аваз: «Түгел! Түгел!» – дип пышылдады.

Бүген гадәти көн түгел иде шул! Нәкъ менә бүген Хариссыз дөнья үзенең шыксызлыгы һәм җанөшеткеч шәрәлеге белән аларның йортына бәреп керде. Улы Раил үзенең сөйгән кызы белән кайткач! «Кыз күрсәтергә» дип атала мондый кайтулар. Харисы да янда булса, чып-чын бәйрәмгә

әвереләсе көн ләбаса. Бүген – күр инде: йорттагы биш кеше, бишесе дә борсаланып, йокыга китә алмый изалана: кайнана белән кайната, Раил үзе, Рәмзия атлы теге кыз бала...

«Әллә нигә сине юксына-а-а-ам...»

«Карале, бу җырның күңелгә кереп оялавын күрче! Әллә кайдан, җан түреннән үк калкып чыга да аваз сала, калкый да аваз сала... Яңгырын әйтер идем, туктый да белмәде, ичмасам! Шык та шык итеп, бәгыренә тама да тора...»

«Әллә нигә сине юксына-а-а-ам...»

Ниндидер үзгә бер тавыштан Нурия кинәт сискәнеп китте.

«Әллә капка ачылды инде? Их, ачылсын иде дә...»

«Әллә нигә сине юксына-а-а-ам...»

Кемдер ишек шакыды. Ниндидер таныш түгел бер зат аларның төн йокысын бүләргә җөрьәт иткән. Белгән-күргән таныш кеше булса, кыңгырауга басар иде дә, ә бу – кага, берөзлексез «дык» та «дык» ишек дөбердәтә.

Нурия, сискәнеп, аягүрә басты, чыгарга да, чыкмаска да белми, бер урында таптанып торды. Караңгы төшкәч, ишек ачарга ир-ат чыгу гадәткә кергән иде. Бүген никтер кайнанасы аякка баскан.

– ...Кем соң син?

– Рүзилә мин... Наил хатыны...

Нурия шым булды. Башын гел бер сорау бораулады:

«Наил хатыны? Рүзилә? Гомер-гомергә бу йортка аяк басмаган хатынга ни кирәк?»

Кинәт хәтер түрен ертып, беркөнне ишеткән хәбәр калкып чыкты:

– Наилгә Казан бальнисында операция ясаганнар... Ачып кына япканнар, ди...

«Ачып кына япканнар?»

Бу – иң куркыныч, шомлы диагноз. Моннан да яманрагы була алмый. Димәк, Наилдә яман чир икән...

Кайнанасы инде тышкы ишекне ачкан, Рүзилә белән ни турындадыр бәхәсләшеп маташуы:

– Илдә булмаган хәл! Юкны сөйләмә!

– Мин нишли алам соң?

Хатын мышык-мышык борын тартты.

– Нурияне күрәсем килә, ди бит! Атна-ун көннән артык тормас, ди врачлар... Күпме гомере калгандыр...

Нурия торараштай катып калды.

Наилнең аны күрәсе килә! Күпме вакытлар узгач... Инде барысы да үткәндә калды, онытылды дигәндә... Шул Наил аркасында бит инде Харис белән тормышлары әздән генә җимерелми калды. Ярый әле ул чакта кайнатасы акыллы булып чыкты. Бөтен кызган җаннарны бер сүзе белән суытты да куйды.

Хатын, калтырап, стенага сыенды...

...Нәкъ егерме биш ел элек юллама буенча килде Нурия бу авылга. Яңа гына педучилище бетергән 19 яшьлек кыз иде ул чакта. Фатирга Шәмсиягә керттеләр үзен.

– Бик чиста, тәртипле хатын. Өе дә зур, малае белән генә тора, – диделәр.

Шәмсияне ул бер күрүдә үк ошатты. Ике сүзнең берендә «и-и-и, җаныем»ны кыстырып сөйләүче бу хатынның, инде 65 не узуга карамастан, һаман да хат ташучы булып эшләп йөргән көннәре. Үзе – түм-түгәрәк, юантык, үзе гаҗәеп җитез бер хатын иде ул.

«Малае» дигәне – шул Наил булып чыкты: кечкенә генә буйлы, сипкелле генә бер үсмер. Шәмсия үзенең улын әллә нинди сәер бер мәхәббәт белән ярата иде. Инде «мыек чыгып килгән» Наилне, кеше бар дип тә тормый, кочаклап алып шапылдатып сөюләр, бит уртасыннан чупылдатып үбеп алулар дисеңме... Үзе гел бер сүзне кабатлар:

– И-и-и, җаныем, 49 да тапкан улым бит ул минем!

Шәмсиянең башка балалары, барысы да кызлар булып, инде күптән әниләре кебек түм-түгәрәк юантык хатыннарга әйләнеп беткәннәр. Ял җитте исә әле берсе, әле икенчесе килеп, ярдәм итеп, хәл белеп китәргә гадәтләнгәннәр. Дөрес, йорт эшләренә Наил үзе дә кызларга биргесез, көянтә-чиләкләп су ташырга, идән-сайгакларны юарга да тартынып тормый. Күрше авылга йөреп, сигезенче классны бетергән дә, колхоздагы машина паркында эшләп йөрүе.

Нурия белән Наил беренче көннән үк дуслашып алдылар, энеседәй якын күрде ул бу малайны. Мәктәптә укулар башлангач, бу дуслык тагын да ныгый төште. Авылда башлангыч мәктәп кенә булып, Нурияне беренче класска билгеләгәннәр иде. Тик көтмәгәндә-уйламаганда, тагын бер йөкләмә тагып куйдылар үзенә: күрше авылда кечкә мәктәпкә тарих-география укытучылары җитешми икән.

– Минем әлегә бер тәҗрибәм дә юк, институтка да быел гына читтән торып укырга кердем, – дип тартышып карады кыз.

Аны кем тыңлап торсын, ди: «Укытырга тек – укытырга!» Мәктәбе – күрше авылда шул, ике араны – төгәл бер чакрым, диләр. Ризалашмый да ярамый.

Мәсьәләне Нурия урынына Шәмсия хәл итте дә куйды:

– И-и-и, җаныем, яшь кешегә бер чакрым – нәрсә ул! Барыр, барыр, бармый ни, имә, җаныем? Гимнастика булыр үзенә...

Менә шул. Дәресләр саны әллә ни күп түгел икән, атнага өч көн күрше авылга тәпиләргә тиеш булып чыкты Нурия.

– Апаңа иптәш булырсың – син дә бар! Ничу монда шалтай-балтай йөрергә, – дип, улы Наилгә дә приказны биреп куйды Шәмсия.

Әни сүзенә каршы әйтү гадәте юк иде бу йортта.

Әллә ни сүзчән булмаса да, шактый төпле үсмер икән бу Шәмсиянең «49 да тапкан!» малае. Ике авыл арасын бергә-бергә күп таптады алар. Әнә шунда Нурия искитмәле бер яңалык ачты: Наил шигырьләр яза икән! Баштарак ул аны Нуриядән яшерергә тырышты:

– Каяндыр күчереп алган идем, авторын белмим, – дип алдап та маташты әле...

*«Мин сине яраткан шикелле,*
*Ятратмам беркемне беркайчан,*
*Синең күзләрең шикелле*
*Күзләрне очратмам һичкайчан...»*





Кыз үзе дә, үсмернең читенсенүен тоеп, авторларын сорап бүтән тинтерәтмәде, эчтән генә елмаеп, яңадан-яңа шигырьләрен тыңлый бирде. «Мин булсам, болайрак язар идем», – дип, киңәшләр дә биргән булды әле.

Әнә шул малайның бер сәер гадәте барлыкка килде: сөйләшкәндә-аралашканда карашын гел читкә бора торган үсмер, дәрес вакытында укытучы апасына томырылып-төбәп карап, кызны оялта торганга әйләнде. Туп-туры карый да дөньясын оныта... Ә Нурия нишләргә тиеш? «Миңа карама!» – дип, үз укучысына бәйләнә алмый ла! Шул үсмернең карашыннан, сөйлисе сүзен онытып, тотлыгып-буталып калган чаклары да булгалады аның. «Инде әйтәм, дәрес вакытында миңа карап утырма, диячәкмен!» – дип тәгаенләгән бер көндә, Наилгә военкоматтан чакыру килеп төште. Буйга кечкенә малай сыман булса да, егетебезгә унсигез тулган лабаса!

Шәмсия үзенең «49 да тапкан малае» белән бик авыр хушлашты. Хатынның «и-и-и, жаныем!» дип уфылдауларын сабыр гына тыңлап җиткерергә үзендә көч тапты Нурия. Аннары Наилдән хатлар килә башлады. Әнисенә дә шулай еш язгандырмы, Нурия анысын белми, ә менә кызның үзенә атнасына өч-дүрттән дә кимрәк хат килмәгәндер. Авылда чакта гел «Нурия апа!» дип дәшкән егет хатларында «Нурия!» дип кенә җибәрә хәзер. Бу хатларны кызга Шәмсия үзе тапшыра иде. Әллә нинди сәер, аналарча йомшак елмаю белән:

– И-и-и, жаныем, сиңа хат бар... – ди дә, үзәкне өзгеч җылы тавыш белән, – «кызым!» – дип тә өстәп куя.

Нурия андый чакларда «дерт» итә. Егетнең хатларын җавапсыз калдырмаска тырыша ул. Кыз озаграк җавап язмый торган чакларда, Шәмсиянең «И-и-и, жаныем!»-нары тагын да арта төшә:

– Армиядә чакта, берәрсеннән хат килсә, бәйрәм була инде ул, диләр, и-и-и, жаныем...

«Үзе хат ташучы булгач, барысын да белеп тора. Мин исә, җавап яздым, дип алдаша алмыйм, ичмасам!»

...Шул язда армиядән Харис кайтып төште. Нуриягә әллә ни булды. Аның әле берәү белән дә яратышып йөргәне юк иде, Харис аның бөтен күңелен яулап алды. Бик рәхәт, бик тә, бик тә рәхәт иде аңа Харис янәшәсендә. Көзен шау-гөр китереп туй үткәрделәр дә, Нурия аръякка килен булып төшкәнен сизми дә калды. Армиядә Наил атлы бер үсмер барлыгын яшь килен бөтенләй исеннән чыгарып җибәрде ул чакта.

...Шәмсия Нурияне дәресеннән чакырып чыгарды.

– И-и-и, жаныем, сагынып беттем үзеңне, – дип, бермәл яшь хатынны кочагына кысып торды. Аннары әллә нинди еламсыраган тавыш белән:

– Улыма ник хат язмыйсың? – дип тә өстәде.

Нурия аптырап китте:

– Соң, Шәмсия апа, бәгырем, мин кияүгә чыктым бит... Харис әллә ни уйлар...

– И-и-и, жаныем, чыксаң ни...

– Наилгә дә бу турыда күптән язып салдым...

Шәмсия эчке кесәсеннән бер конверт тартып чыгарды:

– Наил белми... Хатыңны җибәрмәдем...

Нурия шаккатты.

– Барыбер беләчәк бит, Шәмсия апа! Нигә яшерергә инде?

– Син хат язуыңны бел. Калганы – минем эш! 49 да тапкан улым ул минем!

...Солдат хатларын Шәмсия мәктәпкә китереп бирә башлады. Китерә дә:

– И-и-и, жаныем, рәхмәт инде сиңа... кызым, – дип пышылдый.

Бервакыт елый-елый шешенеп беткән Шәмсияне күреп, Нуриянең коты очты:

– Ни булды?

– Өч атнадан артты! Малайдан бер хәбәр дә юк!

– Уф! Котымны алдың, Шәмсия апа! Нәрсә булды икән дип торам. Наил диңгез флотында хезмәт итә бит...

– Булса ни...

– Соңгы хатында «учениегә китәбез!» дип язды лабаса. Алар кораблары белән диңгездә! Аңлыйсыңмы – диңгездә! Тиз генә хаты килмәс әле, борчылма син...

Шәмсия елый-елый өенә юнәлде. Әллә шатлыктан, әллә диңгез куркынычы янаган улы өчен күз яше түкте – белмәссең.

Ике айдан бер төргәк хат күтәреп килде ул. Төп-төгәл илле хат!

– И-и-и, жаныем, сиңа хат бар... кызым!

Конверт тышына Шәмсия кулы белән «бер», «ике», «өч» дип, саннар куелып, хатлар тәртип буенча тезелгән, буталмасын өчен, җеп белән бәйләп тә куелган иде. Илле хатның да мөһерләре бертөрле. Димәк, Наил диңгездә чакта да аңа һәр көнне диярлек хат юллаган, ярга чыккач, барысын бер үк көндә почта тартмасына салган. Ә менә хатларның язылу тәртибен Шәмсия каян белгән диген?

Кыска гына, җыйнак, гадәти хатлар... Бернинди ярату, мәхәббәт сүзләре дә юк анда. Соңгы җөмләләре генә гел бертөрле тәмамлана:

«Әллә нигә сине юксынам...»

Армиягә китүенә елдан арткач, Наил үзе ялга кайтып төшмәгән булса, бу хат язышулар күпмегә кадәр сузылыр иде – белгән юк.

Нурия инде ул чакта декрет ялына чыккан иде. Район үзәгендә йөргәндә нindидер озын буйлы, зур, таза солдат аны күтәреп алды да зыр-зыр әйләндерә дә башлады. Нурия куркудан телсез-авызсыз калып, күзләрен чытырдатып йомды. Аяклары белән «дык» итеп асфальтка бастырып куйгач та, бермәл күзен ачарга куркып торды әле.

Ачса – шаккатты: зур, таза солдат дигәне – Наил икән лабаса! Авызын колагына кадәр ерып, битендәге сипкелләрен балкытып торуын күр син! «Солдат ипие үстерә» дигәннәре шушы була икән! Егет очрашу шатлыгыннан шундый дулкынланган, «Нурия!» дә «Нурия!» дип, аның бер алдына, бер артына төште. Нуриянең шактый калынайган гәүдәсенә баштарак игътибар да итмәде ул, бертуктамый сөйләнүен белде. Кинәт, нәрсәдер сизенеп, әллә нишләп китте. Кызның уң кулын чытырдатып кысып алды да, бер – атсыз бармактагы балдакка, бер – аның күзләренә карап тораташтай катты. Егетнең күзлә-

ре үтә күренмәле яшь элпәсе белән каплана баруын Нурия шундый якыннан күрде ки, менә теге элпә түбәнгә җыелды, бераздан яшь бөртегенә төенләнде дә, керфекләрен чылатып, бите буйлап түбән тәгәрәде. Кызның күзен дә әллә нәрсә ачыттырып куйды. Нурия күзләрен сыпырган арада, егеттән җилләр искән иде инде...

Тик Наил алай тиз генә югалмады әле. Кичен абзарда мал карап, сыер савып йөргән Нурияне саклап торып котын очырды:

– Ник мине көтмәдең? – дип, янагандай итте хәтта.

– Наил, акыллым... – дип ялынган Нурияның ай-ваена карамыйча, яшь хатынны кочаклап ук алды.

– Мин сине барыбер урлыйм! – дип ярсыды солдат егет, ычкынырга тырышкан хатынның кулларын каерып.

Эшләр харап иде. Кеше ишетүеннән шикләнеп, баштарак шыпырт кына ялварган Нурия куркуыннан кычкыра ук башлады. Тавышка кайнанасы йөгереп чыкты. Аңа тагын кайната да иярмәгән булса, вакыйга ни белән тәмамланыр иде, белгән юк. Китте шау-шу, ызгыш... Шул чакта эштән кайтып җитешкән Харисы да килеп өстәлде, Наилнең: «Мин аны барыбер урлыйм!» – дип, бертуктамый кабатлап торуына чыдый алмый, солдатны бәргәли дә башлады. Тынсыз-өнсез булып стенага сеңгән Нуриянең барлыгын бермәлгә барысы да онытып җибәрде бугай. Һушларына килгәндә Нурия инде, ыңгырашып, абзар идәненә ауган иде. Иң башта кайната айныды:

– Туктыйсызмы, юкмы? Җитте сезгә! – дип, Харис белән Наилнең икесен ике якка селтәп җибәрде.

Аннан:

– Мәхәббәткә маңка мишәйт итми, диләр, – дип, Нурияне җиңел генә күтәреп алды да өйгә юнәлде.

Абзардагылар ул чакта әнә шулай тиз суынды. Иртәгесен Нурияне бәби табу йортына алып киттеләр. Ул әни булды...


...Ул чакта кайната киленне гаепсез дип табып, өйдәгеләрне бик нык кисәткән иде, ахры. Бу вакыйга турында хәтергә алмаска килешенгәнгә, Наил исеме йортта бервакытта да кабатланмады.

Нуриянең улы бик елак булды, әнисен яныннан да җибәрми интектерде. Бәби мәшәкатьләренә чумган Нурия Шәмсиянең үлеме турындагы хәбәрне карчыкның инде җидесе узгач кына ишетеп шаккатты.

– Шәмсияне балалары бик олылады. Сәдаканы да бик зурдан тараттылар. Солдат улы да үзенең армиясенә әнисе каберенә ташын куеп, чардуганын коргач кына китте... – дип сөйләделәр авылда.

Шәмсиянең шулай көтмәгәндә-уйламаганда үлеп куюына Нурия никтер үзен дә гаепле тойды:

«Нигә шулай килеп чыкты соң? Аның бит күңеле гел яхшылыкта булды. Берәүне дә рәнҗетәсе, үпкәләтәсе


Рәсем: Наталья Васильева





килмәгән иде!» Ике күкрәк арасын нәрсәдер авырттырып тырнады, йөрәк үзе дә, сулык-сулык итеп, күпмедер сызланып йөрде әле...

...Гомер үтә торды. Шәмсия, Наил турындагы хатирәләр инде онытылды дигәндә, тагын бер хәбәр Нуриянең тынычлыгын бозды.

– Шәмсиянең Наиле авылга бөтенләйгә кайткан, ди...

– Кайчан гына орчык буе малай иде, хәзер үзе өч бала атасы икән!

– Хатыны бик чибәр икән... Башкорт ягыннан ди.

Күп тә үтмәде, Шәмсиянең шактый искерә төшкән йорты урынында менә дигән таш пулат калкып чыкты. Бер авылда яшәгәч, күрешми ни чара дигәндәй, буранлы кышкы кичтә районнан җыелыштан кайтучы Нурияне Наил, туктатып, машинасына утыртты. Наил бик үзгәргән, тагын да зурайган, битендәге сипкелләре дә каядыр җуелып, үзе шактый олыгайган иде.

– Менә тагын очраштык, Нурия!

Нурия үзен тыныч тотарга ни тырышса да, йөрәгенең дөпелдәвенә һәм тавышының калтырап чыгуына да хуҗа була алмады. Алар шактый юлны сүзсез генә үттеләр.

– Мин сине кайчан ярата башладым, беләсеңме?

Нурия «дерт» итте. Теге чакта сыер абзарында булган вакыйга исенә төшеп, машинаның ишегенә сыена төште. Әмма Наил шундый тыныч, үзалдында елмайган килеш кышкы юлга төбәлгән дә сөйли бирә:

– Кичке мәктәпкә күрше авылга йөргәнне хәтерлисеңме? Мин синең өчен генә бардым анда. Сиңа карыйм да, хыялланып тик утырам. Син шундый чибәр, зифа буйлы матур кыз. Ә мин – карсак малай, җитмәсә, сипкелле дә. Ул чакта сиңа яратуымны белдерсәм, син хурланырсың дип курыктым. Көлүен көлмәс идең анысы, син андый түгел идең...

Нурия дә, тынычлана төшеп, машина тәрәзәсе каршында биешкән кар бөртекләрен күзәтте.

– Армиядә чакта язган хатларың өчен рәхмәт сиңа... Бервакыт өч ай учениедә булдык. Күз алдына китерәсеңме? Өч ай буе – су төбендә! Беренче тапкыр бит! Кайбер егетләргә психолог ярдәме дә кирәк булды хәтта. Ә мин сине уйлыйм да учениедән соң вәгъдә ителгән отпуск турында хыялланам. Мин ул чакта буйга үскән идем инде. Бер ел эчендә егерме биш сантиметрга үстем, аңлыйсыңмы? Менә кайтам да, «мин сине яратам!» дип, курыкмыйча әйтәм, дим... Синең кияүгә чыкканыңны белгәч, никтер син бәхетсездер кебек тоелдың... Барыбер урлыйм! – дип, үземә сүз бирдем. Урлыйм да – бәхетле итәм!

Нуриянең йөрәге кысылып куйды, сулыш алырга да куркып, тынып калды. Күңелдә бер уй: «Никләргә утырдым аның машинасына?»

Ә Наил буранлы юлдан күзен дә алмый, иреннәре елмайган, үзе сөйли дә сөйли:

– Әнине җирләгәч, атна буе авылда тордым. Шул чакта мин сине урлау планын кордым. Барыбер бер чыкмый калмас дип, өегез янында төн буе сакладым. Урлап китәм дә, бәхетле итәм, имеш. Шунда мин сезнең өйалдында йоклаганны абайлап алдым. Шундый якында, янәшәдә генә! Такта стенаның теге ягында! Стенага сеңеп, сезне тыңлый башладым... Шунда мин искитмәле бер ачыш ясадым: син бәхетле идең! Аңлыйсыңмы? Син шундый бәхетле идең! Мин, бары тик мин генә бәхетле итә алам дип хыялланган кыз – инде бәхетле...

...Яңа уку елы башланыр алдыннан Нурия, кулына исемлек тотып, беренче классларны барларга чыкты.

«Закиров Шамил Наилевич»... Бу – Наилнең улы иде.

Нурия тәрәзә төпләрендә гөлләр балкып утырган зур матур йортның ишегалдына үтте. Ишек бикле булмаса да, кыңгырауга басуны кирәк санады ул. Береаздан теге якта аяк тавышлары ишетелде. Инде килеп җитте, ишекне менә ача дигәндә генә, ишек «дык» итеп ябылды да, кемдер аңа эчке якта бик салып өлгерде. Нурия, аптырап, кыңгырауга тагын, тагын басып карады, соңрак тәрәзәгә күз төшерде. Челтәр пәрдә читеннән үзенә туп-туры төбәлеп торган чибәр хатынның уттай күз карашы белән очрашкач, калтырап куйды...

Бу хәл тагын берничә тапкыр шулай кабатланды. Наил хатыны аңа бервакытта да ишек ачмады, өенә дә кертмәде. Юллары туры килгәндә дә, Нурия белән очрашмас өчен, урамның каршы ягына чыгып үтә иде ул.

Ә малайлар бер-бер артлы мәктәпкә килә торды. Өч ел укытып, берсен күрше авыл мәктәбенә озатуга, аннан кечерәге беренче класска килеп керә, аннары – өченчесе... Кечкенә буйлы, сипкелле малайлар, аз сүзле булсалар да, яхшы укыды, мәктәптәге җыелышларга гел әтиләре йөрде аларның. Наилнең үзенә туп-туры төбәлгән карашыннан, Нуриянең еш кына сүзләре буталган чаклар да була иде...

...Ә бүген алар бусагасында – шул хатын! Рүзилә!

– Үлем хәлендәге кешенең теләге бит, апа!

– Булса!

Кайнана каты торды.

Рүзилә аның саен ялварды:

– Нурияне күрәсем килә, ди! Әллә нигә шуны юксынам, ди!

Нурия калтырый ук башлады.

Күңелдәге теге моң да: «Әллә нигә сине юксына-а-а-ам...» – дип ыңгырашты.

– Нурияне җибәрмим! Гомердә булмаганны!

Шунда өйалды идәне усал шыгырдады.

– Холыксызланма!

Кайнатаның кинәт яңгыраган тавышыннан әллә теге моң да калтырап куйды инде?

«Әллә нигә сине юксына-а-а-ам...»

– Нурия кызым! Бар, бәхилләш Наил белән!

Нурия чаршау артыннан алар янына чыкты. Биш пар күз аңа төбәлгән иде. Улы Раил белән булачак киленнең аптыраулы карашы астында ул ашык-пошык плащын өстенә киде...

...Көзге яңгыр туктауны белми койды да койды. Ике хатын, лычкылдык пычракны ерып, төн караңгылыгына кереп югалды. Тайгак җирләрдә егылмас өчен, бер-берсенә тотынышып, сүзсез генә атлады алар. Күңелләре иртәгә туачак таңны Рүзиләнең дә тол хатын булып каршылыйсын сизенсә дә, йөрәкләре шул котылгысыз дөреслекне танырга теләми бәргәләнә иде...

# АЛДАШУ



Марат
КӘБИРОВ,
язучы

Гомеренең иң матур елларын совет чорында уздырып, җаннары белән шунда торып калган кешеләр бар. Алар партия дип утка керергә атлыгып тормый инде, әмма күңелләрендә гаделлек тойгысы, кешелеклелек төшенчәсе сакланып калган. Әлеге заман белән килешеп яшәргә тырышсалар да, еш кына төрле матавыкларга тап булалар. Шундыйларның берсе – минем әни. Ул хәтта акча чутын да элеккечәрәк исәпли. Йөз сум аның өчен бик зур акча булып тоела. Шуңа күрә меңлекне йөз сум дип йөртә. Акча чутлый башласаң, аның белән буталып бетәсең.

Менә шул гадәте сәбәпче булгандыр инде… Хәер, баштанрак башлыйм әле. Мин ул көнне каен бөресенә дип урманга киткән идем. Кайтып төшүемә, юлда безнең капка тәңгәлендә бер машина тора. Игътибар бирмәдем инде, ихатага уздым. Каен бөресен сәндерәгә киптерергә куеп, өйгә атлаганда капкадан бер хатын чыгып киткәнен күрдем. Моңа да артык игътибар итеп тормадым. Инәй янына күрше-күлән дә, шәһәрдән кайтучылар да кереп-чыгып йөри. Сөйләшеп чәйләп тә утыралар. Аларның үз дөньясы. Барысына да кысылып йөреп булмый бит инде. Бу юлы да карап кына куйдым да оныттым.

Бераздан өйгә керсәм, әни өстәл янында ниндидер тавыкны урнаштырып маташа:

– Шулхәтле хакка сатып, җонын да юньләп тазартмаганнар, – дип чәйнәнә үзе.

– Нәрсә зарланып йөрисең анда? – дигән булам.

– Менә, тавык сатып алдым әле, – ди әни, өстәл өстендәге табакка күрсәтеп. – Күркә хәтле бар.

Тавык чынлап та зур гына, чынлап та күркә хәтле. Шуңа мин хакын белешәм.

– Дүрт мең булды бөтенесе, – ди әни. – Бишкә бирәсе иде, бер меңне чигерде.

Тавык зур, әлбәттә. Әмма барыбер дүрт мең була алмый бит инде. Безнең якта ул суммага чүт кенә өстәсәң, сарык та алырга була. Мөгаен, ялгыша торгандыр.

– Дүрт йөздер ул, – дим, шелтәле шаянлык белән. – Син гел бутыйсың инде.

– Юк, улым, бутамыйм. Дүрт мең. Менә монда үзең ун мең калдырган идең бит, шуннан алып түләдем. Ышанмасаң, чутлап кара.

Мин әлбәттә, ышанмадым һәм чутлап карадым. Чынлап та! Әни дүрт меңгә бер тавык сатып алган. И-и карт кеше… И-и… Мин артык хискә бирелеп тормадым, китеп өлгермәсәләр дип, урамга атылып чыктым. Эзләре суынган иде. Шулай да ачу килү басылмады. Кайсыдыр юньсезе чит авылга килеп туксанга якынлашкан корткаsuccessfully алдап киткән. Аңлыйм инде мин, заманы шундыйрак. Кешеләргә акча кирәк. Әмма ул акчаны әбиләрне алдамыйча да эшләп була.

Өйгә кердем. Әни аш салырга маташып йөри. «Алдаганнар бит сине, әни. Бу тавык бит ул кадәр бәя тормый», – дип әйтмәдем инде. Алдану – бер нәрсә, алдануыңны аңлау – икенче. Икенчесе күпкә авыррак. Ул авырлыкны инәй кешегә йөкләү мәҗбүри түгел бит инде. «Бигрәк олы тавык булган бу!» – дип, күңелен күтәрергә азапландым.

Ләкин нәфрәт югалмады. Теге хатынны табып, кирәген кигезү теләге юкка чыкмады. Авыл җире ич инде бу, кемгә кем кергәнен белеп торалар. Шуңа аны табу кыен булмады. Тагын бер-ике күршегә тавыктыр-үрдәктер сатып чыккан әле ул. Аларын алдый алмаган инде, яшьрәкләр бит. Башта машина маркасын, шуннан номерын әйттеләр. Аннан соң инде кем икәнен, адресын табу кыен эш түгел.

Мин бик сиздермәскә тырышсам да, күршеләргә кергәч, инәй үзенең алдануын белеп чыккан:

– Биш йөзгә алганнар. Шул ук тавык. Миңа дүрт меңгә сатты, оятсыз!

Хәзер инде мин дә яшереп тормадым.

– Кайда торганнарын белештем. Барып иманнарын укытып кайтам әле.

– Йөри күрмә, балам, – дип карышты әни һәм минем тыңларга җыенмавымны күреп, өстәп куйды. – Ризалыгым юк. Ике аягыңның берсен дә атлама. Ходай җәзалар. Сиңа ризалыгым юк.

Нишлисең инде. Шулай өзгәләнеп әйткән сүзен дә тыңламасаң, рәнҗеткән кебек була. Йөрмәдем. Суындым. Вакыт үтә торды. Җәй уртасы җитте. Күп нәрсәләр онытылды, онытылмаганнарына кул селтәдем. Шулай да бер мәлне күрше районга баргач, теге авылга сугылып чыгарга булдым. Авыл урамына кереп, йортларын сорагач, бер апа:

– Хәзер монда тормыйлар бит, – дип көрсенеп куйды. – Яшен сукты аларны. Ирен җирләдек, хатынын балалары алып китте. Урын өстендә ята.

– Яшен? – дип аптыравымны үзем дә сизми калдым, ә апа шундук эләктереп алды.

– Әйе. Хан сарае кебек дөнья җиткергәннәр иде, барысы да янып бетте. – Һәм минем ни әйтергә белми торуымны күреп, өстәп куйды. – Хәрам байлык бәхет китерми шул.

Мин сүзсез генә юлга кузгалдым. Кайбер нәрсәләр турында бер сүз дә әйтеп булмый. Бәлки, кирәкмидер дә.



яшәеш

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

*Бөек Җиңү көне якынлашкан саен, күңел яралары кабат кузгала. Болай да әрнүдән туктамаган йөрәк сулкылдап сыкрый башлый.*

Авылга кулсыз-аяксыз кайткан фронтовикларны күреп сугыш фаҗигасен аңлаган буын без. 19 яшьлек Шәйхелислам абый ике күзсез һәм ике кулсыз кайткач, Эзмәнең бар халкы өнсез калган иде. Әнисе Мәргубә җиңеләйде, саташып сөйләшә торганга әйләнде.

Җиңү килгәч, исән калганнар кайта башлады. Безнекеләр дә кайтыр, дигән өмет яңарды. Балалар урамда уйнасалар да, күзләре юлда булды. Әтием белән әнием соңгы сулышларына кадәр көтсәләр дә, ике абыем кайтмады. Олы абыем Гарифҗан фронтка китеп 14 көн үтүгә беренче баласы туу турында белмичә дә калды: хәбәрсез югалды.

Миндә Мостафа абыемның сугыш кырыннан язган хатлары да саклана. Морт авылында (Алабуга районы) яшәгән сөйгән кызы Әкълимә апа белән язышканнар. Ул да абыемның үзенә язган хатларын миңа җибәрде. Аларны уку күңелне кузгата, күзгә яшь тула.

Өченче абыебыз Нурислам сугыштан яраланып кайтты. Тракторчылар бригадиры булып эшли башлады. Беркөнне басудан борчылып кайтты. «Тракторчы Нәсимәгә плугарь кирәк иде. Төнге сменага мен әле, сеңлем», – ди. Шатланып риза булдым. Төнлә җир сөрәбез дә, иртән мәктәпкә имтихан бирергә барам. Нәсимә апа мине трактор йөртергә өйрәтте. Аның бик йокысы килгән вакытларда руль артына мин утырам. Ике җәйдә дә икешәр капчык бодай бирделәр. Моңа гаилә белән сөенүләр! Шул бодайны тракторга салып үзем алып кайттым. Билгеле, Нәсимә апа да янымда иде.

Урып-җыю вакытында буа буып, су ындыры әзерләү дә 11–13 яшьлек балаларга йөкләнә. Җитәкчебез – Фәүзия апа Динмөхәммәтова. Тамак ялгап алырга дигән бәрәңге, алабута ипие, яшел суганнарны бергә утырып ашыйбыз. «Кызыл атау» әзерләгәндә өйгә кайтып торулар юк иде. Атларга төягән бодай әтиләр-абыйларга барып җитә дип шатланып, аларның ашап утыруларын күз алдыбызга китерүебездән юанычыбыз эчебезгә сыймый. Шунда үтереп тамак ачканы искә төшә. Ләкин сиздермибез. Стенага элене шлемлы солдат: «Син бүген фронтка нәрсәләр белән ярдәм иттең?» – дип, бармагы белән төртеп карап тора бит.

Безнең эштә иң авыры – үзебез буе капчыклар күтәрү. Башта үлчәүгә салабыз, аннары ат арбасына төйибез. Үзебез тырышып үстерсәк тә, аның бөртегенә дә тияргә ярамады. Ындырдан кайтканда эчке киемеңә кадәр капшамый калганнары сирәк. Кесәңдә аз гына ашлык тапсалар да – төрмә. Эзмәнең җиләктәй 18 яшьлек кызлары Сәкинә, Фаягөл, Зөһрәбикәне унар елга иректән мәхрүм иттеләр. Шәмәрдән заготзерносыннан чыкканда кесәләреннән 200 әр грамм ашлык табылган. Алты елдан соң сәламәтлекләре начарланып, иреккә чыксалар да, хурланып, авылга кайтмадылар. Төрлесе төрле җирдә гомер кичереп, гүр ияләре булды. Сугыш шулай кешеләрне исән була торып та, туганнарыннан, туган җирләреннән аерды. Үз башыннан кичкәннәр өчен бик авыр хәлләр, күрергә язмасын берүк.

*Фәүзия ВАХИТОВА.*
*Казан шәһәре.*

*Әниемнең вафатына ничә еллар үтсә дә, күңел һаман тынычланмый. Әни булганы өчен генә дә түгел, ул үзенчәлекле, кызыклы шәхес иде. Исеме дә – Хәерзадә.*

Дини нәсел кызы, сугыш елларында да уразасын тотты, намазын онытмады. Аның әтисе, минем картәти Хәйрулла мәдрәсәдә укыган, патша армиясендә русча укырга-язарга өйрәнгән. Авылыбызда русча белгән бердәнбер кеше булган. Шуңа да аны волостька



Фото: Газинур Хафизов

писарь итеп алганнар, аннары мәчеттә мөәзин вазыйфасын башкарган.

Инәйнең (без әнине – «инәй», әтине «әтәй» дип үстек) балачагы революциягә кадәрге чорга туры килгән. Абыстайга йөреп тә, әтисеннән дә гарәпчә укырга-язарга өйрәнгән. Сугышта хезмәт армиясендә булган әтәйгә хатларны гарәп имлясында яза иде.

Сугыш чорында инәй мәктәптә җыештыручы булып эшләде. Ул вакытта аларның эше идән юу, җыештыру белән генә чикләнмәде, утын да әзерләделәр, класслардагы мичләргә дә яктылар. Бу эштә әнигә апаларым ярдәм итте. Җәен гел колхоз эшенә йөрде. Инәйне иң яхшы уракчы дип мактаганнары исемдә.

Инәйнең тел байлыгы искиткеч иде. Яшүсмер чаклары Беренче бөтендөнья сугышына, революциягә туры килмәсә, ул педагог белеме алган булыр иде, дим. Без – җиде баласының өчесе педагог булды. Беребез медицина фәннәре кандидаты, мин менә журналист, 45 ел матбугатта эшләдем, 25 ел редактор вазыйфасын башкардым.

Әтәй дә бик максатчан, четерекле хәлләрдән дә чыгу юлларын таба белә торган кеше булган. Егерменче елларда, НЭП вакытында, ул авылдан шәһәргә ит, ашлык, тире, йон илтеп, халык өчен кирәкле товарлар алып кайтып саткан. 1930 елда безнең ике ат, ике сыер булган, яңа йорт салып кергәнбез. Әти колхозга керергә теләмәгән. Бер-бер артлы салым түләтә башлаганнар. Авыл советында эшләүче туганыбыз: «Милкегезне конфисковать итәргә, үзегезне Себергә сөрергә карар чыгардылар. Котыласыгыз килсә, хәзер үк колхозга керү турында гариза языгыз. Атларыгызны, бер сыерыгызны, хуҗалык әйберләрегезне төяп, колхоз дворына илтегез», – дигән.

«Нишләмәк кирәк, әтиегез бер атын җикте, икенчесен җитәкләде, арбага сабан-тырмаларын төяде. Ул алдан атны йөгәненнән тотып бара, мин арттан сыерны чыбык белән куалыйм. Икебезнең дә күздән яшь ага...» – дип сөйли иде инәй.

Аларның күргәннәре моның белән генә бетми әле. 1938 елда әтәйне, халык дошманы дип, кулга алалар. Ярый әле атмыйлар, өч елга төрмәгә ябалар. Инәй ул вакытта алтынчы баласына авырлы булып кала.

Ни гаҗәп: никадәр авырлыклар күрсәләр дә, аларның рухы көчле иде. Сыкранмадылар, зарланмадылар, язмышка риза булып яшәделәр. Иман ныклыгыннан киләдер дим мин моны.

*Хаҗи ӘХМӘТҖАНОВ.*
*Башкортстан, Бәләбәй шәһәре.*

***Филология фәннәре кандидаты Ләйсән Кариева – фронтовик-шагыйрь һәм мөгаллим Әнәс Кариевның кызы.*** *Әнисе ягыннан бабасы –* ***Габдулла Тукайның сабакташы һәм дусты,*** *әбисе исә шагыйрьне дөньяга тудырган Бибимәмдүдәнең нигез күршесе була.*

– Әнием Рәшидә әтиемнең рухи идеалларына фидакарь хезмәт итеп яшәде, – ди Ләйсән Әнәс кызы. – Миңа аларның нурлары төшкән кебек, күләгәләре дә әйләнеп узмады. Әти белән әнинең бер-берсен табуы кемнәргәдер ошап бетми. Алар, Арча педагогика училищесының иң яхшы укытучылары белән бергә, Арчадан куылалар.

Булачак галимә Татарстанның ул чакта Теләче районына керүче Янсуар авылында 1947 елның 15 октябрендә дөньяга килә. Әтисе – илебез азатлыгы өчен көрәшкән фронтовик әдип Әнәс Кариев дөнья куйгач, гаилә әнисенең туган ягына – Арча районының Яңа Кырлай авылына күченеп кайта.

Ләйсән апа менә шушында – дөньяның Габдулла Тукай тасвирлаган җәннәтендә, әдәбият-сәнгать кешеләре чолганышында үсә. Шагыйрьләр Әхмәт Фәйзи, Шәрәф Мөдәррис, Мәхмүт Хөсәен, Нури Арсланов чыгышларын ишетә кыз. Ләбибә Ихсанова, Заһид Хәбибуллин, Вәкил Закиров, Гани Закиров һәм башка язучылар, артистлар, рәссамнар – Тукайның дөньяга күзе ачылган урынга килгән иҗат әһелләре белән аралаша.

1966 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1975–1985 елларда Балтач район газетасында эшли, көн кадагына суга торган язмалар яза. Шул еллардагы хезмәтен зурлап, идеяле, максатчан, тырыш хезмәткәрне ике еллык партия мәктәбенә укырга тәкъдим итәләр. Соңрак фәнни эшчәнлек белән кызыксынып китә – «Татар мифологиясе» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. 1998 елдан 2005 елга кадәр Казандагы В. И. Ленин музей-йорты директоры була. Казан милли-мәдәният үзәгендә эшләгән еллары да нәтиҗәле. Экскурсоводлар төркеме җитәкчесе буларак, татар мәдәниятен дөнья халкына танытуны максат итеп, үз эшен яратып башкара.



– Гомер юлымда очраган яхшы күңелле шәхесләр мине гел рухландырып торды. Фәннәр академиясе галимнәрен, университеттагы укытучыларымны, сабакташларымны һәрвакыт ихтирам белән искә алам, – ди Ләйсән ханым. 2015 елда «Ихлас» нәшриятында аның остазлары һәм университетта бергә гыйлем алган сабакташлары турында «Мәңгелек юлыннан» дип аталган китабы дөнья күрде.

Ләйсән Кариева бүген дә сафта – Казандагы Җиңү паркының Мемориаль музеенда «Буыннар бердәмлеге» циклыннан очрашулар уздыра. Әлеге кичәләрдә Бөек Ватан сугышы чоры балалары, шәкертләр, укучылар катнаша, үзешчән артистлар чыгыш ясый. Соңгы очрашуга Ләйсән Кариева фронтовик язучы, галим, танкист Хәмит Кавиевнең улын – геология фәннәре кандидаты Илгиз Кавиевны чакырган иде. Яраткан эше Ләйсән Әнәс кызына яшәү көче бирә.

*Равилә МӨБАРӘКШИНА,*
*Татарстанның Журналистлар берлеге әгъзасы.*

Фотода: галимәләр Ләйсән Кариева (уңда) һәм Лена Таҗиева.

***Хөрмәтле укучыларыбыз!***
***Сездән хатлар көтеп калабыз.***
***Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.***
***e-mail: ssuum@yandex.ru***

# ӘТИЛЕ ЧАГЫМНЫ САГЫНАМ...




**Халык өчен Рөстәм Зәкуан – шагыйрь, бик күп популяр җырлар авторы, җитәкче, Һ. Такташ, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты. Ә минем өчен әти! Әти сүзе үзенә күп мәгънәне сыйдыра: ярату, таяныч, үрнәк, хөрмәт, терәк, киңәшче... Итәгенә утырып, сөйдерә торган яшьтән күптән узсам да, күңелем белән әле һаман шул чорымда яшәдем. Ул хисләрне тоеп гомер итү шундый рәхәт иде. Гомерем буе әтиле булып яшәрмен кебек иде. Әтинең кинәт кенә арабыздан китеп баруын акылым белән аңласам да, йөрәгем белән озак кабул итә алмадым. Хәер, аның янәшәмдә юклыгын әле дә тулысынча аңлап бетерә алмыйм кебек. Шуңа күрәдер бик еш кына хатирәләргә бирелəм. Әтиле чагыма кайтам...**

### *Әти – яраткан ир*

Безнең Рөстәм... Әти турында, гаиләбез белән бәйле вакыйгаларны искә төшергәндә, әни әнә шулай дип сөйли башлый. Хисләрен ачып салырга яратмаган әниебезнең менә шул сүзе Рөстәменә булган мәңгелек мәхәббәтен, тугрылыгын, чиксез хөрмәтен, рәхмәтен, юксынуын ачып бирә кебек...

Яшьлекнең иң күңелле чорында – студент чакта таныша алар. Кызыл Позиция урамындагы тулай торакта яшиләр, Казан дәүләт университетының танылган татар хорына бергә йөриләр. Уңганлыгы, булганлыгы йөзенә чыккан, чибәр, нечкә билле, соры күзле, кабарып торган иренле Фәния исемле кызга үлеп гашыйк була әти. Ә кыз үзенең бәһасен белә торганнардан. Оялып кына сүз кушкач: «Энем, буең әзрәк үскәч килерсең әле», – дип, үчекләп көлгән була тагын. Шулай да әти бирешми. Әнинең авылдагы күршесе Айдар исемле егет белән дуслашып, аларның

компаниясенә кушыла. Һаман күз уңында йөргән егеткә әни дә башкача карый башлый. «Шул вакытта аның тормышка җигелеп, гаиләне алып барырдай чын ир-егет икәненә инандым», – дип искә ала әни. Әни укып бетерүгә, әти аңа тәкъдим ясый. Әни һич икеләнми риза була. Әтинең әле тагын бер ел укыйсы була. Алар җәйге каникул вакытында өйләнешәләр дә, әтинең туган ягына – Азнакай районы Үчәлле авылына кайтып китәләр. Ә көз көне ул, яшь хатынын кайнана белән кайната «сагында» калдырып, кабат Казанга китә. Һәм Үчәлле белән Казан арасында көн саен диярлек мәхәббәт хатлары йөри башлый. «Исәнме, карчыгым!», «Ни хәлләрең бар, картым?» дип башланган ул хатларны әни әле дә кадерләп саклый.

Әтинең эшенә бәйле рәвештә безнең гаиләгә бик күп тапкырлар күченергә туры килде. Мин хәтерләгәне генә дә унбишкә якын. Әмма ничә тапкыр тору урынын алыштырсалар да, әти, безне алып килгәнче, яшәячәк йортны гөл итеп куя иде. 2017 елда, әле үзе исән чакта, соңгы тапкыр күченделәр. Казандагы бу фатирга тулысынча ремонт ясалып, барлык йорт җиһазлары алынып, тәрәзәгә пәрдәләр эленеп, урын-җирләре, хәтта табак-савыт, кашык-чәнечкегә кадәр әзерләнеп беткәч кенә әни кунак булып килеп керде анда. Шулкадәр зәвык белән җыештырылган фатир тәмам әзер булгач кына әнинең килүенә берәү дә ышанмады. Әмма бу – хак. Ремонт барган вакытта «әниегезгә бер сүз әйтәсе, фотога төшерәсе түгел», дигән шарт белән алып бара иде безне әти. Бу – аның Гөлфәниясенә соңгы сюрпризы булган икән...

Әти белән әнинең бер-берсенә үпкәләп, сөйләшмичә йөргәннәрен бер тапкыр да күргәнем булмады. Гадәттә алар, кайнарланып, бөтен сүзләрен әйтеп бетерәләр дә, берничә минуттан берни булмагандай, кара-каршы утырып чәй эчәләр иде. Олы кызыбыз Әмирә ул вакытларны искә төшергәндә: «Дәү әни, сез бабай белән сүзгә килгәндә дә бер-берегезне яратудан туктамый идегез», – ди.

### *Әти – иң яхшы әти*

Аллаһы Тәгаләгә нәкъ менә әтием белән әнием гаиләсендә туарга, аларның тәрбиясен алырга насыйп иткәне өчен чиксез рәхмәтлемен. «Безнең Айгөлебез белән Айвазыбыз булачак», – дип хыяллана алар гаилә коруга ук. Хыяллары чынга аша.

Урамда кызын җитәкләп барган әтиләрне күрсәм, тукталып калам. Әтине сагынуым тагын да көчәя. Кызчык нәни кулы белән дөньядагы иң көчле кулга тотынган, әтисенә җитешергә тырышып йөгерә-атлый, башлыгыннан чыккан чәчләре күзенә төшеп җәфалый, әмма ул бик бәхетле. Моны бөтен йөрәгем белән аңлыйм һәм сизәм. Минем дә бар андый бәхетле балачак мизгелләре... 3-4 яшь тирәсе булгандыр. Күзләрне ачып булмастай кояшлы язгы көн иде ул. Балалар бакчасы урнашкан авыл урамы гөрләвекләр шавы, сыерчык, чыпчык җырлары, абзарлардан ишетелгән кошкорт, мал-туар тавышы белән тулган. Апрель кояшы бераз киптергән асфальт юлдан кочагын җәеп миңа таба килгән әти каршына чабам. «Әти-и-и!» – дип кычкыруымны бөтен авыл ишеткәндер, мөгаен. Әтием кайтты бит! Комсомол оешмасы районның иң алдынгы яшь белгечләрен ике атнага Югославиягә ял итәргә җибәргән иде ул вакытта. Әти белән беренче тапкыр озакка аерылышып торуым иде. «Әтиең кайтып керү белән: «Фәния, әйдә, Айгөлне балалар бакчасыннан төшеп алыйк», – ди башлады. Ясаган чәен дә эчмичә, чыгып киттек. Көндезге йокыңнан уятып алып чыктым сине. Әтиең урамда көтә дигәч, кызыл резин итекләреңне уңын сулга бутап киеп, ашыга-ашыга, чыгып йөгергән идең», – ди әни.

Ә энем Айваз тугач, Зәкуановлар нәселенең дәвамчысы дип сөенделәр. Фамилия югалмый бит! Әти энемне үзеннән бер дә калдырмады. Ял көннәрендә дә басуларны, ферма тирәләрен бергә урап кайталар иде. Башлангыч сыйныфларда укыганда ук әтинең танышлары, дуслары арасында, үзеннән күпкә өлкән булган абзыйлар янында «Рөстәм малае», ышанычлы «үз кеше» булып йөрде. Әти аны үзенчә чын ир-ат тормышына шулай әзерләгән, күрәсең. Энемдә елдан-ел әти чалымнары ныграк сизелә: күп сөйләшергә яратмый, әмма үз эшен төгәл белә, безнең ныклы терәк. Тышкы кыяфәте белән генә түгел, өстәл янында утыру рәвешләре, телефоннан сөйләшкән чакта бүлмә буйлап арлы-бирле йөрүләре, кап-кайнар итеп чәй эчкәндә: «Эххх, шә-ә-әп» дип куюлары – барысы да әтине хәтерләтә.

### *Әти – җитәкче*

80 нче еллар уртасында әтине бик ярлы, киләчәге билгесез «Янтарь» совхозына рәис итеп билгеләгәннәр. Ул ярты ел чамасы Җинан исемле әбидә фатирда яшәгән. Аннан мәктәбе, балалар бакчасы да булмаган совхозның искерәк агач йортына әни белән безне алып килә. «Балалар бакчасын да, мәктәбен дә үзебез ачарбыз әле», – ди әти әнигә. Авылны күтәргәндә авыр вакытлар булса да, сүзеннән кире кайтмый ул. Илбәк авылында балалар бакчасы да, башлангыч мәктәп тә ачыла. 1989 елда беренче укытучым – әнием булды. Ә ун ел дигәндә, Татарстанда иң беренчеләрдән булып кечкенә авылда төзелгән заманча мәктәпкә аяк бастык. Боларның барысы өчен әти тырышып йөрде.

Җитәкче кеше иң беренче үзе үрнәк күрсәтергә тиеш! Моны кечкенәдән белеп үстек. Миңа 8-9 яшьләр тирәсе булгандыр. Ул вакытта колхозларда авыл халкына чөгендер кишәрлекләре бүлеп бирү бар иде. Әти җитәкче кеше булуга карамастан, иртәнге көтүне куганнан соң ук, 2-3 яшендәге энемне коляскага утыртып,

«Исәнме, карчыгым!», «Ни хәлләрең бар, картым?» дип башланган хатларны әни кадерләп саклый.



әни белән иңбашларыбызга кәтмән салып, башка авылдашлар белән бергә басуга ашыга идек. Бераз үскәч, урып-җыю вакытында амбарга эшкә йөри башладык. Басудан арпа алып кайткан йөк машиналарын аеруча «өзелеп көтә» идек. Баштанаяк кылчыкка батып, керпе балаларыдай энәлегә әйләнәбез, әле аның кычытуына түзеп булмый. Әмма бер кеше дә зарланмый. Әти һәрвакыт амбарга килеп, эшләгән укучы балаларның хәлләрен белешеп китә. Минем янга да, энем янына да килеп басмый. Ерактан гына баш иеп, ишарә белән генә сәлам бирә... Әти бик кешелекле җитәкче иде. Бу аның эш кешесенә булган ихтирамында күренә иде. Илбәк авылына совхоз рәисе булып килгәч, иң беренчеләрдән тәртипкә китерелгән биналарның берсе – ашханә булгандыр. Соңрак шунда ук җәйге веранда да төзелде. Әле дә хәтеремдә: төш вакытында ашханә тирәсенә килеп чыксаң, урам тәмле аш исенә, тәлинкәләрдә шак та шок «биегән» кашыклар тавышына, ара-тирә эшчеләрнең көр көлүләренә уралган булыр иде. Кырдагыларга кайнар аш барып җитсен дип, бер автобус махсус «көпчәкле кухня» итеп җиһазландырылды. Бусы да әтинең идеясе. Анда пешкән ашларны җылытыр өчен газ плитәсе дә, кул югычы да куелган иде. Хезмәт кешесенең тамагын тук итәргә тырышу гадәте башка эшләргә күчкәч тә сакланды әтидә. Өйдә, авылда ремонт-төзәтү эшләре башланыр алдыннан, планнар хакында сөйләшкәндә: «Тә-ә-әк, егетләр, сезне ничә тапкыр ашатасы була?» – дигән сорау беренче яңгырый иде.

70–80 нче елларда киләчәге булмаган авыллар исемлегенә кергән Илбәк авылын күтәрергә гаиләбез белән бергә булыштык әтигә. Авыл халкы аңа бик рәхмәтле булып калды. Шулай булмаса, инде әти үзе булмаса да, озак еллар бергә эшләгән авылдашлары, укытучылар әнинең хәлләрен белешеп, бәйрәмнәр, туган көннәр белән котлап тормаслар иде.

### *Әти – коллега*

2013 елда әти «Таттелеком» элемтә компаниясенең матбугат бүлеге җитәкчесе итеп билгеләнгәч, мине ярдәмче итеп чакырды. Шулай итеп, без әти белән коллегалар булып куйдык. Ул бар кешедән дә иртәрәк эш урынында булыр иде. Мин иртәнге сигезгә килеп җиткәнче, әтинең амбар кенәгәсе зурлыгындагы блокнотында көнлек эш планы төзелеп куелган. Бу эш исемлеге һәр иртә генераль директор үткәргән планеркадан соң тагын да озынаеп чыга. Әтинең һәр башлаган эшен җиренә җиткереп башкаручы, шуннан тәм таба белүче кеше икәнен «Таттелеком»ның ул еллардагы җитәкчесе Лотфулла Шәфигуллин бик тиз чамалый, күрәсең. Нәкъ менә шуның өчен дә ул фикердәшләре, дуслары катнашында Татарстанда яши торган халыкларның милли байлыкларын һәм тарихи мирасын, мәдәниятен үстерү, саклап калуга юнәлдерелгән дистәләрчә проектларны тормышка ашыруны әтигә ышанып тапшыра. Моңа бәйле командировкаларда күп йөрде әти. Фотоаппарат, блокнот салынган сумкасын ала да юлга кузгала. Ничә мең чакрымнар үтелгәндер, билгесез... Соңгы елларда ул командировкалардан кара төн җиткәч кенә кайтып керә иде. Мавыгып китеп, еш кына ял көннәре барлыгын да онытты. Әмма әти-коллегамнан бер генә тапкыр да: «Эш күп, арытты», – дигән сүзне ишетмәдем...

### *Әти – бабай*

Әти, әни, энем, киленебез Лилия, ирем Алмаз, кызларыбыз Әмирә белән Камилә, барыбыз бергә җыелган вакытларны сагынам. Ял көннәрендә кайтып җитәбез, дип, алдан шалтыратмасак та, әти тәмәкесен көйрәтеп, безне һәрвакыт капка төбенә чыгып каршылар. «О-о, минем кызларым авылга кайткан», – дип, оныкларын кочагына алыр. «Әниегезнең бәлеше әллә кайчан пешеп чыкты инде, суынмасын дип мендәр астына төреп куйды, ә сез һаман кайтып җитә алмыйсыз», – дип, безне

яратып шелтәләп алыр... Барыбыз бергә өстәл тирәли тезелеп утырып бәлеш ашаганнан соң, атна буе җыелган яңалыклар белән бүлешәбез, кызып-кызып бәхәсләшәбез, көлешәбез. Әти чын мәгънәсендә җир кешесе иде. Авылга мәхәббәтне шәһәрдә туган оныкларында да уятырга тырышты ул. Махсус алар өчен мунчада чабынырга кечкенә себеркеләр бәйләр иде. Яз көннәрендә оныкларын өй тирәсендә, су буйларында келәм булып үскән сап-сары әпәпия чәчәкләрен җыярга алып чыгар. Ә җәйләрен әти яшь-җилкенчәк егет кебек яланаяк, чалбар балакларын күтәреп куеп, кызлар белән караңгы төшкәнче бакчада түтәлләргә су сибәр иде...

Казаннан эштән кайткан бабаларын җәйге каникул вакытында авыл башына чыгып көтеп торуларын, аның белән җәйрәп яткан болыннарга төшеп җиләк җыюларын, чишмәгә баруларын кызларым хәзер гел сагынып сөйли. Ә көндәлегенә әле оялып кына беренче шигырьләрен яза башлаган үсмер Әмирә кызыбыз аеруча юксына бабасын...

## Әти – шагыйрь

Әтинең күңелендә шигърият уты гел пыскып янып торгандыр ул. Бик тә шигъри җанлы иде. Ул утның дөрләп кабынуына да әнигә булган мәхәббәте сәбәпче. 2004 елда әтигә, Татарстан Дәүләт Советы депутаты булып сайланып, Казанга күчәргә туры килә. Әни ул чакта Азнакай типографиясендә директор булып эшли. Ире артыннан ук башкалага күченеп китә алмый. Әти бер ел буе Казан белән Азнакай арасында йөри. Нәкъ яшь чактагыча, өйләнешеп, «карчыгын» әти-әнисе янына кайтарып куйган вакытлардагы кебек. Ул елларда ике арада сагыну-сагыш хатлары йөрсә, бу юлы әти шигырь яза башлый. «Гөлфәниягә...» дигән беренче шигыре сагынудан туа аның. Бөгелмәдән Казанга самолетта очкан вакытта язган ул аны. Эшкә килеп җитүгә, сәркатибеннән факс белән хатынына җибәрүен сорый. Тастымал буе озынлыктагы факсны күргәч, әни аптырап кала башта. Ул минутта кичергән хисләрен безнең белән бүлешми. Очкынны хисләр ялкынына әверелердәй тылсымлы сүзен, мөгаен, әйткәндер әтигә. Чөнки нәкъ шул вакыйгадан соң әтинең шигырьләре җирдән бәреп чыккан чишмә төсле акты да акты. Әти белән әнинең бер-берсенә, төчеләнеп, «мин сине яратам», «алтыным», «бәгърем» дигәннәрен хәтерләмим. Әмма җанны дәвалар, колакны иркәләр ихлас сүзләрнең икәүдән-икәү генә калгач әйтелгәненә иманым камил. Ә тыйнаклык белән әйтми калган сүзләре әтинең шигырьләренә салынган.

*Бәхетлеме, диеп сорама син, сорама син*
*Бәхетле дип әйтмәм сүз белән.*
*Хисләремне әгәр аңлыйм дисәң, аңлыйм дисәң*
*Серләремне укы күземнән.*

Салават Фәтхетдинов башкаруындагы бу җыр әти белән әнинең иң яраткан җырларының берсе иде...

Әтине җир кешесе дигән идем инде. Шуңадырмы аның күп шигырьләре елларда авылда язылды. Биектау районының Красна авылындагы кечкенә генә өебезгә кайткач, ул шәһәр ыгы-зыгысыннан арынып, тынычланып кала иде. Түр өйдәге өстәлендә лампа кабызып куеп, тирән уйга чума... Бераздан тормыш тәҗрибәсе ташып торган авыл агае сыман тәмәкесен тартып керә. Шигырь юллары ул әйтергә теләгән хисләрне белдереп, энҗедәй тезелеп әзер булгач, әнигә, безгә укый. «Илһам бит ул бик кызык нәрсә. Теләсә кайсы вакытта, хәтта төнге йокыңнан уятып та килергә мөмкин. Күңелеңә килгән юлларны кәгазь битенә төшермәсәң, яңадан башны ташка бәрсәң дә искә төшереп булмый», – дия иде ул. Шуңа да аның түш кесәсендә һәрчак блокнот йөрде. Китаплары нәшриятта басылып чыгасы көнне әти бер дулкынлану белән көтә иде. Хәер, гаиләбез белән көтә идек ул могҗизаны. Типография буяулары аңкып торган иҗат җимешен күтәреп кайткан әтине кысып кочаклап, бит очыннан «пәп» итеп алганнан соң, тизрәк өр-яңа китапны актарырга утыра идек... Тирән уй-фикерләре, хыял-максатлары, кешеләргә, гомумән, дөньяга җиткерәсе сүзләре шигырь җыентыкларында уелып калды аның. Шигырьләренең көйгә салынып, популяр җырларга әверелүен әти үзе сизми дә калды. Кайсыдыр бер очрашуда композитор, җырчы Фирзәр абый Мортазинга китапларын бүләк иткән булган ул. Фирзәр абый исә күңеленә ошаган шигырьләргә көй язган һәм Салават Фәтхетдиновка тәкъдим иткән. Салават абыйның традицион август концертларына барган әтинең танышлары, авторы Рөстәм Зәкуан булган берничә җыр ишетеп кайта. Концертка үзе дә барып ишетеп кайткач, әти Фирзәр абыйга шалтырата. «Әзи, шигырьләрең шәп бит, сиңа сюрприз ясарга теләгән идем», – ди ул. Менә шуннан соң әтинең шигырьләренә Альфред абый Якшимбетов, Вил абый Усманов, Илгиз абый Закиров, Марсель абый Иванов, Нурзадә һәм башкалар көйләр яза башлый. Әти үзе исән вакытта ике йөзгә якын җырын җыеп, җыентык ясаган идек. Әмма аларның саны тагын да күбрәк булырга мөмкин. Әти беркайчан да шигырьләрен сатмады.

Хәзер әти үзе булмагач, шигырьләре никтер бөтенләй башкача ачыла. Әйтерсең лә әти инде шул вакытта ук тормышның бар мәгънәсен ачкан, барысын да алдан белгән, сизгән. Аның сүзләренә язылган җырлар да бүген башкача яңгырый кебек... Шунысы сөенечле: алар мәңгелек.

Әтине югалту ачысы әле дә жанны телә. Озак вакытлар ул исән, бары тик эш буенча берәр җиргә киткән дип, үземне ышандырырга теләп йөрдем. Ябылдым, йомылдым... «Айгөл, син мондый түгел идең бит», – диләр миңа. Әйе, үзгәрдем. Гаилә корып, яраткан хатын, кадерле әни булсам да, 2018 елның салкын декаберенә кадәр бер кайгысыз, иркә, бик бәхетле, әтиле кыз да идем шул... Әтине югалту хәсрәте мине бик үзгәртте. Инде дөньяга башкача карап яшәргә тырышсам да, әтиле кыз булган вакытларымны юксынам...
Бик сагынам...

Айгөл ЗӘКУАНОВА-НӘБИУЛЛИНА
Фотолар: гаилә архивыннан

PRESSA



Әнием хатлары... Алар мине өермә булып күтәреп алалар да, балачагыма, студент чакларыма, зур тормышка аяк баскан көннәремә алып китәләр. Моң-зарлары, ярату-сагынулары дәрья булып баштанаяк күмә... Әни хатлары сакланган, соңгы җиде елда бөтенләй кагылмаган чемоданны ачтым. Әгәр дә бу кадәр авыр буласын белсәм, бәлки, ачмаган да булыр идем. Әнинең бөтен бер дөньям булганын әле хәзер генә аңладым... Әйтерсең, ул хатларны беренче тапкыр күрдем! Аларда – 1966 елдан башлап 2001 елга кадәр язылган авыл хәбәрләре, гаилә, туганнар, һава торышы, күршеләр, халыкара хәлләр... Ул чемоданда яшь ярымнан ятимлекне татыган, сугышның авыр елларын үз җилкәсендә күтәргән, сигез бала табып, икесен җирләгән, өч улын армиягә озатып каршы алган, өч кызын өч якка очырган шигъри күңелле әнием тормышы...



Нәзифә КӘРИМОВА

# ӘНИЕМ ХАТЛАРЫ



## Гомердә назлы сүзләр әйтмәгән, иркәләргә дә оялган әни хатка шундый йөрәк өзгеч сүзләр язган.

Мин өйдән 15 яшемдә чыгып киттем. Яшәргә дә, кеше танырга да, ялгышмаска да, ялгышсам еламаска да үзлегемнән өйрәндем. Янымда акыл бирүче, өйрәтеп торучы юк, сагынуларга дәва булып, бары тик әни хатлары гына килеп торды. Аларның берсен дә ташламадым, шул хатлары аркасындадыр, әни һәрвакыт минем белән булды.

Беренче хатлары мин Алабугада укыганда килә башлады. Әнигә ул вакытта нибары 39 яшь булган! Хат язуы да үзенчә: үз стиле, үз кагыйдәсе бар иде аның. Мин кыз чагында алар болай башланды: *«Сагынычлы хат башы! Сезки безнең өчен бик тә кадерле булган кызыбыз Нәзифәгә синең өчен дә кадерле булган әтиең белән әниеңнән бик сагынып, бик күп кайнар сәламнәр җибәреп калабыз.»* Аннан соң инде беренче урынга кияү чыкты: *«Сезки безнең өчен кадерле булган олы киявебез Илгизгә...»* Тора-бара балалар өстәлде. Сәламнәрдән соң кайчак болай дәвам итә: *«Кызым, синең рәхәтләнеп язган хатыңны рәхәтләнеп, туйганчы укыдым. Хәлим әйтә* (энем – *Н. К.*) *безнең әни апай белән абыйдан хат килсә, чүпрәкләндереп бетергәнче укый ди. Армиягә киткәч, сагынсаң, хатларымны син дә шулай кат-кат укырсың әле, дидем үзенә. Теге син җибәргән түбәтәй кыйбатмы ул, кызым. Күрше Сәлиха акча салыр идем, миңа да алсын әле, ди. Сау бул, кызым.»* Ул кайчагында хатларны шулай кисәк кенә тәмамлап куя.

1968 елның 8 апрелендә язган хаты. Минем училище тәмамлап, Минзәләдә эшләгән чагым. *«Кызым, сиңа хәер-дога инде. Исән-сау гына йөре. Атаң да бик сагына. Мактана кызлары белән. Минем кызларым шикелле булмас инде, ди.* (Гомердә алдына утыртып сөймәгән, иркә сүзләр әйтмәгән әтинең шундый сүзләр әйтүе мине гаҗәпләндерә, күңелем тула. – *Н. К.*) *Кызым, палас суга башладым әле мин. 35 палас суктым кешегә. Мамык шәл дә бәйлим. Тик менә күзләрем начар күрә башлады. Әти күзлеген киеп эшлим. Миңа килешә.»*

1969 елның маенда язылган хат: *«Кызым, Миннулланы армиягә алдылар. 12 май көнне әйтте кичтән авыл радиосы. 13 майда иртән иртүк военкоматка барып җитәргә дип. Төнге сменага чәчүгә киткән иде, барып алдылар. Төне буе йокламадык. Озатырга үзем дә бардым Мамадышка. Авылдан 10 малай чыгып киттеләр. Бик ямансу вакыт. Сабантуйларын да күрми киттеләр. Атаң ару гына йөри әле. Һаман рәтләнеп бетә алмый. Көн дә сине көтәбез. Туган көнеңә бик матур яшел капрон яулык алып куйдым. Кызым, сиңа шул сүзем бар икән әле, анда сиңа кибетләрдә кырые кара, чәчәкле йон яулыклар очрамас микән? Фәгыйлә апаныкы да бар, Айсылуныкы да бар, Гөлбикәгә дә алып кайтканнар. Минеке генә юк. Озак хат яза алмый торгач сүзем күп булыр диган идем, бер рәтле сүз булмады, шушы малай армиягә китеп башымны әйләндерде.»*

Монысы мин инде Мәскәүдә укыганда килгән хат: *«Быел ләйсәннәр дә яумады, җәе нинди булыр микән бу елның. Күңел тыныч түгел. Безнең авылга Амур якларыннан 250 кеше киләсе ди. Аккош тавында окоп казыйсылар икән. Дөнья бетә диләр, шунда качып калырга яшеренер урын әзерлиләр ди. Сезнең укытучы Хуҗи абыегыз үлгән, аның өчен дөнья бетте.»*

Ул кешеләр килгәндерме, әни ул турыда кабат язмады. Ә менә авылга су кертәчәкләр, колонкалар куялар дип бик сөенеп язды: *«Сәмигуллалар турына калункы куйдылар. Суы гына чыкмый. Насосы күгәргән икән, шуны алыштыргач булачак ди. Хәзер инде чишмә суы һәр кешенең өенә кергән.»*

Мин кияүгә чыкканчы, кемгә чыгарсың, ничек яшәрсең дип бик кайгырды әни. Бер хатында болай дип язган: *«Кызым, Казанда укыган бер классташыгыз маржага өйләнгән ди. Кемдер кайтып анасына әйткән. Анасы барып кайткан яннарына. Биш айлык балалары да бар ди инде. Анасы бик рәнҗегән. Кеше арасына чыгарлыгымны калдырмадың, дигән. Балакаем, башка милләт кешесенә генә кияүгә чыга күрмә. Атаң да берүк урыска чыга күрмәсен ди.»* Әни кабат бер тапкыр да бу сүзләрне әйтмәде. Шөкер, алты баласыннан берсе дә башка милләт кешесенә өйләнмәде, кияүгә чыкмады.

*«Кызым, көлерсең микән инде, бер шигырь язам әле сиңа.*

*Яшьлегем үтеп китсә дә,*
*Яшьләрдән һич көнләмим.*
*Тик шулай да яшьлегемне*
*Искә алам, көн дә мин.*
*Ә яшьлегем кайтып керә –*
*Сагынганымны белеп!*
*Яшьлегем – кызым Нәзифәм –*
*Каршымда тора көлеп.»*

Әнинең бу хаты да Мәскәүдә укыган вакытта килгән. Мәскәүдә торучы авылдашыбыз адресын язган, барып хәлләрен белергә кушкан. *«Кызым, Мәскәү урамнарында күп йөреп адаша күрмә. Адресыңны кесәңә тыгып йөре. Мурманскийга, апаларга, Комсомольский на Амурга Нурулла абыйларга хат язып сал.»* Моңарчы алар белән хат алышканым юк иде. Күрәсең, әнинең Мәскәүдә яшәгәнемне туганнарына белдертәсе килгәндер дип уйлыйм хәзер.

Менә тагын бер хаты: *«Кызым, быел барып булмас инде* (Мәскәүгә – *Н. К.*) *Көннәр бик салкын тора, юл юк, кар күп. Әллә ничә көн буран булды. Өйләрне күмеп китте. Әле Казан юлларын ача алмагач, Казаннан танклар чакыртканнар ди. Кар астында калган бер машинаны казып чыгарганнар. Эчендәге дүрт кеше дүртесе дә үлгән, ди. Суыклык 40 градуска җитсә дә туңмадык, өй җылы. Кичләрен күрше-күлән кич утырырга керә. Чаллыда бәрәңгенең поты 9 сум ди. Ит 5–5,5 диләр. Нинди еллар булыр. Кибетләргә оннар кайтмый. Икмәк алмаган кешеләр дә күп булды. Ничек яшәр-*

Фото: Газинур Хафизов

# «...Кызым, бик сагынам сине, көне буе карточкаң белән сөйләшәм.»

*ләр. Безнең, Аллага шөкер, әле Хәлим эшләгәнлек белән. Кичә колхозның отчеты булды, Хәлимгә грамота, 30 сум премия биргәннәр.»*

Әнинең хатларына караганда, әллә мин аларга ай саен посылка салып торганмын? Хат саен посылка өчен рәхмәттән башлый, ә мин хәтерләмим дә...

*«1986 ел. 19 март көнне посылкаңны алдык. Бик тәмле әйберләр җибәргәнсең. Атаң да бик яратып ашады. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын, кызым. Атаң тәрәзәдән карап өйдә генә утыра. Тышка чыкмый хәзер. Бик каты чирләп алды. Әлфия дарулар алып кайтып тора. Рәхмәт аңар. Балакайларым, рәхәт яшәгез инде, мәңге хәер-дога, бигрәк тә кызларыма. Малайлар кайтмый. Грипп каты булды, атаң грипптан тернәкләнеп китә алмый әле. Быел кар күп булды, язгы ташулар шәп булыр диләр. 12 мартта Тимер Мәрҗәне үлде. Әле Миннулла да чирләгән. Билен бик каты авырттырган. Аңар 100 сум акча салдым әле. Берәр җиренә ярап куяр. «Җаныңа чир тисә, җан чыга, талау тия», диләр бит.»*

Әти бик каты авырудан соң 1988 елның апрелендә бакыйлыкка күчте. Ул елны авылга алты тапкыр кайттым. Хат язарга әнинең дә вакыты булмагандыр.

1989 елның апреле. Әни тагын посылка килгәч тә хат язуын әйтә. *«Кызым, авырып торам әле. Әтиеңнең елын уздырдык. Бик авыр ул булмагач. Атаңның хәергә дип калдырган акчалары бар иде. Барыгыз исеменнән дә хәер өләштем. Әлфия белән Илфат та кайттылар. Чирләвем дә шуннан булды ахры – атаңны уйлап, гел елап йөрим бу арада.»* Әтинең вафатыннан соң әни 18 ел яшәде.

1989 елның 7 сентяберендә язган хаты: *«Кызым, сездән посылка килгәч тә хат язып сала алмадым. Әлфия кызы белән Альфира янына барып кайттык.* (Альфира әнинең төпчеге. – *Н. К.*) *Кайтуга бәрәңге сабагын урып куйганнар, урманда чикләвек, өйдә бала-чага.* (Энем Хәлим армиягә барып кайтты да, авылдан беркая китмәде. Киленебез Фирдәүсә белән әти-әни янында, аларны бик хөрмәтләп яшәделәр. Әлбәттә, балалар әни кулында үсте. – *Н. К.*) *Кызым, бик күп чәй җибәргәнсең, Аллаһының рәхмәте төшсен сезгә. Хөҗҗәт Миннәхмәтләренең лапасы янды бар печәннәре белән, әзерләгән утыннары да янып бетте. Өйләре калды. Утны төрткәннәр диделәр. Шакирның анасы үлде, күмделәр бүген.»*

1990 ел 28 май: «Кызым, *«Азат хатын»да «Май кырмыскасы» дигән хикәяңне укыдык. Бик күңелле чыккан. Кызым, быел бер май аенда Арташта 5 кеше үлде! Әбелкасыймны Воркутадан алып кайтып күмде хатыны Мәрзия.»*

1971 елның июнендә язган хаты: *«Кызым, бала ничек? Башына кидертеп өйрәт. Кыз кешенең башы матур, түгәрәк булсын. Кидертмәсәң озынча булып үсә ул. Салкын тидермәгез. Бәләкәй чакта салкын тигән бала чирләшкә була.»*

Әни күп балалы гаиләдә алтынчы бала булып дөньяга килә. Аңардан соң әле тагын бер сеңлесе туа. Шул җиде баланы ятим калдырып, 40 яшендә әниләре вафат була. Үги ана белән яшәгән әни, 13 яшендә, котомкасын асып, Берсут совхозына олы апасы янына китә. Кырык чакрым җирне җәяү үтеп, җиде чакрымга сузылган урманны кичеп барып җитә... Сугыш вакытында механизаторлар курсын тәмамлый, совхозда тракторда эшли. Безнең әни бары тик дүрт класс кына укыган, анысы да латин хәрефләре белән. Кириллицага үзлегеннән өйрәнгән. Кайбер урында сүзләргә латин хәрефләре дә кертеп җибәрә иде ул. Ләкин мин аның хатларын аңларга, танырга өйрәндем. Әнинең тәрбиясе җаныма, күңелемә, акылыма шул хатлар аша да килеп җиткәндер. Янында булганда иркәләү сүзләре ишетергә бик туры килмәде. Без дә алты бала, мин – олысы. Әнинең 1983 елның сентябрендә язган хаты: *«Кызым, мин сине кызганып сагынам. Тормышның иң авыр чакларында үстең. Рәхәт тормышны өйдә күрә алмады дип кызганам. Олы бала булдың, бар авырлык сиңа туры килде.»*

Алабугада укыганда хатларны саклык белән генә ача идем: конверт эченә әни бер сум булса да акча тыга иде. Мин дә аның үрнәгендә хат эченә акча салуны үземә гадәт иттем. Барып җитә иде! Бер хатында әни: *«Кызым, биш тәңкә тыккан хатың да килеп җитте. Мин аңа ураза фытрасы итеп дога кылдым. Үзем ураза фытрасын әнигә төшердем»*, – дип язган. Әнинең үги әнисе – әби исән чак әле. Әни уразасын да, намазын да калдырмады.

Мәскәүгә күп тапкырлар килде ул. Гомумән, ерак юл дип тормый, балаларына йөрергә ярата иде. Бер энем Башкортстанда яши. Әни аның янына барырга җыенуы турында яза: *«Кызым, бу хатны Мамадыштан язам. Әлфияләрдә утырам әле. Ике кич кундым инде. Миннуллаларга бармакчы идек. Өйдән чыкмаслык, яңгыр коя. «Сукыр тычкан юлга чыкса аршын ярым кар явар», ди. Кызым, үзем дә картайдым инде быел. Гел чирләштерep торам. Үзегез нихәлдә? Гөлфәния әнисен Алабугага алып китте. Торырга. Кәримә апа үлде. Газизә апа сиңа сәлам әйтте. Сау бул, кызым. Бик сагынам сине, бала җимешем.»*

Бала җимешем... Бу юлларны укыганнан соң күңел кабат мөлдерәмә тула...

*«Кирмәнгә колхоз бәрәңгесен ярырга йөри идек, әле бүген өйдә калдым. Пенсиядә булсам да, эшкә әйтәләр, тыңламый булмый. Иртәгә көтү чираты. 17–18 е яулык җыялар, 19 ы – Сабан туе.*

*Безнең авыл шундый матур,*
*Хуш исле болыннары.*
*Шуны сагынып ел да кайта*
*Читтәге балалары.*

*Сау бул, кызым. Сез генә кайтабыз дип әйтмисез шул.»* Бу хатны әни 1971 елның 16 июнендә язган. Кызыбыз Айгөлгә бары ай ярым. Кая кайтасың инде?! Ә әни көткән...

Икенче бер хаты: *«Кызым, кайчан кайта алырсыз икән? Әйбәтләп ачык кына яз әле. Чикләвек бик күп булды быел. Халык җыя. Бер атна-ун көннән җиргә коела башлый инде ул. Кайтсаң җыяр идең, дип язам. Кызым! Илфат армиядә еракта хезмәт итә, Польшада. Бик сагына. Син дә хат яз әле аңар. Кызым, калганын кайткач сөйләшербез рәхәтләнеп. Өйдә бик рәхәт, гөлләр чәчәк атты. Хат яз. Көн дә көтәм.*

*Кәстрүлдә пешкән ашларыңны*
*Чоланнарга чыгып суытма.*
*Дөнья мәшәкатьләре күп диеп,*
*Шәһәрдә анаңны онытма.»*

Безнең әни укырга бик ярата иде. Алты балалы хатынның укырга вакыты кайдан табылгандыр, белмим. «Колхозчы тавышы» дигән район газетасын, безгә «Яшь ленинчы» газетасын яздыра иде. Мин Алабугада мәдәни-агарту училищесының беренче курсында укыганда (1962–63 уку елы), хат эченә салып «Яшь ленинчы» газетасыннан кисеп алган фото һәм шигырьләр җибәргән. Мин ул хатның эчтәлеген бик яхшы хәтерлим: *«Кызым, кара әле бу матур егеткә, ул шигырьләр яза икән. Армиядә чакта турниктан егылып төшкән дә имгәнеп калган.»* Ул егетнең исеме Фәнис Яруллин иде. Әни җибәргән фото белән шигырьне кечкенә чемоданымның эченә ябыштырдым... Фәнис Яруллин иҗаты шуңа да миңа бик якын. «Яшь ленинчы» әнинең хатларында тагын берничә тапкыр телгә алына: *«Кызым, «Яшь ленинчы»да «Авылым җыры» дигән хикәяңне басканнар. Синең турында Хәкимҗан Халиков дигән кеше бик матур сүзләр әйткән.»*

1986 елның июнендә язган хатында әни болай ди: *«Кызым, кичә Сабантуй мәйданында Шаһинур Мостафин яныма килеп, синең «Җәнлекләр кайта» дигән китабыңны биреп китте. Көлешә-көлешә укыдык өйгә кайткач.»*

Әни хатларын уку җиңел түгел, бигрәк тә миңа үпкәләгәнрәк юллар очраса: *«Син дә сирәк яза башладың. Сездән хат килмәгәч бик читен. Көн дә көтәбез. Укыганда ешрак килә иде хатларың. Хәзер инде үстең шул. Тик син миңа барыбер шул 15 яшьлек бала бит. Үземнең картайганымны чутламыйм. Чәчем ап-ак хәзер. Һәрбер балам турында уйлаганга ул.*

*Ишегалдым түгәрәк кул,*
*Көн дә әйләнеп узам.*
*Сезнең яктан кошлар килсә,*
*Хат юкмы дип, кул сузам!»*

Әнинең кайбер хатларын бүген туган авылыбызның тарихы дип тә укыйм: *«Шахта Харислар да Чаллыга балалары янына күчеп киттеләр. Китәселәре килмәде, бик елап киттеләр. Шәкүрова Минсылуны балалары Алабугага алып китте. Әле безнең янибызда балалар бар, Аллага шөкер.»* Бу инде авылның бушый башлавы булган...

Ә бу хат 1969 елның 30 июлендә язылган: *«Кызым, озак хат яза алмадым. Эш күп булды. Бүген яңгыр ява. Мин өйдә. Фәгыйлә апаның Рифаты армиягә китте. Авылдан өчәү киттеләр. Сабан туе булды. Сабан туена Әлфияләр дә, Аппакай да кайтты. Кызым, син сагынма дигәч, ике атна сагынмыйча тордым. Бу озак хат язмавым да шуннан. Син дә кайтырсың дигән идем. Менә бүген хат килеп төште дә бөтен өметләрем өзелде. Кайтмыйсың икән. Быел бакчалар соңга калды. Бәрәңге тишелә генә әле. Җүнле җылы көн юк. Кыярлар да үсми. Кызым, бәлки кайтып килерсең әле. Сау бул, балакаем.»*

Әни хатларын укыганда, аны күреп сөйләшкәндәй, авылга кайтып килгәндәй буласың: хәбәр арты хәбәр тезелгән. 1977 елның 9 сентябрендә язган хаты: *«Кызым, 29 көнне ике посылкагызны алдык. Бик әйбәт килгәннәр. Киемнәре Альфирага да, Хәлимгә дә таптаман, үлчәп теккән кебек. Менә Әлфиягә дип җибәргән күлмәгең ярамас аңар. Юан ул хәзер, тормышы рәхәт аның. Посылкаң белән әти дә кайткан бит.»* Бу юлларны укыгач башта аңламый тордым, аннан исемә төште. Мин ул посылка белән бабай янында әни белән Фәгыйлә апа төшкән фотоны зурайтып җибәргән идем. *«...Иллә дә матур кеше булган инде безнең әти. Әтине күргәч Фәгыйлә апа белән еладык.»*

Әнинең соңгы хаты 2001 елда килгән. Шул елны аларга телефон керттеләр: без бик еш телефоннан сөйләшә башладык. Ә әнинең соңгы хаты васыяте кебек: *«Кызым, мәңге хәер-дога сиңа, рәхмәтем яусын! Аяк атлаган саен әни хәер-догасы бу диген. Мәңге рәхәт яшә. Кая барсаң да эшең уң булсын, сүзең өстен булсын, адәм арасында йөзең якты булсын, үзеңне зурлап йөртсеннәр, йа Рабби Ходаем. Миннән теләк шул сиңа, кызым-балакаем. Рәхәт яшә, кызым!»*

2006 елның гыйнварында бакыйлыкка күчте әни. Соңгы минутларына кадәр үз аңында иде. Белгән догаларымны укып, кулыннан тотып утырдым. «Әни, дөрес укыйммы?» – дим. «Дөрес укыйсың, кызым, дөрес...» – диде.

Әни озак авырып ятмады – балаларына бер авырлык та салмады. Һәр өйдә була торган олы сандык аныкы да бар иде. Сандыгын ачкач барыбыз да гаҗәпләнүдән тынып калдык. Хәер-сәдакага бирәсе һәр әйберне аерым төреп, язып куйган: су китерүчеләргә, су салып торучыларга, юучыларга, тастар башы тотучыларга... 16 гыйнвар көнне вафат булды әни. Урамда җил, 35 градус салкын. Кабер казырга кеше килерме икән дип борчылды энем. «Безнең әни изге кеше ул, менә күрерсез, көнне җылытачак!» – дим. Чынлап та шулай булды: җил тынды, дымык кына йомшак кар ява башлады, көнне җылытып җибәрде. Кабер казырга күрше авыллардан ук көрәкләрен күтәреп бик күп кеше килде. Җир каты булмаган – кабер эченнән җылы пар күтәрелеп торган.

Әнине искә алмаган көнем юк. Рухы шат булсын...

# «ЙӨРӘГЕМ КИЧЕРМИ...»

Гөлнур
САФИУЛЛИНА

**– «Ул вакытта атагыз Абдулла Сарасы белән йөри иде...» Авылда булган берәр вакыйганы искә төшерүен сорасаң, әни бераз уйланып тора да, сүзен гел шулай башлый иде. Исемнәр генә үзгәрә... Әнинең йөрәге боларның барысына ничекләр чыдагандыр?! Аның сабырлыгына әлегәчә шаккатам...**
**Сугыш алып килгән фаҗигаләрнең очы-кырые, саны-исәбе юктыр. Бу язма – шуларның берсе турында.**



– Әтине мин беренче күрүдә үк яратмадым...

Урам буйлап кайтып килгән кыз, әнисенең бакча буенда кем беләндер кочаклашып торганын күреп аптырап кала. Нәрсә бу, нинди хәл? Әни бит ул аларныкы гына! Ә теге ят абый әнисе артыннан өйгә үк керә. «Мин барысын да күрдем, әти кайтуга аңа әйтәчәкмен!» – кечкенә кыз ачуын яшереп тә тормый. «Кызым, мин бит әтиең инде синең, кил әле, кочаклыйм!» – дип елмая ир-ат. Әтисеннән ун айлык кына булып калган Саимә, әлбәттә, танымый аны. Кайдан танысын – күз салырга фотосурәте дә булмагач соң... Әмма үз әтисе икәненә ышангач та, итәгенә барыбер утырмый ул аның. Апасы утыра, ул – юк. Икенче көнне дә якын килми. «Әти» дип тә дәшми. Әнисе күршеләргә кереп киткән әтисен ашарга чакырып чыгарга куша. Әнисе әйткәч бармый булмый, бара, әмма «әти» дип дәшәргә тел әйләнми: «Анда сине чакыралар...» – ди... Әбисе соңыннан: «Кызым, син

Фото: www.pexels.com

шул чакта ук барысын да сизгәнсендер, мөгаен», – ди аңа.

1946 ел бу. Әтисенең авылга әле ялга гына кайткан чагы. Аягы яраланып, Куйбышев шәһәрендә озак кына госпитальдә ята ул. Аннан соң да тоткарлана. Әбисе эче пошкан саен кечкенә Саимәне җитәкли дә, Украинадан эвакуация белән килгән багучы хатынга бара. Бер бара, ике, өч… Соңгысында багучы аңа: «Мөслимә апа, башка килеп йөрмә инде… Улың исән дидем бит, кайта, әмма барыбер сезнең белән яшәми. Ышан сүземә!» – дип, аны кире бора.

Әтиләре авылда озак кунак булмый – кире китә. Хатыныңдагы яңалыкны белеп киткән булса кирәк, хаты килә: «Малай тапсаң – кайтырмын, тагын кыз булса, мине көтмә…»

Нәкъ тугыз айдан тупырдап торган ир бала туа: «Шундый яраттык без аны… Энебез иде бит, әллә нинди мәхәббәтле бер бала иде ул». Бу яңалык Куйбышевка да барып ирешә. 1947 елның яз башында әтиләре авылга әйләнеп кайта, аны шунда ук колхоз председателе итеп куялар. Тормыш бертөрле көйләнгән кебек була. Әмма бик азга шул…

## Әни бик яраткандыр әтине, шуңа түзгәндер – араларны ахыргача өзмәгәндер дип уйлыйм.

– Әни бик еш искә төшергәнгәдер, минем дә ул көн бүгенгедәй истә. Май ахырында колхозда сарык йоны алалар иде. Әни янына дус хатыны килә дә: «Ахирәт, бар кайт әле, синең өчен үзем эшлим», – ди. Әни шунда ук: «Кирамның маржасы кайтканмы әллә?» – дип сорый. Йөрәге сизгәндер инде… Аның барлыгын белгән бит. Әти яткан госпитальдә ул хатынның туганы эшләгән, шулай танышканнар бугай. Күрәсең, әти белән хәбәрләшеп тә торганнар… «Бер сарык өстен алып бетердем, икенчесенә хәлем җитмәде», – дип сөйли иде әни. Туп-туры Фәрит абыйларга барган әни – әтинең теге хатынны шуларга алып кайтканын әйткән булалар инде. Нечкәлекләрен белмим – әтинең дус кешесе булгандыр инде ул абзый, туган-мазары түгел иде. Әнинең каршысына әти чыга: «Динә, тормышны бозмыйк инде, бар өйгә кайт, ике-өч көннән китә ул», – дигән. Әни өйгә кайтты да, апа белән безнең күлмәкләрне алыштырды, чәчләребезне җыйды. «Ә хәзер Фәрит абыйларга барыгыз, сезгә яңа әни булырга әтиегезнең маржасы кайткан анда», – диде. Киттек апа белән җитәкләшеп. Бөтен авыл урамда – бу хәлләрнең ничек бетәсен беләселәре килә. Авылда русча бик оста сөйләшүче Суфия апа бар иде. Каршыбызга чыкты да: «Үзегезне анда матур тотыгыз, «папа мой, папа наш» дип кенә әйтегез», – диде. Кабатлаттырып та карады. Кем икәнебезне чамалагандыр инде, кунак хатын безне ишек төбендә үк каршы алды. Икебезгә дә икешәр шакмак шикәр тоттырды. «Сахар», – ди. Ул русча әйткәч, Суфия апа өйрәткән сүзләр искә төште. Апага: «Ела!» – дим. Үзем башладым. Өзмикуймый: «Папа!», «Папа мой!» – дибез… Анда тагын бер күрше апа бар иде, ул: «Бу кадәр елагач җитте инде», – дип, безне туктатты. Зур эш эшләгәндәй чыгып киттек…

Ике-өч кичтән соң Фәритнең хатыны: «Динәнең күзенә карарга оялам, маржаңны бездән алып чыгып кит!» – ди иргә. Кирам кунакны алып, бертуган абыйлары йортына күченә. Авыл йорты зур түгел: котелмәгән өйдәшләр өчен бер бүлмәне бушаталар. Аларның алты-җиде баласы исә кич саен Саимәләргә кунарга менә… «Кемдер анда аулагөй ясый, ә син бер көтү балага урын җәясең. Йөрәгеңә мүк үсмәгәндер бит – кертмә шуларны!» – дигән ахирәтләрен Динә шунда ук туктата. «Мин Кирамның тасма теленә ышанып 45 чакрымнан килдем, ә ул хатын бит миңа караганда бик күпкә ерак җирдән кайткан. Кеше көлдерергә ярамас», – ди.

Ул арада Карагандада яшәүче олы улы янына кыш чыгарга – балалар карашырга киткән әбиләре кайтып төшә. Төп йорттагы килененең:

– Әнкәй җаным, без тагын әллә нишләп беттек бит! – диюен ишетүгә Мөслимә әби аңын җуеп егыла: телсез-авызсыз кала. Авылда яңалык тиз тарала: өйгә хәл белешүчеләр килеп тула. Карчыкны күмәргә әзерләнәләр – кәфенлекләр киселә, кабер урыны билгеләнә. Берәр атна шулай уза. Кунак хатынның өйдә үзе генә икәнен белгән теге усал Суфия апа бер көнне аларга барып керә. «Син ни дип кайттың монда? – ди ул. – Кеше үтерергәме? Мөслимә апа терелмәсә, авылда ничек яшәрмен дип уйлыйсың? Сиңа закон табылмас дип беләсеңме?» Хатын акланырга керешә: «Сукыр карчык – әнием дә, бер балам гына бар, дип әйтте бит ул. Китәм мин, китәм…»

Саимә апа күңелендә кабат хатирәләр кузгала.

– Көненә кадәр истә, онытылмый… 4 июнь иде. Көн шундый салкын – карлы-бозлы яңгыр ява. Безнең өй урамга таба салынган. Әни мичкә ягып йөри, ә мин почмак тәрәзәдән урамга карап утырам. Кинәт күреп алдым – түбән очтан әтинең аты килә: арбаның бер ягына – әти, икенче ягына теге хатын утырган. Әтинең өстендә кожанка, ә тегесе юка пальтодан гына – туңган, бөрешкән… «Әни, әтинең маржасы китә!» – дип кычкырдым. Әни тәрәзәгә күз генә салды да, бирнәгә алып килгән паласын тотып, әтиләрнең каршысына чыгып йөгерде. Сугыш вакытында калган паласларын сатып бетергән, монысы – соңгысы иде… Мин дә әни артыннан ияРдем.

– Үзең киенгәнсең, ә аның өстенә нигә берәрсеннән калынрак кием сорамадың? Әйт үзенә, бөркәнеп утырсын, – диде ул әтигә. Аннан: «Мә!» – дип, көндәшенең алдына паласны илтеп салды…

Әти шунда шаккатып калган иде. Ул кичне бик соң кайтты – кунагын кая кадәр озаткандыр, белмим. Әби миңа әни белән аларның баскыч төбендә нәрсә сөйләшкәннәрен тыңларга кушты. «Алтындыр синең йөрәгең, Динә!» – диде ул әнигә… Ә Куйбышевтан хатлар безгә озак

PRESSA



## Әти очрашып йөргән, өйләнеп торган хатыннарның берсеннән дә ким түгел иде әни.

килде әле. Русча азрак белә башлагач, матчага кыстырган ул хатларны укыдым да. «Вокзалда сиңа охшаган бер ир-атны күрдем дә, юләрләнәм дип торам», – дип язган иде берсендә. Яраткан булгандыр инде әтине – ирләр юк заман иде бит, сеңлем...

Әйе, ир-атның һәрберсе исәптә чак. Юк, исәптә генә түгел – кадердә чак. Халык та усал, көн туса: «Аның белән чуала...», «Моның белән чуала...» дигән сүзләрне җиткереп кенә торалар. Һәрбер андый яңа хәбәрнең йөрәккә ук булып кадалуында эшләре юк... Динәсе дә берәүдән дә ким булмый югыйсә: зифа буйлы, озын кара чәчле, ак тәнле. Кирам аңа өйләнгәч: "Бу кадәр чибәр кыз минем белән торырмы икән?!» – дип аптырый... Тирә-юньдә атаклы бер колхоз рәисе янына иярләшә әтиләре. Әмма ул акыллы хатын булып чыга: алар авылына бер килгәч, «Кирамның хатынын күрсәтегез әле», – дип сорый. Ул хатынның киләсен белеп, иң матур күлмәген киеп чыккан Динәгә читтән генә күз төшерә дә, ирне башка үз янына аяк бастырмый. Әмма аңа алмаш исә бик тиз табыла – күрше авылның кибетчесе.

Ул җәйне әтиләре гел таң алдыннан гына кайта: беркөнне, имеш, арыш башы кисә башлаганнар, икенче көнне, имеш, бер кешенең аты кереп икмәкне таптаган – кизү торган, өченче көнне... Озакламый ул бөтенләйгә өч балалы шул хатынга күченә. «Сугыштан кайткач, әти безнең янда барлы-юклы ике ай гына торды. Мин үз гомеремдә нибары ике ай әтиле булып яшәдем», – ди Саимә апа... Әтисе исәнсау була торып та, тормышны әтисез килеш кичәргә язган аңа.

Кибетче хатынның әзер бурасы була – әтисе шуны алып кайтып, күрше урамга яңа йорт сала. Йорт түгел – сарай! Саимәләрнеке белән чагыштырганда – сарай... Капка-коймага, абзар төзергә дигән материалларын, сакларга дип, төп йортының лапасына китереп тутыра. Динәсе – аерылган хатыны – аларны, чынлап та, саклый. Салкын өйдә утырып туңган балалары: «Әтинең шул бер капка тактасын гына ягыйк әле мичкә», – дип күпме ялынсалар да, кагылдырмый. Ә үзенә, ягарга утыны булмаганга, колхоз кәнсәләрен кертә...

Саимә апаның йөрәгенә мәңгелеккә уелып калган тагын бер хатирә бар:

– Әтигә бер тапкыр гына ялындым мин... Сабантуй алды иде, ә мәйданга бит яңа күлмәксез барып булмый... Кибеткә кызгылт-сары җирлеккә вак кына чәчәкләр төшкән күлмәклек ситсы кайткан. Апа белән икебезгә 5 метр ситсы җитә, метры – 53 тиеннән. Әнидән сорамыйбыз да – акчасы юклыгын беләбез. Сыер асрады ул, шуңа гына ачлык күрмәдек... Кибетче апа котырта: «Атагыздан акча сорагыз», – ди. Барып кердем өйләренә, әти теге хатынның бер баласын өстенә утырткан да, яткан килеш шуның белән уйнап ята. «Кызым, карале, болар әти дип әйтсен өчен, мин аларга нәрсәләр генә алып кайтмадым, ә алардан барыбер ул сүзне ишетмим», – ди. Өстәл өстендә – яңа күлмәкләр, аяк киемнәре, панамкалар... «Әти, безгә дә күлмәклек кирәк иде», – дим. «Акча бирәм», – дип калды. Бик сөенеп кайткан идем дә... Кибеттәге теге ситсы сатылып бетте, Сабантуй да килеп җитте... Әни килен бүләге итеп әбигә намазлык алып килгән булган. Артына ситсы теккән иде аның – әни шуны сүтеп алды. Иртәгә Сабантуй дигән көнне кибетченең өен җыештырды, мичен агартты, идәннәрен юды, ә ул апа безгә теге ситсыдан күлмәк тегеп бирде. Аксыл җирлеккә беленер-беленмәс кенә сирень чәчәкләре төшкән иде аңа... Сабантуйга баруга әтине эзләп таптым, бала бит – күлмәк белән мактанасы килә. Ә ул көрәшче иде, мәйданга чыгарга әзерләнә. «Әти, көрәшеп алган бүләкләреңне безгә дә бирерсең әле», – дим. «Ярар, ярар, кызым, әнә Вәсилә янында басып тор», – ди. Вәсилә – яңа хатынының кызы, миннән бер яшькә кечерәк. Әти Сабантуй буена көрәште һәм бөтен алган бүләген Вәсиләгә китереп тоттырды. Бер кисәк сабын гына бирсә дә, түбәм күккә тигән булыр иде... Миңа нәрсәдер булды шунда. Әни минем өчен генә гомеремдә беренче тапкыр Сабантуйга төшкән иде. «Саимәне мәйдан эченнән алып чык әле», – дип, күрше апага ул әйткән. Телсез-авызсыз булганмын, атка салып алып кайтканнар. Ничә сәгать ятканмындыр, белмим: күземне ачсам, әби елый-елый миңа нәрсәдер эчерә... Әниләр аерылышсалар да, әби авылдагы икенче улына күченмәде, бездә яшәп калды. «Әти эрбет чикләвеге алып бирмәде», – дигәнмен аңа. Аннары торып урамга чыкканмын да, нигез туфрагына ятып, ауный-ауный елаганмын. Халык мәйданнан кайткан вакыт булган инде бу. «Нәрсә, аю биетәләрме әллә?» – дип, әти дә килеп кычкырган. «Тор!» – дип, миңа аягы белән төрткән...

Кечкенәдән йөрәк авыртулы булып үстем. Югары уку йортларын тәмамлагач, эшли башлагач кына табиблар миңа: «Сез инде ике инфаркт кичергәнсез», – диделәр. Мин аның берсе шул Сабантуй көнне булгандыр дип уйлыйм...

Сугыштан соңгы елларда берәүгә дә җиңел булмаган. Өстенә кияргә киеме, аягына кияргә итеге юклыктан мәктәпкә йөри алмыйча укуын ташлаганнар Саимә генә булмый, әлбәттә. Көзге беренче яңгырларга кадәр генә парта артында утыра ул, аннан кире борылып өйгә кайта. Колхоз бригадиры: «Синең язуың матур, әйдә, миңа булыш әле», – дип, аны үзенә ярдәмче итеп ала. Бер ел шулай уза. Тагын уку елы башланыр чак җитә. Күңел алгысына – укырга ярата ул. Җитмәсә, беркөнне әтинең теге үги кызы килеп: «Сигезенчегә укырга барам», – дип, ындырдагы кызларга китап-

ларын күрсәтеп китә... Саимә ул кичне өйгә кайтып: «Мин шулай укымыйча калырмынмы икән-ни?» – дип елый. Өч кадак май биреп, әнисе аны базарга җибәрә.

Мәктәптә аларны Вәсилә белән бер парта артына утырталар: утырмас иде – Вәсиләнең дәреслекләре бар, аныкы юк. Кара көзгә кадәр укый да, мәктәпне тагын ташлап кайта Саимә. Укыган өчен 150 сум акча түләргә кирәк, әнисе аны кайдан алсын? Әтисе сугышта үлгән дип, Вәсиләгә интернаттан урын бирәләр, Саимәгә анысы да юк – әтисе исән бит... Коеп яңгыр яуган көнне кызны эзләп мәктәп директоры үзе килә: «Укырга кирәк сиңа, югыйсә әрәм буласың», – ди... Ул елны Саимәдән 75 сум гына түләтәләр, ә икенче елны инде аның бәхетенә уку өчен түләү бетерелә.

– Вәсилә белән өч ел янәшә утырып укыдык без. Мәктәпкә бергә йөрдек. Йөрдек дип... Кыш көне аны мәктәпкә илтергә дип, капка төпләренә җиңүле ат килеп туктый. Колхоз председателе кызы бит! Аның өйдән чыкканын көтеп урамда мин йөрим. Кармы, җилме, буранмы... Бер бик салкын көнне әйтмичә китеп барган бу. Сигез чакрым җәяү атладым. Ул чакта шундый суык көннәр була иде бит. Барып җиткәнче ике тез башым да өшегән иде... Унынчы класска җиттек шулай. Инде буй җитеп киләбез. Әни беркөнне апа белән миңа: «Кызлар, фельдшер булып эшләүче Фәния апагыз быел җәй кияүгә чыга икән. Бирнәгә челтәр бәйләп бирмәссезме, ди. Сабантуйга сезгә күлмәклек алыр идек», – диде. Ризалашмаган кая?! Ничә ай буе дәресләрдә парта астында челтәр бәйләдем: караватт өсләре, тәрәзә пәрдәләре, мендәр читләре, өстәл япмалары... Укытучылар белсәләр дә, сүз әйтмәделәр. Шул акчага штапель күлмәклек алдык. Минем күргәнне хуҗасыз эт кенә күрде дип, гел әйтәм...

Әтисенә үпкә ул елларда күңелдә тау-тау булып өелә. Мәктәпне тәмамлап, эш эзләп Казанга килгән мәлләрдә – бигрәк тә. Шундый зур колхозны җитәкли бит ул: аңа кемнең генә йомышы төшми. «Кызымны эшкә алыгыз әле», – дип, кайсына мөрәҗәгать итсә дә, каршы килмәсләр иде. Саимә ул чакта туганнан туган апаларына барып керә. Дөрес, ул аны үзе белән ияртеп заводка алып бара, әмма анда: «Паспортың юк», – дип, кызны кире боралар. Ике-өч кичтән соң апасы: «Без сине пропискасыз тота алмыйбыз», – дип, урамга чыгарып җибәрә. «Мине дә сез эшләгән җирдә эшкә алмаслармы?» – дип, Саимә икенче авылдашына барып керә. Авылдашлар шулай икенчесеннән – өченчесенә, өченчесеннән – дүртенчесенә, бишенчесенә... ике ай буе йөртәләр аны. Бер кыз белән вокзалда йоклаларга туры килә. Вокзал стенасында «эшчеләр кирәк» дигән язу күреп, шул адрес белән контораны эзләп китәләр. Кадрлар бүлегендәге хатын күрше авылныкы булып чыга, әмма ул өмете өзелер дәрәҗәгә җиткән кыз баланы тыңларга да теләми: «Паспортың юк!» – ди... Коридорга чыгуга Саимә кычкырып елый башлый – һич берничек туктый алмый. Шул вакыт аның янына өлкән яшьтәге бер рус кешесе килеп баса. «Доченька, нигә елыйсың?» – ди ул аңа. «Эшкә алмыйлар, ә безнең сыер үлде, апам авырый...» – дип тезеп китә кыз. Ул Саимәне кулыннан җитәкләп кире кадрлар бүлегенә алып керә һәм теге хатын каршына бастыра. «Аның паспорты юк...» – дип әйтә башлаган кадрлар бүлеге начальнигын шунда ук туктата. «Паспорты бармы дип сорамыйм, аның эшлисе килә, эшкә ал», – ди кырыс кына. Аннан Саимәгә борыла да, йомшак тавыш белән: «Доченька, ә сиңа тулай торак кирәкме?» – дип сорый. Ә кыз тулай торакның әле ни икәнен дә белми... Төзелешкә эшкә алалар аны: вагон-вагон бүрәнә, күмер, кирпеч бушата. Авыл кызы бит – авыр дип тормый. Ә теге кеше «Казтрансстрой» тресты начальнигы булып чыга. «Иң авыр вакытымда миңа ярдәм күрсәтте», – дип, Саимә апа аңа хәзер дә дога кыла.

Әйе, авыр чакларда әтисе түгел, гел җиде ятлар ярдәмгә килә аңа. Хәер, әтисендә башка кайгы була шул: күрше урамда уника ел яшәгәннән соң, тагын башка хатынга чыгып китә... Барысын да кабат өр-яңадан башлый. Чит-ят җирдә бер ялгызы калган хатыны йортын кире үз авылына күчереп салырга хәл итә. Бу зур эшкә тотыныр алдыннан Динә апа янына керә ул: «Өмәгә килүчеләргә чәй генә куеп тормассыңмы икән? Монда башка кешебез юк бит инде», – ди. Чәен дә куя Динә апа, табак тотырып бәрәңге дә пешерә, маен да чыгара... Алгарак китеп булса да әйтим: авылга бер кайтуында Вәсилә аларга килеп, Саимәне әнисе янына алып китә. Үлем түшәгендә яткан хатын Саимәдән гафу үтенә: «Сезнең алда бик гаеплемен, хәзер генә аңладым... Зинһар, рәнҗемәгез... Мин үлгәч, догаңнан калдырма», – ди...

Инде әтисе белән соңгы очрашу турында.

– Мин инде югары белем алып, әйбәт кенә эшкә урнашкан, тормышым да берникадәр җайлана төшкән иде. Беркөнне ашарга пешереп йөри идем, ишектә кыңгырау шалтырады. Барып ачсам – әти басып тора! Мин аңа бик ачылып, сөенеп дәштем: «Кайлардан килеп чыктың, әти? Әйдә, уз, кер!» – дим. Бусаганы узды да, ишек яңагына сөялде. «Ни булды?» – дип куркып калдым. «Болай каршы алырсың дип уйламаган идем», – ди. «Әйдә, әти, дөньялыкныкы дөньяда бетсен инде», – дим. Елаштык, аннан икәү утырып чәй эчтек. Бераздан ашым пешеп чыкты – аны бик яратып ашады. Аннан: «Кызым, бераз ятып торыйм әле. Сәгать дүрттә уятырсың», – ди. Биштә генә уянды да, кабат йоклап китте. Кичке җидедә генә торды. Тынычлап йоклавы булды бугай. «Мин сезгә әти булып яши алмадым, гафу ит», – диде ул шул вакыт...

Мин әтине гафу иттем кебек, үпкәләр дә таралды шикелле, әмма йөрәк кичерми, сеңлем... Кичерми... Хәтер кичерми!

...Дөньялыкныкы – дөньяда калсын... Күңелдәге, йөрәктәге ул авыр йөкне алып ташлар өчен нәрсә эшләргә кирәк икән соң? Аннан котылыр өчен бер гомер генә җитәрме?

Җитсен иде...



Фәгыйлә
ШАКИРОВА

# ҺАДИ

Әлмәт районының Елховой, Түбән Абдул авылы якларында «Һади бураны» дигән гыйбарә яшәп килә. Ул бик аянычлы вакыйга белән бәйле.
Фронтовик Һади абый белән булган хәлне бу якларда белмәгән кеше сирәктер.
Әле дә хәтерлим, без кечкенә чакта өлкән яшьтәгеләр шушы тарихны бала-чагага бик тәфсилләп сөйлиләр иде.
Сугыш тәмамланып ничә ел узды, ләкин фронтовикның ачы язмышы бүген дә беркемне битараф калдырмый, искә төшеп җанны актара, күздән яшьләр чыгара.

Фото: pixabay.com.

Бөек Җиңү көненнән соң бер елга якын вакыт узса да, тыныч тормыш урнашмаган әле. 1946 елның март ае. Сугышта катнашканнар берән-сәрән туган җирләренә кайтып торалар. Типсә тимер өздердәй ирләрне сугыш танымаслык итеп үзгәрткән: кайтучылар арасында гарип калганнар да, аяксыз-кулсызлар да бар. Фронтовикларның сугыштан әйләнеп кайтуы – авыл халкы өчен зур вакыйга, бәйрәм: ул йортка атналар буе халык агыла. Елашалар, хәл-әхвәл белешәләр. Кулларына кара кәгазь алган аналар, хатыннар да килә, фронт турында сорашалар. Иң кадерле кешеләрен югалтсалар да, йөрәкләрендә өмет чаткысы сүнмәгән: «Син дә кайттың, минем улым да, минем ирем дә кайтыр» – дип, үз-үзләрен юаталар. Авылда кемнеңдер исән-имин әйләнеп кайтуы толлар җанындагы сүнгән өметне уята...

Ирләрен көтеп яшәүчеләр арасында алты бала анасы Нәкыя дә була. Ул да ире Һадины зарыгып көтә. Юк-юк, кара кәгазь алмаган ул, Аллаһ сакласын...

Нәкыя белән Һади бик яшьли яратышып өйләнешәләр. Әлмәт районы Түбән Абдул авылы кызы чибәрлеге белән күпләрне үзенә гашыйк итә. Нәкыя үзенә яр итеп егетнең иң асылын – зәп-зәңгәр күзле, кара чәчле, төз гәүдәле Елховой авылы егетен сайлый. Һади бар яктан килгән, уңган егет була. Бергә уртак тормыш корып җибәргәч, бер-бер артлы алты балалары – дүрт малай һәм ике кыз дөньяга килә: Әбелхарис, Әкрәм, Әбелкәрам, Кәүсәрия, Мингакыйлә, Мөхәррәм. Сугыш башланганда олы уллары Әбелхарис җиткән егет була инде. Военкоматка аны иң беренчеләрдән чакыралар. Ул китеп озак та узмый, чират әтиләренә җитә.

Гаилә терәге булган иң газиз кешеләре фронтка киткәч, Нәкыягә биш баланы тәрбияләү бер дә җиңел булмый. Ул колхоз эшеннән кайтып керми, бушаган арада ризык хакына хәллерәк авылдашларына эшкә яллана. Өйләр юа, бакча казый. Нәкыянең әти-әнисе Хәлиулла абый белән Хәлимә апа кулларыннан килгәнчә оныкларны карашырга булыша, күршеләре дә ярдәм итеп тора.

Ул чорда беркемгә дә җиңел булмый. Авыл халкы авызыннан өзеп булса да, мохтаҗ балаларга өлеш чыгара.

Нәкыянең иң кечкенә улы – 2 яшьлек Мөхәррәм эче күбүдән газаплана. Колхоз кырларында җыелган уңыш фронтка китә. Ул елларда ачтан үлмәс өчен авыл халкы алабута онынннан питрач пешерә. Сабыйның бу ризыкны ашауга эче авырта башлый. Бала елаган тавыш бөтен урамга ишетелә. Күршеләре Нурислам белән Фәрхинур гаиләсе хәлле кешеләрдән санала. Ипи салгач, Нурислам хатынын Нәкыя яшәгән йортка кертеп җибәрә: «Бар, хатын, сабыйга ризык керт, ашасын, бәлки елаудан туктар», – дия торган була. Уң як күршеләре Хәтимә абыстай кәҗә асрый. Арык булса да, хайван сөтне мулдан бирә. Хәтимә карчык та, балаларны кызганып, Нәкыягә кәҗә сөте кертә.

Шулай итеп, мәрхәмәтле авылдашлары ярдәме белән Нәкыя балаларны ачлыктан саклап кала.

Бу авыр елларда фронттан килгән хатлар гына хатынга көч бирә. Улы да, ире дә Берлинга хәтле барып җитә. Сугыш тәмамлангач, Әбелхарис исән-сау туган йортына әйләнеп кайта. Һадины гына җибәрмиләр, көтегез, дигән соңгы хаты 1946 елның февралендә килә.

1946 елның 24 марты. Бу көнне гомер булмаганча буран котыра. Хәлиулла абзый, буран ачмасын дип, җил капканы бау белән бәйләп куя, мич төннеген тикшерә. «Ходаем, уткүз генә чыга күрмәсен», – дип, бисмиллаларын әйтеп, йокларга яталар. Төн уртасында йорт тәрәзәсен кагалар. Бу тавышка уллары – 14 яшьлек Исмәгыйль уяна. «Торыгыз, тәрәз шакыйлар», – дип, малай әти-әнисен уята. «Мондый шыксыз кара төндә кемнәр йөрер, бер-бер бәла чыкмагандыр бит?» – дип, ир белән хатын, сукрана-сукрана, җылы урыннарыннан торып, тәрәзә каршына килләр. Урамда буран котыра, караңгыда ике кара шәүлә шәйләнә. «Киявегез Һади кайттымы? Ул бит безнең белән бер олауда иде...»

Өй хуҗалары тәрәзә дөбердәтүчеләрне танып та өлгерә алмый кала – серле юлчылар урам караңгылыгына кереп югала.

Көтелмәгән бу хәлдән барысы да аптырап кала, йокылары кача, төнне ничек уздырырга белмиләр. Иртәнге якта буран бераз басылып, офыкта яктылык шәйләнгәч, Хәлиулла абзый өстенә иске бишмәтен киеп, аягына киез катасын эләктерә дә, кызы яшәгән Елховой авылына чыгып китә.

Иртә таңнан ах-ух килеп кергән атасын Нәкыя бик гаҗәпләнеп каршы ала. Өйдә тынлык, балалары изрәп йоклый, ә ире кайтмаган...



Фотолар гаилә архивыннан.

# БУРАНЫ

Шынталы станциясендә поездан соры шинельле, башына бүреген батырып кигән, кулына агач чемодан тоткан фронтовик төшеп кала. Авылына кайтып баручы Һади була ул. Нәкъ шул көнне станциягә олаулар белән Түбән Абдул, Елховой авылы кешеләре килә. Фронтовик шул олауларның берсенә утырып, авылга кайтырга чыга. Чирмешән чатына җиткәч, бик каты буран кузгалып, юлны югалталар. Адашканнарын аңлап, туктарга мәҗбүр булалар. Атларны бер җиргә туплап, олаучылар бүленәләр дә, юл эзләргә карар кылалар. Күпмедер вакыттан соң кабаттан җыелып, юлларын дәвам итәләр. Ләкин Һади гына алар арасында булмый. Кызганыч, һәркем үз уена бирелеп, солдатның юклыгына игътибар да итми.

Фронтовикның юкка чыгу хәбәре яшен тизлеге белән тирә-юньгә тарала.

Халык Нәкыяләр йортына агыла. Якын туганнары Вәлиәхмәт, Хәбибулла, Талип, олпат гәүдәле Гобәйдулла да читтә калмыйлар. Колхоз рәисе Кыям каравылчы Гомәргә хәллерәк атларның барысын да җигәргә боера. Күршеләре – япон сугышында катнашып, яңа гына кайтып төшкән Миншакир, Әхмәтгата, Кәшиф, I, II дәрәҗәдәге Бөек Ватан сугышы орденнары иясе Гыйльметдинов Гата, авыр яралар белән аксап кайткан Фәтхетдин, Камил, Шәфикъ, Сәлимҗан, кодалары Мингата белән Фәтхетдин – авылда йөрерлек хәле булган һәркем Һадины эзләргә китә. Тирә-юньне ничек кенә айкамасыннар, фронтовикны таба алмыйлар. Эзләүләр икенче көнне дә дәвам итә. Ниһаять, Коры елга дип атап йөртелгән урында, Бәркәтә авылы янында – басуга чәчеп калдырган киндер чүмәләләренә сөялгән хәлдә фронтовикның үле гәүдәсе табыла. Солдат, көлтәгә таянган килеш, уң кулы белән бүреген күкрәгенә кыскан хәлдә җан биргән...

Ни кызганыч, алты ел буе ут астында йөргән, Берлинга барып җиткән Һади абый, туган авылына җитәргә ике чакрым кала буранда адашып вафат була...

Солдатның гәүдәсе салынган чана Түбән Абдул авылына килеп кергәч, күтәртмәле чабаталы бала-чага ат артыннан чаба.

Хәзерге көндә авылда гомер итүче хөрмәтле Вәгыйзә апа белән Исмәгыйль абый, әти-әниләре Миндар абый белән Гаҗибә апаның сөйләгәннәреннән:

– Бала-чага мәет салынган чана артыннан йөгерде. Солдатның ике аягы чанадан чыгып бара. Бер аягында ботинкасы бар, икенчесендә – юк, зәңгәр төстәге ноские генә күренә. Солдатның үле гәүдәсен туган йортына кайтарып салалар. Берни аңламаган сабыйлар шатлана-шатлана: «Әти кайтты! Әти сугыштан кайтты!» – дип, аталарының үле гәүдәсен кочаклыйлар, битеннән үбәләр. Бу хәлне күзәткән халык, тыела алмыйча, үксеп елый...

Кайгысыннан шашар хәлгә җиткән Нәкыяне күршесе Бибигайшә карчык, кочаклап: «Елама! Минем ике улым да сугышта үлеп калды. Синең Әбелхарисың исән кайтты бит, иреңнең үле гәүдәсен булса да күрдең, син миннән бәхетлерәк», – дип юатырга тырыша. Фронттан кайткан Гобәйдулла абзый исә Һадиның ике баласын ике кулы белән кочаклап, бите буйлап аккан күз яшьләрен сабыйларның әле берсенең җилкәсенә, әле икенчесенекенә сөртә. Авылның аксакалы Әхмәтша бабай мәетнең башыннан сыйпап, үксеп елый: «Әҗәлең бураннан булса, яз җиткәч тә буран чыгар», – дип кабатлый... Аянычлы фаҗига турында Чирмешән хастаханәсенә хәбәр итәләр. Военкомат хезмәткәрләре, табиб килеп җитә, мәетне җентекләп карап чыга, протокол төзиләр. Солдатның гәүдәсендә сугышта җәрәхәтләнгән җиде яра табалар. «И-и, нинди аяныч, озак эзләгәнсез шул, – ди табиб. – Солдат бүген таң алдыннан гына җан биргән, култык асты да суынып өлгермәгән».

...Кичке авыл тынлыгын бозып, кемнәрдер җыр суза. Әле генә фронттан кайтып төшкән, оста итеп гармунда уйнаганы өчен халык тарафыннан «Сандугач» кушаматы алган Кыям тальян гармунда уйный. Аның янында сугыштан исән-сау әйләнеп кайткан кордашлары – Әтәч Шәфикъ белән Тансык Гомәр. Ирләр, авылны яңгыратып, авылдашлары Һади истәлегенә багышлап чыгарган җыр суза: *Бураннар дулый икән лә, / Җаннарны урлый икән. / Ялгыша икән язмыш та, / Хисаплап тормый икән... / Тәрәз ярыкларына ла / Сабын кыстырма икән. / Кыйбла яктан җилләр исәр, / Сагынып сызгырма икән...*

Бу җырны ишеткән апа-әбиләр яулык чите белән күз яшьләрен сөртә, ирләр исә авыр көрсенеп куя, карашлары уйчанлана...

Алты ел буе фронт юлларыннан үткән, җиде тапкыр яраланып госпитальләрдә яткан Һади Дәрҗеманновның исеме «Хәтер» китабына кертелгән. Нәкыя апа алты баласы белән фронтовик ире янына җирләнгән. Оныклары бабалары истәлеген онытмый – Җиңү бәйрәмендә уздырылучы Үлемсез полкта Һади Дәрҗемановның фотосын күтәреп чыгалар.

Бүген дә март аенда чыккан буранны Әлмәт районы халкы «Һади бураны», дип атап йөртә...

# «ӨЙДӘ МИН ИШЕТЕРГӘ ТЕЛӘГӘН КЕШЕНЕҢ ТАВЫШЫ ЯҢГЫРЫЙ...»



Марат ШӘЙДУЛЛИН (Нур Алиев) – режиссер, дрон пилоты; гаилә стажы – 23 ел; 8 һәм 14 яшьлек ике кыз әтисе.

**Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...**
**Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.**

**1 Иң элек хатын-кызның сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...**

– Мөлаемлыгынадыр, мөгаен. Ир-атлар урамнан узып барган чибәр хатын-кызга игътибар итми калмый, билгеле. Әмма минем күзләрендә нур, йөзендә самимилек, ихласлык булган хатын-кызга төшә нигәдер күзем. Мөлаем кешенең эчке дөньясы аның күзләре, елмаюы, карашы аша күренә. Ә тышкы матурлык артында бернәрсә дә булмаска мөмкин... Үз хатынымның иң элек кайсы ягы җәлеп итте икән, ике сүз белән әйтү авыр. Безнең мәхәббәт тарихы бик катлаулы, сикәлтәле, күп сынаулар аша узган тарих булды. Мин аны беренче тапкыр абитуриент чакта күрдем. 1993 елның җәе. Университетка керергә, имтиханнар бирергә әзерләнеп йөргән чак – көн саен лекцияләргә барам. Йөзләп абитуриентны сыйдырган зур аудиториянең соңгы рәтенә – иң югарыга менеп утырам. Түшәмнәр биек, диварлар киң. Яңа дөнья, таныш булмаган мохит. Күңелдә – моңарчы татымаган ирек хисе... Беркөнне иң беренче рәткә кереп утырган туташларның берсенә күз төште. Яхшы укучы, иң тәртипле кызлар, гадәттә, алгы рәтләрдә утыра бит. Тәнәфескә чыкканда да гел аны күзәтәм. Килеш-кыяфәтенә караганда, шәһәрнеке булырга тиеш: үзен иркен тота, авыл кызы болай бизәнми дә... Имтиханнарны биреп, татфакка укырга кердек, мин 1133 нче төркемгә эләктем. Күзем төшкән кыз да укырга кергән. Тик ул 1134 нче төркемдә, староста! Ул арада беренче курслар «День первокурсника» кичәсе уздыра башлады. Музыка белән кызыксынуым күпләргә мәгълүм иде инде – 1134 нче төркемдәге таныш егетләр мине үзләренә музыка көйләргә чакырдылар. Гөлнара белән беренче якыннан аралашуыбыз шунда булды. Бергә биедек!.. Иң истә калганы – көлмәге, чит Галәмнән килгәнмени – көмешсыман ялтыравык төстә, хәтта утны сүндергәч тә күренә...

**2 Хатын-кызның кайсы сыйфатын гафу итеп була?**

– Әгәр ир-ат белән хатын-кызга бергә булу рәхәт, алар бер-берсенә тартыла икән, миңа калса, теләсә нинди сыйфатларны гафу итәргә генә түгел, аларны, гомумән, күрмәскә дә була. Ниндидер вак кимчелекләрне, шул исәптән, хатын-кызларга хас күп сөйләшүне... Гөлнараны күп сөйләшә дип әйтә алмыйм, ләкин кайвакыт ниндидер проект өстендә утырганда, ул эштән кайта да өй эшләре белән шөгыльләнә-шөгыльләнә миңа нидер сөйли... Күп вакыт сүзнең нәрсә хакында барганын да аңламыйм, ләкин беләм – өйдә мин ишетергә теләгән кеше бар, һәм хәзер аның тавышы яңгырый.

**3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?**

– Җитди сорау... Рухи хыянәт өчендер, мөгаен. Бу хатын-кызга гына түгел, ә дуслык, хезмәттәшлек мөнәсәбәтләренә дә кагыла. Әгәр якын кешең синең белән бергә булып, башка берәү турында уйласа, моның белән килешү бик авырдыр. Хыянәт дигәндә күпләр физик хыянәтне күз алдында тота, әмма монысы бит куркынычрак. Тән хыянәте ниндидер бер хата, очраклылык кына булырга да мөмкин һәм кешенең уйлары синең белән калса, бу хатаны төзәтергә – кичерергә була. Ә рухи хыянәтне – юк.

**4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр.**

– Икесе дә якын! Үземне немецлар кебек педант дип әйтә алмыйм, ләкин миңа һәрбер әйбернең тәртибе булу зарур. Әтидән күреп, мин дә шулай күнеккән. Өйдә бар яктан да тәртип безнең: балаларның өс-башы каралган, дәресләре әзерләнгән, өстәлдә – тәмле ризык: мин бик бәхетле ир-ат – һәр көнне өйдә ресторандагы кебек ашыйм!.. Менә шуңа күрә дә, нинди дә булса проектка тотынганда, ул эшне ерып чыгарга комачаулардык әйберләр турында уйламыйсың. Чөнки беләсең – гаиләңдә тәртип. Синең бурыч – эшеңне уңышлы башкарып, өйгә табыш алып кайту. Ә илһамландыру... Әгәр хатының өйгә кайтып кергәч җырлыйсың килә икән, димәк, ул сине илһамландыра!

**5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?**

– Әлбәттә! Без хатыным белән тормышта кайбер мәсьәләләрне дус белән дус статусында хәл итәбез.

**Бу – табигый. Ир белән хатын гына түгел, ир-ат белән хатын-кыз арасында да дуслык була ала дип саныйм. Югыйсә алар арасында ниндидер мөнәсәбәтләр барлыкка килә икән, һичшиксез секс белән дәвам итәргә тиеш дигән фикер бар. Килешмим! Сабакташ кызлар белән университет елларында барлыкка килгән мөгамәләләр бүген дә саклана. Шундый тугры дуслар гына бер-берсенә эчкерсез ярдәм итә ала, аның өчен нидер көтми, сорамый, таләп итми.**

**6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?**

**– Теге кичәдә беренче тапкыр биедек, дидем... Үзең ошаткан кыз белән беренче бию, аңа беренче кагылу – ул бик тылсымлы әйбер. Нерв импульслары дәрәҗәсендә аңлыйсың – ул синең кешеме, түгелме? Һәр хатын-кызның үзенең табигый исе була. «Шанель № 5» хушбуе турында сүз бармый монда... Миңа аның исе дә ошады. Йөрәк дөп-дөп тибә... Шул кичне үк карарга килдем: беренче семестрдан соң, өстәмә имтиханнар бирәм дә, аларга – тарих төркеменә күчәм. Мин аңа якынрак булырга тиеш!**

**Без өч тапкыр ташлаштык. Беренчесендә әби-бабай янына авылга ук кайтып киттем. Уку елы уртасында! Дөнья беткән кебек иде... Берничә көннән соң мине алырга авылга делегация килеп төште. Арада Ул да бар иде...**

**1998 елда диплом алдык һәм шул елның августында без өченче тапкыр араларны өздек. Нишләтәсең, икебездә дә көчле характер... Иң авыр аерылу шунда булды. Ул вакыт мин «Курай» радиосында эшлим, телевидениедә «Сәлам юллыйм» тапшыруын алып барам – бөтен кеше таный. Сиңа көн саен йөзләгән кызлар шалтырата. Кайберләре подъездда көтеп тора. Әйе, син күпләр кызыгырлык кияү егете, синең белән танышырга, якынаерга телиләр, ә сез тагын ташлашасыз... Шул көзне аспирантурага укырга кердем. Декабрьдә инглиз теленнән лекцияләр башланды. Язмыш! Кинәт аудиториягә Ул керә! Гөлнара да аспирант икән, тик башка институтта. Лекция вакытында: «Дәрестән соң ашыкмыйсыңмы?» – дигән хат кисәге килде. «Юк», – дип җавап бирдем... Аңладым, ул үзгәргән, ләкин суынмаган. Мин дә һаман янам! Беренче тапкыр әни белән киңәшләштем ул көнне. «Синеке дип уйлыйсың икән, тәвәккәл бул», – диде ул... Шимбә көнне «Сәлам юллыйм» тапшыруының туры эфирында «Чык миңа кияүгә!» – дип тәкъдим ясадым. Гөлнараның ишетәчәген белә идем – татар гаиләсе шимбә кичендә «Сәлам юллыйм»ны карамыйча тагын нишләсен инде?!**

**7 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?**

**– Ә нинди хатын-кызларны? Кайсы чорда? «Москва слезам не верит» фильмында Гошаның: "У вас взгляд незамужней женщины. Они смотрят оценивающе", – дигән атаклы җөмләсен хәтерлисезме? Аерылган хатын-кызларны ир-атларда бер нәрсә җәлеп итә, 18 яшьлекләрне – икенче... Күзәткәнем бар: бүген кайбер кызлар иң элек егетләрнең аяк киемендә нинди логотип булганына карый. Әгәр «NB» икән, «текә» диләр, башкага исләре китми. Ир-атның авызыннан чыккан сүзләре белән кылган эшләренең тәңгәл килүенә игътибар итсен иде алар. Ниндидер ялтыравыкка, лейблга, прическага гына мөкиббән булу – хата.**

**8 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике Галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.**

**– Без 1999 елда өйләнештек, беренче балабыз 2008 елда туды. Кызыбызга нинди исем кушу мәсьәләсе алдыбызда тормады, чөнки 9 ел алдан беренче баламның кыз булуын, исеме Мәдинә икәнлеген төшемдә күрдем... УЗИдан чыккач: «Кем була дип нигә сорамыйсың?» – ди Гөлнара. «Мин бит беләм», – дим. «Ул Мәдинә булырга тиеш», – дип, төшемне сөйләгәч, хатыным берсүзсез ризалашты. Ә бит күп хатын-кызлар: «Мин – баланың анасы, үзем теләгән исемне кушарга хакым бар!» – дип әйтә диләр...**

**9 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.**

**– Бу очрак безнеке түгел. Әйткәнемчә, өйләнешкәннән бирле тәмле ашап яшим. Ә кухняга, гомумән, кысылмыйм. Пешермим дигән сүз түгел бу: тамак ачса, әлбәттә, нидер әзерли алам. Беренче балабызны көткәндә, Гөлнара ай ярым хастаханәдә ятты – кирәк булгач, пешердем. Әмма «нигә андый май салмадың», «нигә тозың эре» дип бәйләнү, кысылу гадәтем юк. «Бүген дөге пешерәбезме, әллә карабодаймы» дип тә бәхәсләшмибез. Әгәр шулар хакында да сүзгә киләсең икән, ничек яшәп бетәргә кирәк?!**

**10 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.**

**– *(Көлә.)* Безнең гаиләдә соңга калучы миндер... Хатыным – төгәл кеше, алдан төзеп куйган җәдвәл белән яши, һәм кайчак безнең расписаниелар бер-беребезнеке белән туры килеп тә бетми. Нәрсә беләндер мавыгып китәм икән, мине аннан кире чыгару авыррак шул... Ә хатынымның башында һәрвакыт план бар һәм шул планны ничек үтәү ысуллары да әзер. Юкка гына иминият компаниясендә җитәкчеләрнең берсе булып эшләми. Алдарак «хатын – ул синең өчен дус та», дидек. Минеке әле сәркатип тә. Берәр эш белән мавыгып, бөтен дөньямны онытуымны белгәнгә, еш кына ватсапка язып җибәрә: «Син бүген шул кеше белән очрашырга тиеш идең». Мин моны үзем турында кайгырту дип кабул итәм.**

**11 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.**

**– Мондый хәлдән күңел төшмәсен өчен бүләкне ниндидер әйбер дип көтәргә кирәкми, ул – бары игътибар гына. Футболчы Аршавинның җанатарлар күңеленә кереп калган сүзе бар: «Ваши ожидания – ваши проблемы», – дигән иде ул команда оттырганнан соң... Гөлнара бүләк сайлауда миңа караганда күпкә талантлырак: шаблоннардан читкә китә белә. 35 яшемә ул миңа телескоп бүләк итте. Күк, ай, йолдызлар белән мавыксам да, үземнең аны алырга башыма килмәс иде. Бакчага баргач, кызларым белән бергә телескоптан Галәмне өйрәнәбез. Кызыксыналар, сораулар бирәләр – яңа белемнәр туплыйлар... Бу бүләккә инде ничә ел, ә гаиләбезгә ул әле дә ниндидер мәгънә өсти.**



Тулысынча укыгыз »



Фото: pexels.com



**Сорауларга Республика клиник тире-венерологик диспансеры дерматологы Наталья ИСМӘГЫЙЛЕВА җавап бирә**

**Баланың арт ягына вак бетчәләр чыкты, кызарып та тора. Бер атна дәвам итә инде бу. Подгузникны икенче төрлегә дә алыштырып карадык, ярдәм итмәде. Берәр нәрсәгә аллергия микән әллә?**

Мондый бетчәләр биләүсә дерматиты (пеленочный дерматит) башлануын белдерә. Аның төп сәбәпләре – подгузник астындагы тиренең ышкылып торуы, югары дымлылык, тиренең бәвел һәм тәрәт белән контакты, pH күрсәткеченең селтеле якка авышуы һәм гөмбә инфекциясе кушылу. Биләүсә дерматитын булдырмау өчен гади генә кагыйдәләрне үтәргә кирәк: подгузникны вакытында алыштырыгыз, баланың астын сабынсыз гына җылымса су белән юыгыз; мөмкин кадәр күбрәк вакыт подгузник кимичә яткырыгыз; тирене саклый торган кремнар кулланыгыз (мәсәлән, пантенолны, цинк оксиды кергән кремнар); спиртлы, фталатлы, парабенлы, отдушкалы, антибактериаль компонентлы чистарткыч салфеткалар һәм кер юу чараларыннан баш тартыгыз.

**Ярышта катнашканнан соң кызыбызның иренендә гел герпес чыга. Сәбәбе нидә икән? Герпестан бөтенләйгә котылып буламы?**

Ирендәге герпес (лабиаль герпес) – 1 нче тип герпес аркасында чыга торган авыру. Ул лайлалы катлау һәм тирене генә зарарламый, нерв тукымасына да зыян сала. Шунда гомер буена сакланып кала. Иммун системасы вирусны тотып тора. Физик һәм эмоциональ авырлык килгәндә, ОРВИ һәм моңа кадәр булган чирләр аркасында герпес кискенләшеп китә.

**Җәй җитүгә улымның битендә ак тап барлыкка килә. Кубалакланмый, ләкин ул урында тиресе сизелерлек коры булып тора. Көз көне ул тап үзе юкка чыга. Нинди тап икән ул? Аларның гел чыгуы куркыныч түгелме?**

Бу таплар – ак лишай симптомнары. Балаларда очрый ул, куркыныч тудырмый. Йогышлы түгел, контакт аша да күчми. Ул ялкынсынудан барлыкка килеп, тиренең өске күзәнәкләрен кубаклакландыручы дерматит дип атала. Зарарланган урында тире аксылрак булып тора. Күпчелек очракта ак лишай дәвалау таләп итми һәм үзеннән-үзе юкка чыга. Тизрәк бетерер өчен эмолиентлар, тирене йомшартучы һәм дымландыручы кремнар кулланырга була.

**Җил чәчәге белән авырганда кызыбыз бетчәләрен кашып, битендә эзләр калды. Сизелмәсен өчен аларны дәвалап буламы?**

Җөйләрне дәвалау өчен хәзер бик күп чаралар бар. Әлбәттә, һәр очрак үзенчәлекле. Дерматолог сезгә ялкынсынуга каршы гормональ компонентлы тышкы йогынты чаралары да, коллаген ясалуга тәэсир итүче препаратлар да, ферментлы дарулар да, силиконлы гельләр һәм дәвалауның лазерлы методларын да тәкъдим итәчәк.

**Нәниләргә күчтәнәч!**

**Телефон камерасын QR-кодка якынайтып, аудиоформатта язылган әкиятне балагызга тыңлатыгыз.**



**Кадерле әниләр!**
**«Яшь әни» рубрикасына сездән сораулар кабул итәбез.**
**Җавап бирүче белгечләр: педиатр, гинеколог, стоматолог, невролог, хирург-ортопед, кардиолог, иммунолог-аллерголог, гастроэнтеролог, эндокринолог, офтальмолог һәм башкалар.**

**Балаларга кагылышлы сорауларыгызны – 8 (843) 2-22-09-77 телефоны аша, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт адресы буенча яисә ssuum@yandex.ru электрон адресына «Сорау–җавап» дип язып җибәрә аласыз.**



**Сорауларга Республика балалар клиник хастаханәсе гастроэнтерологы Диләрә ТАРАСОВА җавап бирә**

**? Даруханәдән балага антибиотик йә башка дару алганда һәрвакыт пробиотик та тәкъдим итәләр, өстәп саталар. ОРВИ белән авырганда, дәваланганда аларны эчү шулкадәр мәҗбүриме? Баланың ашкайнату системасында беркайчан да проблемалар булганы юк иде.**

Мәҗбүри түгел. Бу – маркетинг алымы. Күп очракта эчәкләрдә биоценоз бозылмый. Микрофлорада берәз үзгәрешләр булса да, үз вакыты белән уза ул. Әлбәттә, антибиотиклар кулланудан эч китүче пациентлар да бар, алар бу үзенчәлекләрен белеп, пробиотик кулланалар. Антибиотик куллануда бер нечкәлек тә бар әле. Сакланган пенициллин дигән препаратлар бар. Алар амоксициллин һәм клавулан кислотасы комбинациясеннән тора. Эч китүне нәкъ менә клавулан кислотасы китереп чыгара да инде. Амоксициллиннан мондый реакция булмый.

**? Кызыбызга өч атна тирәсе булганда эч чәнчүләр (колики) башланды. Тиздән биш ае тула, имезүдән башка ризык биргән юк әлегә. Эч авыртулары әле дә туктамады. Алар шулай озак дәвам итәме? Бәлки бу чәнчү түгел, башка төрле авырудыр?**

Балаларда күзәтелә торган эчәк чәнчүләре гадәттә алты айда бетә. Үскән саен ул авыртулар баланы сирәгрәк борчый һәм бөтенләй туктый. Шуннан ары да эче авыртып борчыса, гастроэнтерологка мөрәҗәгать итегез. Гадәттә моның сәбәбе берничә булырга мөмкин. Лактоза җитешмәүне ачыклау өчен тәрәтне углеводка тикшерү буенча анализ бирегез. Сыер сөте аксымына аллергияне белер өчен үзегез кулланган ризыкларга игътибар итегез, сөт ризыкларын киметегез. Невролог консультациясе баш сөягә эчендәге гипертензия булу-булмавын ачыклар. Санап киткән тикшерүләрне табибка барганчы ук үтеп куйсагыз да ярый.

**? Улыбызга лямблиоз дигән диагноз куйдылар. Озак дәвалансак та, уң яктан эч авыртулары туктамады. Лямблиоз башка органнарга йогынты ясап, өзлегү барлыкка килмәсме? Кайсы җирен тикшертеп карарга икән?**

Лямблиоздан өзлегү булмый. Ә менә лямблияләргә каршы препаратларның йогынтысы булырга мөмкин. Алардан дару гепатиты да барлыкка килә кайвакыт. Лямблиозга кадәр балада, бәлки, үт куыгы патологиясе йә Одди сфинктеры булгандыр. Шуңа күрә корсак куышлыгына УЗИ ясатырга һәм биохимик күрсәткечләргә кан анализы тапшырырга кирәк (АЛТ, АСТ, гомуми һәм туры билирубин, ГГТП, гомуми аксым...). Шул нәтиҗәләр белән гастроэнтерологка мөрәҗәгать итегез.

Республика балалар клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

# СОРАУ—ҖАВАП

# БИЮ ТЕРАПИЯСЕ

**Бию – хәрәкәт итә алган һәркем өчен дару ул. Биергә яратмаган кеше аздыр да. Бию терапиясе хәтта психиатриядә кулланыла. Әмма аны гадәти бию педагогикасы белән тәңгәлләштерергә ярамый. «Ecstatig Danc»е төре XX гасыр башында барлыкка килгән. «Анда билгеле бер хәрәкәтләр, эстетика мөһим түгел. Иң мөһиме – тән хәрәкәтләре аша хисләрне, эмоцияләрне ачу. Бию барлык сфераны – акылны, эмоцияләрне, тәнне колачлап алырга тиеш. Шул вакытта гына нәтиҗәсе була: психологик киеренкелектән чыгара, стресстан дәвалый, тәндәге «блокларны» бетерә», – ди табибә, ирекле бию чараларын оештыручы Алия НАСЫЙРОВА.**

### Бию хатын-кызларга нинди тәэсир ясый?

Бию – һәркем өчен табигый халәт ул. Уйлап карагыз: йөри башлаганчы ук биибез бит. Кечкенә балалар музыка ишетүгә яткан җирләреннән тыпырчына башлый. Аларга ничек хәрәкәт итүләре мөһим түгел, бары тик ләззәтләнәләр генә. Музыка аларның җанын һәм гәүдәсен биләп ала. Үсә башлагач, кешеләр билгеле бер кысаларга керә, һәм күңел кушканча ирекле бию мәгънәсез, сәер бер шөгыльгә әйләнеп кала. Ә нәкъ менә шундый бию, киеренкелектән чыгарып, ял иттертә. Тән сәламәт булсын өчен көчле профилактика ул. Психологлар киңәшеннән башка, билгеле бер тәэсирләрсез генә – үзлегеннән тән сәламәтләнә.

### Ирекле бию белән кайчан шөгыльләнергә була?

Кәефнең теләсә нинди чагында, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ирекле бию белән шөгыльләнергә мөмкин. Басып биергә теләмисең икән, утырып, ятып хәрәкәтлән. Әмма табибә буларак әйтәм, бию бик нык файдалы. Ирекле бию төрле кешегә төрлечә тәэсир итә: кемгәдер көч кереп китәр, энергия ташый башлар, ә кемдер, кайнар ваннадан чыккан кебек, йомшарып калыр.

### Ирекле бию өчен нинди музыка файдаланыла?

Ирекле бию шаблоннардан азат, шуңа күрә музыка да гадәти булырга тиеш түгел. Музыка табигый циклларга корылган: салмак кына башлана, тизләнә, иң югары ноктасына җитә, кабат салмаклана һәм әкренләп тына. Бу дулкынга корылган музыка кешегә эчке халәтен ишетергә мөмкинлек бирә. Музыка бер жанрдан икенче жанрга да күчәргә мөмкин, иң мөһиме – ул таныш булмасын. Мондый музыкада кеше медитация халәтенә керә. Бу вакытта баш мие контролен кимәтә. Эчке ирек халәте барлыкка килә. Ә бу – безнең табигый халәт. Ә эчке ирегеңне ачу яшәү рәвешен яхшыртмый калмый.



### Аның билгеле бер кагыйдәләре бармы?

Берничә кагыйдә бар. Яланаяк яки носкидан биергә. Сөйләшмәскә! Дөрес бию иң югары ноктасына җиткәндә, кычкырасы да килә башлар, бу нормаль күренеш. Шул рәвешле эчтә җыелган эмоцияләр чыга. Алкоголь кулланмаска. Безнең чараларда мин әле күзгә битлек кияргә дә киңәш итәм. Кешеләр миңа карыйдыр, сәер тоеламдыр дигән уйлар комачауламасын өчен эшләнә бу.

Фото:

### Стресс белән көрәштә дә бию ярдәм итәме?

Һичшиксез! Бию терапияләре рәсми медицинада да кулланыла. Өч минут бик тиз хәрәкәтләнеп бию дә стресска каршы торучанлыкны арттыра. Бәхет, үсү гормоннары бүленеп чыга башлый. Бу исә стресс белән бәйле авырулар килеп чыгуын кимәтә.

# КҮРҮ СӘЛӘТЕН ЯХШЫРТАБЫЗ

**70 процент мәгълүматны күзләр аша кабул итәбез. Шуңа күрә дә күз күременең камил булуы мөһим. Шунысын да әйтергә кирәк: тәннең күп проблемалары күз мускуллары эшләмәгәннән. Безнең организмда бөтен нәрсә үзара бәйләнгән бит. Махсус күнегүләр ясагач, күзләрнең күрүе дә, тән хәрәкәтләре дә яхшырыр. Рубрикабызның даими эксперты массажист Ләйсән САБИТОВА махсус күнегүләр өйрәтә. Аларны балаларыгыз белән бергәләп эшләсәгез, тагын да яхшырак булыр, чөнки гаджетларда озак утырган балаларның күрү сәләте начарая, алар бөкрәя башлый. Шулай ук үзегез дә көн дәвамында компьютер артында утырганда, берничә минутка тәнәфес ясап, бер-ике күнегүне ясый аласыз. Файдасын бик тиз сизәрсез.**





*Иң элек тест узабыз. Моның өчен алга, артка бөгелеп карыйбыз, кулларны хәрәкәтләндерәбез. Күз өчен күнегүләрне ясап бетергәч, бу тестны тагын узыгыз, хәрәкәттәге үзгәрешләрне сизми калмассыз.*



- Ачык килеш күзләрне учларыбыз белән каплыйбыз. Яктылык үтеп кермәскә тиеш, шулай бер минут дәвамында торабыз.
- Әле бер күзне, әле икенчесен каплап, озак итеп бер ноктага карап торабыз.
- Шулай ук бер күзне каплап, икенчесе белән әле ераккка, әле якынга карыйбыз. Икенче күз белән дә шундый ук күнегү ясыйбыз. Күзләр арыса, туктагыз.
- Берәр карандаш алып, аны кул сузымы ераклыгында төрле фигуралар ясап йөртәбез. Бу вакытта бары тик күзләр генә хәрәкәт итә. Башны селкетмәгез. Бу күнегүне һәр күз өчен аерым ясасагыз, тагын да яхшырак.
- Шулай ук карандашка карыйбыз. Аны ерагайтабыз һәм ул ике булып күренә башлаганчы күз янына китерәбез. 10–15 тапкыр шулай эшләгез.
- Карандаш – кул сузымы ераклыгында. Күзне алмыйча аны читкә җибәрәбез һәм күзне йомгач, кире урынына кайтарабыз. Бу күнегүне дә әле – бер, әле икенче күзне каплап ясыйбыз.
- Җайлап утырып, киеренке халәттән чыгабыз. Кул учларын маңгайга «ябыштырабыз» да әкрен генә тирене өскә таба тартырабыз. Йомык күз белән төрле фигуралар эшлибез (квадрат, сигезле, өчпочмак). Бу вакытта биттәге мускуллар, тел, авыз, иреннәр селкенергә тиеш түгел. Әгәр күзне йөрткәндә телегез дә кушылса, димәк, күз мускуллары начар эшли.
- Күнегүләрне ясаганнан соң, күзләр белән баш мие арасындагы бәйләнеш яхшырып китәр, бу исә башка органнар эшчәнлегенә дә файдалы.















QR-код аша кереп, массажны видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

PRESSA



# Сюрпризлы коймаклар





**Май – табигатькә чыгу, дуслар белән ял итү чоры да бит әле ул. Озын-озак кышлардан соң күңелнең иркенгә сусаган мәле. Зәңгәр телле тәтеннәрнең хуш ис бөркеп ак болытларга үрелгәне сагындырган. Алдагы елларда без инде төрледән-төрле шашлык рецептларын да, хашлама, парламаише ашлар әзерләү серләрен дә уртаклаштык. Укучыларыбыз үз итеп өлгергән аш-су остасы Венера АРСЛАНОВА бу юлы бераз үзгәрәк ризык пешереп карарга тәкъдим итә. Аны әзерләү өчен кирәкле ризыклар да суыткычта һәрчак бар. Бризоль икенче аш буларак та, кайнар кабымлык буларак та яхшы. Аны үзең белән табигатькә чыкканда да алырга була. Кайнар килеш тә, суынгач та тәме үзгәрми. Венера ханым әзерләгән ризыклар тәмлелеге белән дә, гадилеге һәм һәркем әзерли алырдай булуы белән дә аерылып тора. Бу бризольләрне бер әзерләп карасагыз, яраткан ризыгыгызга әвереләсенә шигебез юк.**



**Кирәк** 700 г фарш / 1 баш суган (150 г) / 200 г сыр / 150 г тозлы кыяр / 2 помидор / 9 йомырка / 150 мл сөт / яшел тәмләткечләр / 200 г кибет каймагы / 3 теш сарымсак / тәменчә тоз-борыч, паприка / фаршны җәю өчен бер-ике уч он.


**Эш барышы** Фаршка суган кушылмаган булса, бер баш эре суганны вак угычтан уып, иткә кушабыз. Тәменчә тоз-борыч, төелгән баллы борыч (паприка) өстибез һәм барысын бергә яхшылап катнаштырабыз. Әлеге күләмне 9 тигез өлешкә бүлеп, шарлар әвәлибез.

- Сырны эре угычтан уабыз, тозлы кыяр белән помидорны озынчарак итеп ваклап турап куябыз.
- Сарымсакны вак угычтан уып яки пресстан издереп, каймакка кушабыз. Шунда ук ваклап туралган яшел тәмләткечләрне дә салып, барысын бергә болгатабыз.
- Тирән тәлинкәгә бер йомырканы сытып, бер аш кашыгы сөт һәм тәменчә тоз кушабыз. Чәнечке белән яхшылап туглыйбыз.
- Ике полиэтилен пакет арасына куеп, иттән әвәләнгән бер шарчыкны уклау белән җәябез. Җәемнең зурлыгы өлеш тәлинкәсе кадәр булырга тиеш. Он сипсәң, итне җәю җайлырак.
- Тугланган йомырканы зуррак сай тәлинкәгә бушатып, ит җәемен шунда каплыйбыз һәм аз гына май салган кызган табага йомырка аста калырлык итеп шудырып төшерәбез. Өстен капкач белән каплап, һәр ягын дүртәр минут кыздырабыз.
- Әзер коймакны тәлинкәгә алып (итле ягы өстә калсын), сарымсаклы-каймаклы соусны ягабыз, аның өстенә сыр сибәбез һәм бер буй итеп туралган помидор белән кыяр куеп чыгабыз.
- Коймакны тәгәрәтеп төреп, рулет ясыйбыз.
- Калган сигез йомырка һәм ит шарларыннан да шул рәвешле бризольләр пешереп бетерәбез.
- Өстен кетчуп һәм яшел тәмләткечләр белән бизәп, табынга чыгарабыз. Янына яшелчәләр белән әзерләнгән чуар дөге, мичтә тутырамлап кыздырган бәрәңге яки башка төрле гарнир бирергә була. Үзе генә дә бик тәмле һәм туклыклы ул.




















Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

PRESSA

# Өйнең яме — гөлләрдә


Тидея

**Тидея.** Сортына карап, шәмәхә, алсу, чуар кыңгырауларга күмелүче бу гөлне күпләр яратып үстерә. Талымсыз, яздан көзгә кадәр чәчәк ата. Җылыны һәм чәчәк атканда һаваның дымлырак булуын ярата. Вегетация чорында җылылык 22–25 градус, тынлык чорында 15 градус булса кулай. Ә дымлылыкны исә гөл тирәли һавага су бөркеп, бераз арттырырга мөмкин. Тирән тәлинкәгә юеш керамзит салып, чүлмәкне шуңа да утыртырга була. Тидея кояш туры карамаган тәрәзә төпләрен үз итә, яктылыкка артык таләпчәнлеге юк. Җәйге үтәли кояштан аның яфраклары көя башлый. Чәчәк аткан вакытында суны мул итеп өч-дүрт көнгә бер сибәргә кирәк. Чираттагы сугаруга туфрагы кипшергән булырга тиеш. Көзен һәм кышын су сибүне киметәләр. Әчелеге бераз югары булган көпшәк туфракта яхшы үсә. Язын һәм җәен айга бер тапкыр комплекслы ашламалар белән тукландыралар. Тидея – акрын үсүче үсемлек. Күчереп утыртуны ике яки өч елга бер генә башкаралар. Кисеп, формалаштырып тору мәҗбүри түгел, ләкин теләсәгез, артык яфракларын өзеп, җыйнак кына формада тота аласыз. Шиңгән яфракларыннан, чәчәк атып бетергән сабакларыннан исә гел чистартып торырга кирәк. Октябрь урталарыннан тидеяның яфраклары кибә башлый – гөл тынлык чорына керә. Аның өске өлешен бөтенләй кисеп алып, чүлмәкне салкынча һәм караңгы урынга куегыз. Ара-тирә су сипкәләргә генә онытмагыз. Яз башында гөлне яктыга һәм җылыга чыгарып, кирәксә, бүлбеләрен яңа савытка күчереп утыртырга кирәк. Тидеяны орлыктан да (аларны кыш азагында чәчәләр), сабактан да үрчетәләр. Соңгысы җайлырак ысул, беренче тамырчалар инде җиде көннән үк күренә башлый.

**Кампанула** – кәләш белән кияү чәчәге. Ак һәм зәңгәр, кайчагында алсу шәмәхә кыңгыраулар белән чәчәк атучы асылмалы бу гөлне күпләр яратып үстерә. Ак һәм зәңгәр төрләрен бергә утыртып, бик матур композицияләр тудыралар. Халык арасындагы популяр атамасы да әнә шуннан килеп чыккан.

Чагыштырмача талымсыз үсемлек. Яктылык ярата, ләкин көн буе кояш үтәли караган урыннарда чәчәкләре бик тиз сула. Көнчыгышка яки көнбатышка караган тәрәзә төпләрендә яхшырак үсә. Җәен җылылык – 20–22 градус, кышын 12–14 градус булганда үзен яхшы хис итә. Эссене авыр кичерә, ләкин җәй көне веранда яки террасага чыгарсагыз, ул тагын да купшыланып үсеп китәчәк. Көн озынлыгы кимегәндә кампанула да тынлык чорына керә – яңа сабаклар чыгарудан һәм үсүдән туктый. Киләсе язда да шау чәчәккә күмелсен өчен, өске өлешен кисеп, кышын аны салкынча урында ял иттерәләр. Дымга таләпчән, суны даими сибеп торганны сорый. Җәйге эссе көннәрдә яфракларына су бөркегәнне ярата. Ә менә тынлык чорында су сибүне киметеп, айга бер яки ике тапкырга гына калдыралар. Вегетация чорында гөлне ике атнага бер тапкыр чәчәк атучы үсемлекләргә тәгаенләнгән комплекслы минераль ашламалар белән тукландырып торалар. Яңа гына сатып алган гөлне шул ук елны күчерү кирәкми. Алга таба моны һәр елны яз көне – актив вегетация чоры башлангач башкаралар. Шулай да карт гөлне күчереп утыртуга караганда, яшь тармагын тамырландырып, яңасын үстерү отышлырак. Кампанула өчен савытның киңрәген сайларга кирәк. Көпшәк туфракларны үз итә. Тигез күләмдә торф, черемә, эре бөртекле ком, урман туфрагы кушып, җирен үзегез дә әзерли аласыз.


Кампанула


Антуриум

**Антуриум** – экзотик гөл. Аның гаҗәеп формалы, төрле төсле сортлары бар. Йөрәк рәвешендәге яки түгәрәк яфраклысы ешрак очрый. Алар ялтыравык элпә белән каплап алган сыман, купшылар. Талымлы үсемлек – чәчәкләре белән куандырсын өчен, шактый тырышлык сорый. Туры караган кояш нурларын өнәмәсә дә, көн озынлыгының 12 сәгать булуын таләп итә. Көнчыгышка яки көньяк-көнбатышка караган тәрәзә төбендә үстерүе кулайрак. Җылы ярата. Яз һәм җәй көне температура 22–28 градус, кышын 16 градус булырга тиеш. Температураның кисәк үзгәрүен дә, үтәли җилләрне дә өнәми. Дымга да таләпчән. Актив үсү чорында суны даими һәм мул сибүне сорый. Ләкин суны туфрагы яртылаш кипкәч кенә сибәргә кирәк. Артык дым тамырларының черүенә китерә. Коры һавада начар үсә, дымлылык 90 процент булу шарт. Яфракларына су бөркегәнне ярата да, чәчәкләренә су тисә, таплар барлыкка килә. Гөлне чәчәк аттыруның бер хәйләсе бар – аны ай ярым-ике ай дәвамында температура 14–16 градус булган салкынча урында тоталар. Чәчәк ату чоры – майдан сентябрьгә кадәр. Әлеге чорны озаккарак сузар өчен, сула башлаган чәчәкләрне вакытында өзеп торырга кирәк.

Антуриумны кыш азагы-март башында күчереп утырталар. Тамырлары һәм яфраклары тиз зарарланганлыктан, бу эшне сак башкару сорала. Яшь үсемлекне – ел саен, картларын ике-өч елга бер тапкыр зуррак савытка утырталар. Аның өчен таррак, ләкин биек савытлар кулай. Төбенә дренаж салып калдыру мөһим. Декоративлыгын югалтмасын өчен, гөлне яз һәм җәй даими тукландыру да сорала. Гадәттә ике-өч атнага бер тапкыр комплекслы ашламалар кулланалар, органик ашлама кулланырга да мөмкин. Әлеге гөлне орлыктан да, сабак очын тамырландырып та үрчетергә була.



Башка гөлләр үстерү турында да укыгыз.

Фото: www.pixabay.com

## тест: холкыгыз нинди?

**Кешенең холкы төрлечә була. Кемдер сабыр, кемдер ярсу... Моннан тыш, әле холыклар ир-атныкына һәм хатын-кызныкына да бүленә. Ир-егетләрнең холкы мантыйкка буйсынса, хатын-кызлар белән күбрәк хисләр идарә итә. Сез кайсы төркемгә карыйсыз икән? Үзегезнең холкыгызны ачыклар өчен, кызыклы тест узарга киңәш итәбез. Сорауларга «әйе», «юк», «белмим» дип җавап бирергә була. Уңайлы очрак чыга икән, әйдаман булырга тырышам.**

1. Авыр яки аңлаешсыз очракларда якыннарымның киңәшенә таянам.
2. Теләсә кайсы эштә карарларны тиз һәм җайлы кабул итәм.
3. Мин бик тәэсирләнүчән, кызгану хисе тиз туа.
4. Үз абруемны үзем яклый алам.
5. Үз-үземне карарга, тәрбияләргә яратам.
6. Шартларга яраклашырга тырышам, башыма беренче ни килсә, шуны эшләмим.
7. Капма-каршы җенеснең игътибарын яуларга яратам.
8. Үземне рухи яктан көчле һәм бәйсез тоям.
9. Үзем белән гел көзгә йөртәм.
10. Ачу-үпкәләрне озак саклыйм, җае чыкса, үч алырга тырышам.
11. Һәрвакыт салкынканлылык саклап кала алмыйм.
12. Мәхәббәт ул – эчке кичереш, аны һәрдаим күрсәтергә кирәкми дип саныйм.
13. Мин – романтик;
14. Холкым әтиемнеке белән охшаш.

**Нәтиҗә чыгарабыз: так сандагы сорауларга – «әйе», җөп сандагыларына «юк» дип биргән җавапның һәркайсы өчен 10 балл куегыз. «Белмим» дигән җавапның һәркайсына – 5 балл.**

**100–150 балл.** Рухи яктан – сез 100 процент ир-ат. Тәвәккәллек, мөстәкыйльлек, бәйсезлек – сезнең көчле якларыгыз. Башкаларга терәк була беләсез, бу дөньяда ни теләгәнегезне аңлыйсыз. Яшәү принципларыгыз күпләрдә соклану тудыра. Әгәр дә сез чынлап та ир-егет икән, үз җенесегезгә бәйле сорауларда стереотиплык күзәтелә. Әгәр хатын-кыз булсагыз, сорау туа – сез үз-үзегездән канәгатьме?

**50–90 балл.** Нинди шартлар булуга карап, сездә ир-атларга гына хас сыйфат та, хатын-кызларныкы гына да булган холык та чагыла. Сез йомшаклык белән тәвәккәллекне, хис белән акылны үзара яраклаштыра беләсез. Кайчагында тормыш сездән капма-каршы җенес вәкилләренә хас гамәлләр таләп итәдер. Төрле шартларга яраклаша белү, рухи сыгылмалылык теләсә кайсы очракта да юлдашыгыз булачак.

**0–49 балл.** Рухи яктан – сез 100 процент хатын-кыз. Бүген бу бик сирәк очрый торган тип. Аш-су әзерләргә, өйне тәртипләргә, балалар белән мәш килергә яратасыз, холкыгыз йомшак, башкаларга каршы килмисез икән – сез ир-атларның идеалы булырлык хатын-кыз. Чын ир-ат сезне ничек бар шулай кабул итәчәк һәм чын-чынлап яратачак. Әгәр дә сез ир-ат икәнсез... хәлегезгә керергә генә кала.

## йолдызнамә июнь

***Кучкар.*** Активлык чоры. Шактый йөгерергә һәм тир түгәргә туры килүе ихтимал. Вак-төяккә борчылып, сәламәтлекне какшатырга кирәкмәстер. Тиз алмашынып торган вакыйгаларның нәтиҗәсе уңай.

***Үгезбозау.*** Тормышыгызның матди ягы турында ныклабрак уйларга туры килер. Яңа эшкә керешер өчен яхшы вакыт. Эзләгән – тапкан, дигән мәкальне истән чыгармагыз. Юнәлешегезне үзгәртү өчен яхшы мөмкинлек чыгар.

***Игезәкләр.*** Әлеге йолдызлыкта туучыларга кояшның активлыгы көчле чор. Ул бар нәрсәдә – эштә, мөнәсәбәтләрдә, сәламәтлектә чагылыш табачак. Үзегездә күтәренкелек тоярсыз. Проблемалар булса да, тиз чишелер.

***Кысла.*** Игелек эшләү, булышу – бу айда төп эшчәнлегегез шулар булыр. Кояшның тәэсире бик зур, ул энергия белән баетачак. Ялгыз калу теләге көчәер, ул да сезнең файдага – ял итү, уйларны тәртипкә китерү мөмкинлеге туар.

***Арыслан.*** Искиткеч вакыт бу – сезне күрәләр, бәялиләр, сокланалар. Иң кыю идеяләрегезне дә тормышка ашыру форсаты чыгар. Киртәләр булмый калмас, билгеле, ләкин алар гына сезне тоткарлый алмаячак.

***Сөмбелә.*** Көчләрегезне дөрес итеп бүлә белү таләп ителә. Эш дип – гаиләгезне, гаилә дип үзегезне онытып җибәрүегез бар. Тормыштагы киртәләргә фәлсәфирәк карарга тырышыгыз. Юлыгызда перспективалы кешеләр очрар.

***Бизмән.*** Яңалыкка, белемгә омтылышыгыз көчәер. Үзегез өчен нindiдер ачыш ясавыгыз мөмкин. Бу айда барысына җиңел ирешерсез. Күңелле сәяхәт көтелә.

***Чаян.*** Тормышыгызның күп кенә өлкәләрендә үзгәрешләр булуы ихтимал. Сез үз-үзегезгә, көчегезгә ышанырсыз, уйлаганнан да күбрәккә ирешерсез. Ныклы, ышанычлы партнер очрату ихтималы зур.

***Укчы.*** Гаилә һәм эш балансын саклау өчен тырышырга кирәк булачак. Ике өлкәдә дә хәл итәсе мәсьәләләр чыгып кына торыр. Ләкин борчылмагыз: хезмәттәшләр белән килешү, көн тәртибен җайга салу өчен бу ай иң кулай вакыт.

***Кәҗәмөгез.*** Җәйнең беренче ае күңелле вакыйгаларга бай булыр. Нindiдер бер зур мөһим эшкә алынырсыз. Әлеге йолдызлыкта туганнар өчен тырышлык болай да хас сыйфат, хәзер исә ул үзенең иң югары ноктасына җитәчәк.

***Сукояр.*** Сез актив һәм оптимист. Әлеге сыйфатларыгыз күңелле вакыйгаларны магнит кебек тартып китерәчәк. Айның романтик рухта үтүе көтелә, якыннарыгызның уңышы сөендерәчәк.

***Балыклар.*** Төп игътибарыгызны гаиләгезгә бирергә туры килер. Өйдәге тыныч мохит кенә эштә уңышларга ирешергә ярдәм итәчәк. Айның беренче ун көне элемтәләр булдыру өчен кулай чор, яңа эш һәм яңа керемнәр көтелә.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.











# МИЛЛӘТ УЛ – ЯЗМЫШ

Пензада яшәп иҗат итүче Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы, талантлы рәссам Илдар Акъегет 1984 елда туа. 1999–2004 елларда – Пензаның К. А. Савицкий исемендәге сынлы сәнгать училищесында, 2004–2010 елларда И. Глазунов исемендәге Россия сынлы сәнгать академиясендә белем ала. 2012 елда Пензаның сынлы сәнгать училищесында укыта башлый. Үзе белем алган «Гармония» балалар сәнгать мәктәбендә 2004 елны беренче күргәзмәсен ача.

«Россия шәһәрләре» күргәзмәсе кысаларында хезмәтләре Мәскәү, Лондон, Копенгагенда, «Россия образы» күргәзмәсе кысаларында Мәскәү һәм Лондонда экспозицияләнә. 2008 елны Санкт-Петербургтагы «Культурное достояние» фондының яшь рәссамнар өчен тәгаенләнгән грантына, I дәрәҗәдәге дипломга лаек була. Төрле елларда Черногориядә пленэрда, Италиядә оештырылган фестивальләрдә, «Зур Идел» күргәзмәсендә катнашырга туры килә аңа. Илдар Кадим улы Канны шәһәрендә ачылган VIII һәм X Яшьләрнең рус мәдәнияте фестиваленә дә чакырыла. 2017 елны ул Мәскәүдәге «Гаилә – Россия җаны» бәйгесендә җиңә.

Картиналары 2018 елда И. С. Тургенев юбилее уңаеннан Берлин, Люксембург, Брюссель, Страсбург, Париж, Баден-Бадендагы гомуми күргәзмәләрдә экспозицияләнә. Б. Рәмиев портреты бәйгесендә приз яулый. «Ш. Мәрҗани һәм Х. Фәезханов» дип аталган картинасын «Мәдинә» нәшрият йорты заказы буенча яза. Шушы ук нәшрият йортында «Париждагы намаз» картинасы да кадерләп саклана. «Әлеге әсәрне 1814 елның язында Парижның союздаш гаскәрләр тарафыннан алынуы, шәһәргә беренче булып казак полклары да аяк басуы, татарлардан, башкортлардан, типтәрләрдән торган мөселман полкларының да Парижга керүе хакында өйрәнеп яздым. Әйе, татар милләтеннән булган сугышчылар да заманында Парижда намаз кылган!» – ди ул.

«Ибн Фадлан илчелегенең Болгарга килүе. 922 ел» әсәрен дә ул бик яратып иҗат итә. Тарихи темага башка хезмәтләре дә бар.

«Дәү әтием Фәхрисламга Беренче бөтендөнья сугышында катнашып, күкрәгенә медальләр тагып, туган ягына әйләнеп кайтырга насыйп булган, – дип искә ала рәссам. – Ә минем дәү әтием Муса Акъегетов 1941 елның 22 июнендә армиягә алынган. Әбием Сара, шул вакытта йөкле булуына да карамастан, ат арбасына утырып, район үзәге Каменкага ире белән хушлашырга киткән. Хушлашу өчен аларга нибары биш минут биргәннәр. Кире кайтканда әбием борчак кырында икенче баласын тапкан. Әбием ике нарасые белән сугыш михнәтләре аша узган. Бабам Муса Акъегетов өчен сугыш, яраланганнан соң, Белоруссиядә тәмамланган».

Татар каһарманнарын сурәтләгән яңа әсәрләрен әле дә яза рәссам. Кинохроника буенча 1945 елда Мәскәү Җәмигъ мәчетендә узган Корбан бәйрәме кадрларын карап илһамланган! Ул кадрларда хәзрәт татар телендә вәгазь сөйли, мөселман догаларын укый. Шушы елларда «Пенза җире халыклары» сериясенә дә алынган. Бу сериягә керәчәк картинасы татар бишек җырына багышланган! «Милләт ул – язмыш. Үз милләтемне бик яратам. Татарча яхшы сөйләшүем дә – газиз әти-әнием тәрбиясеннән», – дип горурлана Илдар Акъегет.


Аның «Соңгы очрашу» әсәре дә сугыш темасына багышланган. Җирдә – яз, әмма сугыш әле тәмамланмаган, күпләр сугыш ахырында да башларын яуда салган. «Теләсә кайсы сугыш – канкойгыч, бу хакта онытмыйк», – ди ул.


Әлеге тема – илебез ярасы. Әгәр дә Икенче бөтендөнья сугышында һәлак булган һәр совет кешесе өчен бер генә минут тынлык игълан ителсә дә, дөнья ярты гасырдан артык тын торыр иде дигән мәгълүмат та бар шул...

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА









ИЛДАР АКЪЕГЕТ




ТАТМЕДИА

# ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES




KazanExpress




OZON



Я Маркет






АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066 г. Казань, ул. Декабристов, 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама